Безнен МИРАС

06

июнь 2015

ФӘННИ-ПОПУЛЯР, ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ДОКУМЕНТАЛЬ ЖУРНАЛ

ТАРИХИ, МӘДӘНИ, ПЕДАГОГИК, ДИНИ МИРАС, ТӨПЛЕ ФАРАЗ, ӘДӘБИЯТ ҖӘҮҺӘРЛӘРЕ

Максатларыбыз уртак

20 нче майда Татарстан Президенты вазифаларын вакытлыча башкаручы Рөстәм Миңнеханов республика матбугат чаралары җитәкчеләре һәм федераль басма вәкилләре белән очрашты. Әлеге очрашуда республика башлыгы тормышның төрле өлкәләренә кагылган сорауларга җавап бирде.

М.Бадыйкшин фотосы

Каләм! Кальбеңдә ни сер бар — гаян ит,
Килеп кичмешләр әхвален бәян ит.
Дәрдемәнд

Безнең МИРАС 12 +
06(41)
июнь 2015

Журнал «ТАТМЕДИА» АҖ
тарафыннан гамәлгә куелды.
2012 елның май аеннан чыга.



22

ЭЧТӘЛЕК

2015 ЕЛ — РОССИЯДӘ ӘДӘБИЯТ ЕЛЫ

3 **Ач, шигърият, серләреңне.** *Саҗидә Сөләйманова*

ТАТАР ГАМЕ

4 **Искер — изге җир.** *Рәшит Минһаҗ*
12 **Пәри — башка, җен — башка...** *Рифә Рахман*
19 **Милли рух «Атлантида»сы.** *Миләүшә Хәбетдинова*

2015 ЕЛ — ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА ПАРКЛАР ҺӘМ СКВЕРЛАР ЕЛЫ

22 **Панаев бакчасы**

ТАРИХИ МИРАС

24 **Чыңгыз Айтматовны биргән Мәчкәрә.** *Фәүзия Бәйрәмова*
30 **Милли дәүләтчелек туганда...** *Рәмзи Вәлиев*
34 **«Себер тракты тарихы» музее**

ТӨРКИ ДӨНЬЯ

38 **Киңәшле эш таркалмас!**

ДИНИ МИРАС

40 **Көтебе ситтә вә мөәллифләре.** *Ризаэддин Фәхреддин*

ПЕДАГОГИК МИРАС

44 **Әхлак.** *К.Бикколый, Г.Госмани*

ҖИҢҮ — 70!

48 **Югалмасын җирдә эзләре...** *Әрибә Айтуганова*
53 **Кадерлеләр һәм кадерсезләр.** *Фәнзаман Баттал*

ХӘТЕР САНДЫГЫ

64 **Пароходта ике сәяхәт.** *Хәбибрахман Рәфыйков*
70 **Сүз һәм сурәт.** *Рафаэль Сәхәби*

ӘДӘБИ МИРАС

72 **Кутадгу билик (Котайткыч белем).** *Йосыф Баласагуни*

24 ЧЫҢГЫЗ АЙТМАТОВНЫ БИРГӘН МӘЧКӘРӘ. *Фәүзия Бәйрәмова*

110 **КОРЪӘН САВЫТЛАРЫ.** *Руфия Мөхетдинова*

Баш мөхәррир
Лемон Лерон улы ЛЕРОНОВ
(Ләбиб ЛЕРОН)
(843) 222-09-83 (17-91)

Баш мөхәррир урынбасары-җаваплы сәркатип
Марат Закиров
(Марат Закир)
(843) 222-09-83 (17-93)

Киңәшче идарә
Разил Вәлиев
(ТР Дәүләт Советының мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр Комитеты рәисе)
Илдар Гыйльметдинов
(Татар федераль милли-мәдәни автономиясе Советы рәисе)
Айрат Зарипов
(Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча Республика агентлыгы җитәкчесе)
Рөстәм Мөхәммәдиев
(«Татнефть» ААҖ генераль директоры урынбасары, «Рухият» фонды рәисе)
Айрат Сибагатуллин
(ТР мәдәният министры)
Энгель Фәттахов
(ТР премьер-министры урынбасары — ТР фән һәм мәгариф министры)
Фәрит Шаһиәхмәтов
(«ТАТМЕДИА» АҖ генераль директоры)

Редколлегия
Ислам Әхмәтҗанов
Марсель Әхмәтҗанов
Рәдиф Җамалетдинов
Фәнзилә Җәүһәрова
Ринат Закиров
Данил Ибраһимов
Зиннур Мансуров
Ким Миңнуллин
Гөлчәчәк Нәҗипова
Сөмбел Таишева
Рафаил Хәкимов

Бүлек мөхәррирләре
Ленар Гобәйдуллин
Ләйсән Данилова
Рүзәл Мөхәммәтшин
(843) 222-09-83 (17-90)

Дизайнер һәм биткә салучы
Диләрә Нәүрүзова
(843) 222-09-83 (17-92)

Корректор
Дания Фәйзуллина
(843) 222-09-83 (17-90)

Гомуми мәсьәләләр буенча мөхәррир
Рәдиф Сәгъдиев
(843) 222-09-83 (17-91)

Редакция һәм нәшрият адресы:
420066, Казан шәһәре,
Декабристлар урамы,
2 нче йорт
Электрон почта:
yanamiras@mail.ru

«Наше наследие»
Ежемесячный научно-популярный, литературно-художественный журнал (на татарском языке)

77 **«Киңәшсез сүз башлама...»** *Марсель Әхмәтҗанов*
81 **Тукай энциклопедиясе.** *Зөфәр Рәмиев*
82 **Тукай турында истәлекләр.** *Вафа Бәхтияров*
89 **Илһам канатларында.** *Фоат Галимуллин*

ШӘХЕСЛӘРЕБЕЗ

98 **Яңгырап торган мирас калдырды...** *Нәсим Акмал*

ТЕЛ КҮРКЕ — СҮЗ

106 **Миллият сүзлеге.** *Адлер Тимергалин*

100 ЕЛ ЭЛЕК...

108 **«Кояш» газетасында «Казан хәбәрләре»: 1915 елның июнь ае.** *Ленар Гобәйдуллин*

ХӘТЕР САГЫНДА

110 **Корьән савытлары.** *Руфия Мөхетдинова*

ШАЯН МИРАС

112 **Сабан туеның шаян мизгелләре.** *Алмаз Хәмзин*

ЯҢА КИТАП

115 **Кукмара төбәге тарихы — яңа китапта.** *Ләбүдә Дәүләтшина*

118 **Мирасворд**

119 **«Безнең мирас» елъязмасы.** *Июнь*

Заказ №О-1667. Тираж — 1616 данә. Формат 70 Х 108 1/16
Басарга кул куелды: 05.06.2015
Журнал айга бер тапкыр чыга. Бәясе ирекле

Журнал 2012 елның 17 апрелендә Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ПИ №ФС77-57844 нче таныклык белән теркәлде.

Мәкалә авторларының фикере редакция фикере белән туры килмәскә дә мөмкин. Редакциягә килгән язмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Материаллар бары тик электрон вариантта гына кабул ителә. Журналга кергән язмаларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела.
Типография гаебе белән киткән хаталар өчен редакция җавап бирми. Бу хакта техник контроль бүлегенә 519-44-61 телефоны белән хәбәр итә аласыз.

Бу санда Ленар Гобәйдуллин төшергән, Абдулла Дубин, авторларның һәм Татарстан Милли музее архивларыннан фоторәсемнәр файдаланылды.

«ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды. Адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт

Тышлыкның 1 нче битендә — «Сабан туе батыры!» Шәле авылы, 1973 ел.
Р.Якупов фотосы

Саҗидә Сөләйманова
(1926-1980)

АЧ, ШИГЪРИЯТ, СЕРЛӘРЕҢНЕ

Үз энҗемне эзлим һаман,
көн туса, йөрим йөдәп...
Ач, шигърият, серләреңне,
тылсымлы сүзләр өйрәт.

Гөл серләрен тыңлар идем,
чәчәк атса бер гөлем.
Таңда торып, сандугачтан
өйрәнимме җыр телен?

Боз пәрдәсен умырзая
ничек ача? – күрсәйдең.
Энҗе гөлдән мәңге шиңмәс
такыялар үрсәйдең.

Тау чишмәсе таш эретә,
әллә суы кайнармы, –
шуның серен сорыйм әле
сездән, Урал таулары.

Кем уйламый бер очарга,
йолдызларга юл төбәп.
Уйларымны җырга салам –
яшендәй сүзләр кирәк.

Ташка тисә, таш эресен,
һич сүрелмәсен йөрәк!
Ач, шигърият, серләреңне,
тылсымлы сүзләр өйрәт.

1960

ИСКЕР – ИЗГЕ ҖИР

Рәшит Минһаҗ

Әле күптән түгел генә Казаныбызда уздырылган Татарстанның эшлекле хезмәттәшләре җыенында Саратов өлкәсе татар милли-мәдәни мохтарияте рәисе, Татарстан Республикасының Саратовтагы сәүдә вәкиле, эре эшкуар **Камил Әбләзов**, татарның изге җирләре бер Болгар гына түгел, кимендә 150 шәһәр урыны билгеле; ел саен берсен торгыза алмасак та, һич югы аларны тамгалап, монда элек – Алтын Урда заманында татар шәһәре торган, дип билгеләп куярга кирәк; мондый хәл башка халыклар арасында татарны танытуда мөһим чара булыр, шул ук вакытта милләттәшләребез өчен горурлык чыганагына да әвереләчәк, дип чыгыш ясаган иде.

ИСЕМ ХИКМӘТЛӘРЕ

Тубыл шәһәре янындагы Искер — Себер ханлыгының башкаласы шулай ук Алтын Урданың бер үзәге булган. Төмән өлкәсендәге **«Мирас»** төбәк иҗтимагый татар оешмасы советы рәисе **Луиза Шәмсетдинова** да: *«Себер татарларының милли горурлыгын тергезү өчен Искер шәһәрлеген торгызу зарур»*, — дип исәпли. Хәер, берничә ел элек алар бу эшкә керештe дә инде. *«Бу зур эшкә ничек алынырга булдыгыз? Искернең изге җир икәнен ничә яшегездә ишеттегез?»* — дип, мин аңа берничә сорау белән мөрәҗәгать иттем.

Багай районының Күбәк авылында туып үстем мин. Бабамның алты баласы да мәктәп директоры булган. Авылда, төп нигездә бер әнием торып калган. Шул Рәшит бабам үләр алдыннан, ул вакытта миңа җиде яшь иде, кулыма бер бакыр акча салды. *«Әлеге акча иске йирнеке. Шул йирне табу, торгызу белән шөгыльләнерсең. Бүген олы көн — онытма! Кызың туар. Син борынгылыкны өйрәнерсең. Бу акчаны югалтма. Мин инде үләм»*, — диде. Кызганыч, ул акчаны югалттым. Аны 26 октябрь көнне җирләгән идек. 26 октябрь көнне кызым туды. Шунда бабамның васыятен искә төшердем. Ничектер шулай килеп чыкты: Искерне искә алып, 2004 нче елның 26 нчы октябрендә беренче мәртәбә Хәтер көне үткәрдек. 2000 нче елдан башлап кызымның туган, бабамның үлгән көненә туры китереп Хәтем ашы үткәрә идем. 2000 нче елда туган авылымдагы яңа урамда йорт сала башладык. Шул көнне төшемдә **Күчем хан** белән **Ермакны** күрдем. Шул урамга Күчем хан исеме бирдек. 2004 нче елда, бу урамга Күчем хан исеме бирелде, дигән язу элеп куйгач, безгә Тубылдан казаклар килеп җитте. Башта авылдашларым, кайдан таптың ул исемне, дип көлделәр, аңламадылар.

> «Себер татарларының милли горурлыгын тергезү өчен Искер шәһәрлеген торгызу зарур»

Югыйсә, авыл җирлеге башлыгы да, район башлыгы да — татар. Алар да килеп, алып ташла моны, дип үгетләп йөрде. Риваятьләр буенча, авылыбыз каршында Күчем хан яугирләре белән аны сагалап торып суга батырып үтергән. Килгән казаклар, монда Ермак баткан, шуны искә алып бирергә тәре баганасы утыртып куябыз, дигән иде. Шунда авылдашларым, хәлемә кереп, тәре баганасын утыртып куярга ирек бирмәделәр. Әле берничә ел дәвамында хакимиятләр, теләгебезгә каршы килеп, әүвәл Ермак исеме кушыйк, тора-бара берәр яңа урамга Күчем хан исеме бирербез, дип җавап бирде. Ризалашмагач, Придорожный, Береговой, Центральный урамының дәвамы дигән исемнәр тәкъдим итте. Сайлау вакытында район башлыгына, теләгебезне үтәмәсәң, сайламыйбыз, дип шарт куйдык. Өч татар авылы халкының уртак карарына каршы килә алмыйча, ул тыныч кына Күчем ханы исеме бирелүен раслап куйды.

ҺАМАН РӘСМИ ТЫЮЧЫ ЮК

— Мәктәптә укыган вакытта Искер хакында сөйләүче булмадымы?

— Без Татар-Багай мәктәбендә укып, Күбәктә яшәп, Тубылда училище, техникум, институт бетергән вакытта Себер ханлыгының башкаласы Искернең яныннан узып йөргәнбез икән — белмәдек. Туган як тарихын мәктәптә укытмадылар. Онытылсын диптер инде, Искернең бер ягында, бер чакрымда чиркәү салып куйганнар, шунда Преображенка дигән авыл корганнар, икенче ягында, биш чакрымда Абалаково дигән хатын-кызлар монастыре салганнар. Инде бирегә татарлар кайтмас, дип шул тирәдә кабер казып

мәетләрен күмә башлаганнар. Югыйсә, Искер янында гына ханнарыбызның каберләре бар. Риваятьләр буенча, анда җиде ханыбыз күмелгән.

— Әле былтыр да, Тубылдан алып килеп, православлар Искер җирендә үз кешеләрен җирли иде. Бу хәл һаман дәвам итәме?

— Без хәзер анда алып баручы капкаларны яптык инде. Прокуратура аша да тыйдырмакчы булабыз. Су буйларын саклау законын бозу булып та чыга бу. Анда болай да **Зәнки бабаның** ике оныгы ята. Шәехләр җирләнгән. Җирле археологыбыз **Ришат Рәхимов** шактый гына каберләрне, астаналарны (төрбәләрне) ачыклап-барлап паспортлаштыруда күп тырышты. Тарихи документлар буенча эзләнә торгач, шушы Искер тирәлегендә булган өч каберне ачыклауга ирештек. Әмма дә шулар янына Тубылдан, Абалак монастыреннан мәетләрен күмә башлаганнар иде. Табигый, монда яңа каберләр булырга тиеш түгел. Инде бу тирәне койма белән әйләндереп алдык. Чөнки рәсми органнар тарафыннан әле дә, күмү тыела, дигән карар чыгарылмады.

Бу җирне үзебезгә беркетү өчен тугыз ел көрәшергә туры килде. Биредә изге кешеләр күмелгәнен күрсәтү өчен, сигез почмаклы чардуган — истәлек билгесе ясатып, өскә ярымай билгесе куйдык. Аны тугыз ел буе мәсхәрәләп, бозып-ватып мәш килделәр. Без аны алыштырып тордык. Кулларыннан тоткан чаклар булса да, эшне судка җиткерә алмаган идек. Ниһаять, судка җиткердек. Биредәге җәнлек совхозы директоры үзе безгә каршы митинглар оештырды. Бу хакта прокуратурага язсам да, һаман күз йомып килделәр...

Ике тапкыр геодезия тикшеренүләре үткәртергә туры килде. Арендага алу турында рөхсәт кәгазьләрен алганчы вакыт уза, каршы торучылар куәтле. 2007 нче елда, өч ел тартышканнан соң гына, безгә бу җирне арендага бирделәр. Моңа хәтле 47 комиссия аша узарга туры килде. Татарстанга, **Минтимер Шәймиевкә** рәхмәт: геология-геодезия эшләренә 3,5 миллион сум акча күчерделәр. Шунда Искер тыюлыгына база төзеп калдык. Безгә Казан «Компрессормаш» предприятиесе нык булышты.

Менә җиде ел инде Искер җыены уздырабыз. Күрше-тирә республика-өлкәләрдән кунаклар килә башлады. Искергә кайттык, дип әйтергә була

Луиза Шәмсетдинова һәм Дамир Ибраһимов. 2015 ел

инде хәзер. Күчем ханның хатыны **Сүзге** ханымның исемен мәңгеләштерү буенча да эш башланды. Моның өчен Тубылның үзендә 70 сутый җир кишәрлеге алдык. Дөрес, әле ул тулысынча рәсмиләштерелмәгән.

— Менә бервакыт ярдәм итүче калмады…

— Шунда мин Искер тыюлыгының проекты төшерелгән баннер ясатып, төзергә кирәк, дип яздырдым да, юл буена куйдырдым. Аска кечкенә итеп телефон номерымны сырладым. Утырып дога кылдым…

БЕР БУЛСЫН, БЕРӘГӘЙЛЕ БУЛСЫН

Шушы вакытта әңгәмәгә эшкуар, Башкортстанда туып үсеп хәзер Төмәндә яшәүче **Дамир Ибраһимов** кушылды. Олы юлдан узып барганда әлеге баннерга, язуга игътибар итә ул.

— Мин сәүдә белән шөгыльләнәм. Тубылда кибетем бар. Төмәннән ике атнага бер килеп сәүдә эшенең барышы белән кызыксынам. Товар китерәм. Еш кына үзем «Газель»гә төйим дә алып киләм. Зур кибет түгел. Шулай туры килде: юлда туктап чәй эчеп алыйм әле, дидем. Ике-өч ел элек тә **«Искер җыены»** дигән сүз күземә чалынганы бар иде. Әмма анда башка мәгълүмат юк, Искернең кайда икәнен дә белмим. Үзем Башкортстан кешесе мин. Телефон номерын җыйдым да шалтыраттым, Сезгә нинди ярдәм кирәк, дип сорадым. Ул вакытта ашыга идем. Бер атнадан соң килдем, очраштык. Луиза, мәчет түбәсен ябарга калай кирәк, диде. Барып карасам — бер бура гына тора. Бригада яллагыз, монда эш күп әле, кулдан килгәнчә булышырмын, дидем. Эшли башладык. Искер җыенына түбәсен яба алдык. 2013 нче елның җәе бу. Төзи башлагач, якын-тирәдән усал адәмнәр килеп йөри башлады. Мәчет салмагыз, яндырабыз, дип куркыта болар. Яндырырга да мөмкиннәр иде. Без инде ике катлы, ике манаралы, проекты расланган таш мәчет төзетергә булдык. Проекты гына 800 мең сумга төште. Күпме генә басым булса да, рәхмәт яугыры, **Виктор Кашко** исем-фамилияле Тубыл архитекторы проектыбызны раслап кулын куйды (ул 10 ай гына эшләп калды, безгә рөхсәт биргәне өчен аны эшеннән алдылар, мөһер салмасын дип,

Шул Рәшит бабам үләр алдыннан, ул вакытта миңа җиде яшь иде, кулыма бер бакыр акча салды. «Әлеге акча иске йирнеке. Шул йирне табу, торгызу белән шөгыльләнерсең. Бүген олы көн – онытма! Кызың туар. Син борынгылыкны өйрәнерсең. Бу акчаны югалтма. Мин инде үләм», – диде.

31 нче декабрь көнне аны кабинетына кертмәделәр; имзасы бар иде, урынбасары кабинетына кереп, шунда мөһер сукты; берничә көннән мин Викторны урамда очраттым. «Нигә ризалык бирергә диеп күңелем тартыла дисәм, үзем дә татар икәнмен, чын фамилиям **Моратов** икән бит», — дип әйтте ул миңа, дип өсти шунда Луиза ханым). Проектка ризалык алгачтын, 50 мең данә кирпеч алып куйдык. Быелтыр яздан башлап нигезен казып, фундамент ясап, бинаның аскы катын өч метр өскә чыгарып куйдык. Хәзер анда каравылчы бар. Башта янәшәдәге урыс авылыннан каравылчы алган идек, татарларга яллангдыгызмыни, дип авылдашлары эшләргә ирек бирмәде.

Аллаһ боерса, 2015 нче елда план буенча мәчетнең беренче катын салу, 2016 нчы елда тулаем төзеп бетерү күздә тотыла.

ЯРТЫЛАШ КИМЕТКӘННӘР

— Луиза ханым, Искер тыюлыгы өчен гектар ярым җир аз түгелме? Башкала биләмәсе шактый зур булгандыр бит?

— Безгә башта өч гектар җир бирәбез, дигәннәр иде. Аннан соң яртысын гына бирергә булдылар. Башта, эшне башлаганда, бирегә Искерне карарга Мәскәүдән монахлар да килеп йөрде. Янәшәдә, теге гектар ярым җирдә монастырь салу ниятләре дә булган икән. Бәлкем хәзер дә бу ниятләреннән кире кайтмаганнардыр — безгә мәгълүм түгел. Төмән өлкәсе администрациясенең милләтләр эшләре комитеты рәисе **Евгений Воробьёв**: *«Шулхәтле биек, ике катлы, ике манаралы мәчет сезгә нәрсәгә кирәк?»* — дип сорады миннән. *«Бу — символ. Бер манарасы — Искернең булганлыгына ишарә, икенче манарасы — аның хәзер дә исән икәнлеге билгесе. Бу мәһабәт мәчет киләчәкне уйлап төзелә»*, — дип җавап бирдем.

Сакланып калган документлар буенча, басып алучылар килгәндә Искердә 32800 кеше булган, шартлатуҗәзалаулардан соң, шуларның ике меңе генә исән калган. Кечкенә балаларны бәкегә чумдырып чукындырганнар. Күчем хан акыллы булган: баскынчыларны Искергә кертеп, аннан чыгармыйча, ике ел тотып, үч алган. Күбесе шунда үлемен тапкан. Фәкать биш дистә кешесе белән аннан чыга алган Ермакны, авылыбыз янында куып җитеп, Иртышка батырып үтергән. Юкка гына аңардан легенда ясап маташалар. Без — себер татарлары — казаклар, дигән сүзне кабул итә алмыйбыз. Мондый сүз-атамаларны сак куллансыннар иде. Бәлкем кайсыдыр төбәкләр өчен казаклар булу табигыйдер. Бездә бу сүз үгезгә кызыл чүпрәк күрсәткән кебек кабул ителә. Ул фаҗигале вакыйгаларга 400 ел үткән бит инде, диләр. 400 ел түгел, мең ел үтсә дә, әлеге яра һаман сызлап тора. Без тарихыбызны, татарлыгыбызны, ислам динендә икәнлегебезне оныта алмыйбыз. Искер тыюлыгы үзебез күзаллаганча төзелеп бетсә, туган җиребездә горур йөри алачакбыз. Без беркая да китмәдек. Шушы җирдә яшәп калдык, исән калган кечкенә нәселдән кабат күтәрелдек. Ермак отрядын эзәрлекләп барганда унсигез яшьлек мәргән егет аның күзенә тидергән. Патша гаскәриләреннән бу егетне эзләтеп таптырган бит. Шул вакыттан бу нәселгә **Мәргәнов** фамилиясе ябышып калган. Мәргәновлар нәселе бүген дә исән. Шушы Искердән

унике генә чакрым җирдә яшиләр. Әлеге тарихны аларга сөйләгән идем, өченче Искер җыенын уздыру чыгымнарын тулысынча үз өсләренә алдылар. Кеше туган ягы тарихын белсен өчен, мәктәптә әлеге фәнне укытырга кирәк.

Күчем ханның кем икәнен күпләр белми иде. **Фәүзия апа Бәйрәмова** килеп, 2005-2007 нче елларда архивларда утырып, авыллардагы риваятьләрне җыеп, Күчем хан турында китап язды. 2007 нче елда Күбәктә Хәтем ашы уздырганда без әлеге китапны бушлай тараттык. Шуның нәтиҗәсендә 2008 нче елда Искер җыенына бик күп кеше килде. Мәктәпләргә йөреп, Хәтем ашлары, Искер җыеннары үткәреп аңлата торгач, халкыбызның күзе ачылды, тарихи хәтере уянды. Әгәр тиз генә Искерне төзеп куйсак, халык төшенми калыр иде. Максатыбызга шушылай озак килүнең дә бәрәкәте, хикмәте бар, күрәсең. Эшкуарларның керткән өлеше дә бәяләп бетергесез. Бөтендөнья татар конгрессы да тарихи дөреслекне торгызуга зур өлеш кертә.

Без биредә хан йорты, мәчет янында шәехләр өчен төрбә-астана, музей, Күчем ханга, Сөзге ханымга истәлек билгесе, өч кунак өе, чәйханә булыр, дип торабыз. Ун ел элек барча ниятебезгә риза булсалар да, хәзер, төзелеш эшләре башлангач, мәчет кечкенә булсын, чәйханә, хан йорты салырга ярамый, Искер җыены үткәрмисез, дип каршы төшеп маташалар.

Искерне популярлаштыру өчен, Искер җыены уздыра башладык та инде без. Башта бит күпләр борынгы башкалабызның кайда икәнлеген дә белми иде. Бу беренче казанышыбыз булды. Элек монда электр баганалары булмагач, дизель ягулыгы белән эшли торган электр станциясен кулланырга туры килә иде. Шактый гына зур акча чыгарып, Дамир әфәнде Искергә электр чыбыклары суздырды. Анысы да — зур казаныш. Быел **«Мирас»** оешмабызның оешуына ун ел тула. Шунысы да бар: моңарчы хакимиятләр Искер җыенына кеше аз килсен, дип Сабантуйны шул көнгә туры китерергә тырыша иде. Ике ел моңа ирештеләр дә. Шуның өчен дә быел VIII халыкара Искер җыен-фестивален һәм «Мирас» оешмасының унеллыгын август аенда билгеләп үтәргә булдык. Әлегә, берни үзгәрмәсә, аны 7-9нчы августта оештырырбыз, дип торабыз. Әлеге җыен алдыннан ел да Искерне өйрәнүгә ба-

Искер тарихына багышланган гыйльми-гамәли җыенда катнашучылардан бер төркем. 2014 ел

гышланган Бөтенрусия гыйлми-гамәли конференциясе дә уздырабыз. Конференция материалларын бастырып чыгару үзе үк безгә Искерне тарихи татар җире итеп беркетүгә, анда христиан каберлеге ясатмауга нигез, дәлил бирә. Бу гыйльми җыелышның да, Искер җыенының да 425 ел көткән тарихи ядкярләребезне саклау-барлау, торгызуда зур өлеше бар.

БӘҺАСЕЗ ТАБЫЛДЫК

Без музейлаштыру эшен дә алып барабыз. Халыктан борынгы чорларның, узмышыбызның матди чагылышы булган, Искер заманына караган корал-җиһазларны сатып алабыз. Хан йортының бер бүлмәсенә урнаштырылачак болар. Күптән түгел генә безгә бер казан китереп бирделәр. Аны китереп биргән урыс бабае җитмешенче елларда туган авылым Күбәктә, Күчем хан урамының очында, козыклыкта, козык суккан чакта, гади генә әйткәндә, эрбет күркәсе, чикләвеге җыйган вакытта куш эрбет төбендә тимер әйбергә тап була. Дүрт йөзьеллык эрбет төбендә хәзинә күмелгән ахры, дип фаразлыйлар башта. Ике кеше дә колачлый алмый бу агачны. Шул казанның астында кабер бар икән. Мумияләнгән кеше ята. Утыртып күмелгән. Башы, гәүдәсе аерым. Сугышта һәлак булган ир-ат бу. Минемчә, ул йә Күчем хан үзе яки аның бер туганы, нәселе-заты. Яхшылап сагызлап куйганнар, казан белән каплаганнар, казан астына бронза саплы кылыч куйганнар. Кылыч сабына гарәп хәрефләре белән татарча язылган булган. Әлеге кылычны музейга тапшырганнар, казанны үзләрендә калдырганнар, мәеткә тияргә курыкканнар, кире ябып куйганнар. Күчем хан Ермакны батырып үтергәннән соң да, кире кайтып, әле 20-30 ел бу тирәләрдә сугышып йөргән. Ул бит соңгы сулышынача сугышчы булган, коралын ташламаган, картаеп үлгән. Күрәсең, соңгы теләге, васыяте Искергә кайту булгандыр. Шуңа күрә дә аны Күбәккә кадәр кайтарып җиткергәннәрдер, дип уйлыйм мин.

Бу тирәдә — Кондан, Хуҗалан, Тузы авылларында хәзер дә татарлар яши. Искер безнең Күбәк авылыннан егерме генә чакрым ераклыкта. Башкала җимерелгән, Тубылда чиркәүләр төзелеп ята. Тора-бара татарлар аңламый калмас әле, дип, мумияләп, казаны белән каплап, җирләп калдырганнардыр, дип фаразлыйм. Хәзер рөхсәт алып кабат казып карарга иде, дип йөрим. Ул бабай да, кылычны музейга кабул итеп алган кеше дә исән. Әмма, ни кызганыч, без ул кылычны таба алмадык. Күрәсең, вакыты җитте. Күчем хан без төзеп яткан төрбәгә килеп ятарга тиештер шәт. Бүген бик тырышып Ермакның мәетен эзлиләр. Бу эшкә бик күп акча сарыф итәләр. Аны эзләп тапканчы, безгә әлеге затны — Күчем ханмы, шәехме, бер сугышчымы ул — шул төрбәгә урнаштырып куярга кирәк. Һичкемгә бирмичә, лаеклы рәвештә без аны шул җирдә җирләргә тиеш. Башкалар мыскыл итеп, вәйран кылып китмәсен өчен, мин әлегә аның урынын күрсәтә алмыйм.

Биредә шуны да әйтмичә кала алмыйм: бердәмлек җитми. Тәгаен алганда, бездә Себер татарлары конгрессы дигән оешма бар. Андагылар хисап биргәндә Искерне телгә алырга яратса да, Искерне танылсылары, күтәрәселәре, булышасылары килми. Конгресс җитәкчеләренең берсе булган **Насыйров** бер мәртәбә килсә, **Саттаровның** гомумән бирегә аяк басканы юк. Булышмасалар да, һич югы Казанда, җыен вакытында, олуг мөнбәрдә чыгыш ясау мөмкинлеге бирелгәч, Тубылда олы ниятебезне тормышка ашырып киләбез, әйдәгез, Искерне бергәләп күтәрик, «Мирас» оешмабызның унъеллыгына килми калмагыз, дип белдерергә була иде. Ни кызганыч, андый сүз чыкмады. Киресенчә, «Мирас»ны Конгрессның бер филиалына гына әйләндереп калдырмакчылар. Бергәләп эшләгәндә казанышларыбыз зуррак булыр иде ләбаса.

Әбләзов әйткәнчә, хәзер татарның

Тубылдагы туган якны өйрәнү музеендагы себер татарларының тарихына кагылышлы экспонатлар

тарихи ядкярләрен билгеләп кенә калмыйча, анда биналар торгызырга, халык килеп, күреп, горурланып йөри торган урынга әйләндерергә кирәк. Әнә, Кырым ханлыгы. Бакчасарайда ханнар күмелгән урын яхшы мәгълүм. Казан ханлыгында да хан сөякләре яткан изге җирләр, барча халык күрерлек итеп, билгеләп куелды. Без дә Себер ханлыгының изге урыннарын билгеләп кую максатында ниятләгән эшләребезнең утыз процентын эшләдек, дип әйтергә мөмкин. Хәзер менә Әстерхан ханлыгы кала. Казанда уздырылган җыен вакытында мин әстерханлыларга, бөтенебез җыелып килеп андагы изге җирләребезне билгеләп куйыйк, дип тәкъдим иттем. Аның да вакыты җитте. Әстерхан ханлыгын торгызу түгел бит бу. Этнотуризм, бабайларның изге җирләре, балаларыбыз, оныкларыбыз тарихыбызны белергә тиеш, дип яхшылап аңлатсаң, хакимиятләр каршы килә алмаячак. Билгеле, бу эшне җирле татар иҗтимагый оешмалары үзләре башлап йөрергә тиеш. Без барып ярдәм генә итә алабыз. ■

ПӘРИ – БАШКА, ҖЕН – БАШКА...

Рифә Рахман

Рухи бәһасен үлчәү тәлинкәләренә генә салып булмый торган милли бәйрәмнәребез көннән-көн үз кыйммәтен югалта бара. Республикакүләм уздырылуы туктатылган, исеме әллә нигә бер яңгыраган Нәүрүз, «булып торуы да яхшы» дигән ният яисә «башкаларга күрсәтерлегебез бар» дигән мактаныч хисе белән генә оештырылган Сабан туе, атамасы да актив сөйләмнән төшеп калган Җыен... Инде вак-төяк йолалар турында әйтеп торасы да юк.

Минзәлә районының Бикбул авылында сөлге җыялар. 1977 ел

Милли бәйрәмнәрнең татар тормышыннан юкка чыгуында сәбәпләр күп: халык психологиясендә заманга бәйле үзгәрешләр, авыл халкының кимүе, шәһәрләшүе, урыслашуы, хөкүмәт тарафыннан урыс бәйрәмнәренә өстенлек бирелү һ.б. Төптәрәк яткан сәбәпләр дә бар. Шуларның берсе — милли бәйрәмнәрне рәсмиләштерү, аларны зур горурлык хисе белән «интернациональ» дип атап тору. Үзенеке булмаган бәйрәмгә ни яшьләрнең, ни өлкәннәрнең актив катнашмавына, концертка барган кебек баруына йә бөтенләй исе китмәвенә гаҗәпләнергә кирәкми. Уртак малны эт җыймас, дигән кебек, уртак бәйрәмнәрнең дә кадере шуның кадәр генә. Теләсә кайсы туйның хуҗасы һәм кунагы булырга тиешлеген оныттык.

Узган гасыр ахырында ук мәгънәсен югалта башлаган Сабан туена карата күрше милләтләрдә ямьсез әйтемнәр барлыкка килү дә аптыратмый: «Нам татарам всё равно, что война, что сабантуй», — ди урыслар (безнең исемнән!). Бу мәкаль — милләтебезнең үз тарихына, йолаларына битарафлыгын ассызыклау. Шул ук вакытта, милли рухы тапталган бәйрәмнәргә искитмәгән мөнәсәбәттә торуы өчен һичкемне гаепләп тә булмый.

Шагыйрь шигыренә җанын куша, шуңа күрә еш кына аңа каршы иҗат ителгән пародияне күтәрә алмый. Бәйрәмнәр белән дә эш шулайрак. Югарыда аталган милли чараларның пародиягә әверелүе (ягъни, бер булганны уңышсыз, көлке дәрәҗәдә яңадан кабатлау) аларны уздыруга «рәсми куллар» тыгылгач башланды, дип кистереп әйтергә мөмкин. Вакыты, рәвеше, урыны халык, аксакаллар тарафыннан киңәшләшеп ачыкланырга тиешле, ел фасыллары, эш һәм көн итү тәртибенә бәйле, ныклы традицияләргә нигезләнгән Сабан туе инде хәтта безнең буын белгән Сабан туе да түгел. Авылларда, мыек астыннан сагышлы көлеп, аны «җитәкчеләр бәйрәме» (төп ял итүчеләр шулар) дип тә атыйлар, акча эшләр өчен көтеп торуларын исәпкә алып, артистларның «уңыш бәйрәме» дип санаучылар да очрый, әмма горурланып: «Сабан туенда булдым, нәкъ безнең яшьлектәгечә», — дип сөйләүчеләр күренми.

Пәри башка, җен башка, ди халык, төрле әйберләрне аера алмаучылардан көлеп. Инкыйлабтан соң махсус рәвештә тыелган Җыен белән аның урынын алмаштырган Сабан туе турында да шуны ук әйтергә булыр иде. Замандашларыбыз хәтерли торгандыр: кыр эшләре башланыр алдыннан уздырылган Сабан туе, халык теләген исәпкә дә алып тормыйча, җәйгә күчерелгәч, Җыен гомумән юкка чыгарылгач, мондый үзгәрешләрне кабул итә алмаган күпчелек, вакыты һәм эчтәлеге өлешчә туры килгәнне дә күздә тотып, бәйрәмне Җыен дип йөртте. Белдерүләргә башта төрлечәрәк, аннан, нигездә, «Сабан туе» дип язылды.

Җыен — борынгыга барып тоташкан һәм барлык төрки халыкларда да булган милли җыелыш. Зур авыллар үзләре генә, вак авыллар берләшеп уздырган аны. Сабан туе — үләннәр тишелгәч, мал-туарны болыннарга чыгаргач, чәчү алдыннан, май аенда, ә Җыен — чәчү беткәч, иң матур көннәрдә, чәчәкле тугай-болыннарда үткән. «Җир җылынгач, Җыен җыела» мәкале дә шул хакта сөйли.

Фото автор архивыннан

«Мин – көрәшчеләр нәселеннән. Капчык сугышында батыр калган чакларым да еш булды». Мәмәшир авылы урта мәктәбе Сабан туе, 1977 елның 19 мае

Җыенның кабилә, токым, ыру бәйрәме булганлыгын анық берләшеп уздырылуы, бер авылдан күчеп киткән кешеләрнең шул көндә туган авылларына кайтуы, зимагурларның җыелуы һ.б. да сөйли. Моны без кечкенә чакта үткәрелгән бәйрәмнәр дә ачык күрсәтеп торды. Җыенның вакыты авыллардан бүленгән, күченгән пүчинкәләр белән киңәшләшеп билгеләнә иде, чөнки бәйрәм атна-ун көн буе бара, туганнар әле бер авылга, әле икенчесенә җыела, көннәрнең туры килмәве кирәк.

Безнең Кукмарадан Киров өлкәсенә күчеп утырган Күкшел Пүчинкәсе, Мәмәшир Пүчинкәсе, халык телендә шулай аталышлы, әмма рәсми исеме дә булган башка авылларга атналар буе йөри торган идек, ә бәйрәмнең олырагы, дәрәҗәлерәге Малмыж, Нократ Аланы кебек зур торак пунктларында уздырыла, алары да бер көнгә туры

Фото автор архивыннан

«Ренат абыем – Сабан туе батыры». 1980 нче еллар

килми иде (шулай да, июньнең соңгы атнасы хуп күрелде). Халык Җыенның соңгысын — елның иң озын көненә туры килгәнен аеруча көтеп алган. Безнең вакытта «Олы көн җыены»на бистә-шәһәрләргә яисә зур авылларга, тарихи яктан данлыклы торак пунктларга бармау да гаеп тоела, аларда яшәгән туган-тумачаның хәтерен калдырганга, бик зур сәбәп чыкканда гына, кунактан баш тартыла иде. Мәмәшир халкы өчен бу төр җыен, минем аңлавымча, Кукмарадан битәр, Киров өлкәсенең Малмыж шәһәрендә булгандыр. Хатирәләремдә Малмыж өяз җыенын уздырган кала сыйфатында яши.

Балачакның хәтта эшле көне дә — бәйрәм, бәйрәмле көне аеруча нурлы, җылы. Үзеңне кирәкле, кадерле тоясың, зур бер нәселнең баласыдай хис итәсең. Җыен өчен авыллардан атлар,

Виртуоз-гармунчы. Арча районының Кырлай авылы. 1988 ел

машиналар билгеләнә, кунакларны каршы алу оештырыла. Бер авылга җыелу ике-өч көн дәвам итә, хуҗалар үзара сораша: кемнәргә кемнәр кайткан, кемнәр килгән? Теге яки бу авылга кергәндә, басу капкасы янындагылар яисә урамда каршы чыгучылар, безнекеләр кайсы автобус белән, кайсы пароходта, паромда икән... дип йөдәтеп бетерә. Җыен-Сабан туенда кунак төшмәгән өй мәет кергән йорт кебек күңелсез, нурсыз тоела.

Җыеннарның тарихы нәсел-токымнарның үсеш-таралыш тарихына барып тоташа. Ул туганлык җепләрен сакларга ярдәм итә. Хәтта Сабан туе белән берләшкән вариантта да аның күп җирдә уздырылмавы, вакытын махсус рәвештә бер көнгә куеп, бәйрәмне үлемгә дучар итү — кабилә-ыруның гына түгел, ә тулаем халыкның юкка чыгуына алып бара торган юл. Моны хәйләкәр сәясәт чагылышы дими, ни дисең?!

Җәй уртасында уздырылган туйларның Сабан бәйрәме белән бернинди уртаклыгы юк. Быел башкалабызныкы августта үтә икән, диләр. Читләр алдында матур күренүне уйлап, үз халкыңның җанына төкерү, дип кенә бәяләп буладыр моны. Кызым янәшәбездәге Каюм Насыйри урамында ял итеп утыра икән. Бер төркем туристлар килгән. Арадан берсе гидтан: «Сабан туегыз кайчан була?» — дип сораган. Сәяхәт юламаны: «Ул мөселманнарның Корбан бәйрәме кебек гел күчеп йөри, быел августка күчкән бугай», — димәсенме! Ләкин... бу төр наданлыкны да аңлатырга мөмкин. Кышкы Сабан туйлары бар икән, димәк, әлеге бәйрәмнең кыр эшләре белән бернинди уртаклыгы калмаган? Милиция (әй лә, полиция) дә бәйрәм итә аны, артистлар да...

Кайсы урысның Яфрак бәйрәмен кышкы зәмһәрирдә уздыру башына килсен?! Алар ул көнне клуб идәннәрен дер селкетеп, тибенә-тибенә бииләр. Бар нәрсә элеккечә, бар нәрсә ихластан, сөйләшү — урысча, Татарстанда яшибез дип, бәйрәмне татарча уздырмыйлар. Ә без менә... Югыйсә, туган авылыма урыс, мари көрәшчеләре дә килә иде, аларны беркем дә мәйдан уртасына урысча чакырырга уйлап карамаган.

Сабан туйларының бер гадәте: бүләкне читкә җибәрмәү. Инде отты-отты дигәндә дә, башка авылныкыларны җиңәр өчен, кулына сөлге урап, уртага атылучы табылачак. Хәзер көрәш кагыйдәләре үзгәрде. Бер-ике ирне атып бәрәләр дә, батырлар ярышына чыгалар. Элек исә батыр калганны җиңүчеләр дә табыла, шундыйлар табылмаганда гына, ул абсолют җиңүче санала иде. Мин — көрәшчеләр нәселеннән. Нәкыйп белән Наил абыйлар, Рәфкать, Ринат һәм башкалар — һичкемгә бил бирмәгән туганнарым.

Балалар Сабан туен гаепкә алмыйм, ямьсез җирләрен тапмыйм. Бердән, язын үткәрелә, икенчедән, ихластан. Аларда активлык күзәтелә, аларга бүләкне авылдашларым кызганмыйча мулдан бирә. Чын Сабан туйлары юкка чыккач уздырыла башлаган бәйрәм ул. Кайчандыр югарыдагылар каршы төшмәсен өчен, аны да унтугызынчы майга туры китерергә тырышалар һәм Пионерия көне белән бәйлиләр иде. Балалар Сабан туеның бу ямьсез ягыннан котылдык. Ул чын мәгънәсендә хезмәт, дуслык, үзара бил алышу бәйрәменә әверелде, шунлыктан авыл мәктәпләрендә һаман да популярлыгын югалтмый.

Татарларда зиратка йөрү, урыслардагы кебек, дини бәйрәмнәр

Арча районының Наласа авылы Сабан туе. 1974 ел

яисә көннәр белән билгеләнми. Элек Җыенга кайтучылар каберлекләрне тәртипкә китергән. Мазарстаннарны чистарту соңрак май бәйрәмнәренә күчте, әмма элеккеге колачлылыгын югалтты. Кешеләр үз туганнарының каберен карыйлар да китеп баралар, калган каберлекләрне тазарту, корыган агачларны кисүваклау, читкә чыгару күп җирдә, нигездә, карт-корыдан торган авыл халкы, аны бу эшкә оештырган җирле идарә өстенә төшә. Җыеннарның юкка чыгуы каралмаган зиратлар проблемасын да барлыкка китерде.

Сәгать унда башланучан бәйрәм элекке кичке уенлыклар вакытына күчә бара. Күп кенә авылларда Төнге Сабан туйлары уздыру модага керде. Нинди монда үзара хәл белешү, ашъяулыклы табыннар артында гөрләшеп утыру! Авылдан баганага сузылган караңгы ут яктысында күзләр генә ялтырый.

Аграр культ белән бәйле Сабан туе — бөртеклеләр игүгә

мөнәсәбәтле тантана. Ибн Фадлан истәлекләренә дә кергән ул. Казан депутатлары тарафыннан ЮНЕСКОның дөнья шедеврлары исемлегенә тәкъдим ителсә дә, аның тарихи, сәнгати һәм этнологик кыймәте көннән-көн кими, һәм, беренче чиратта, җаваплылык шушы күренешкә күз йомган татар җәмәгатьчелеге, зыялылары өстенә төшә, дип әйтергә мөмкин. Идарәчеләрнең дә күзен ачучылар кирәк! Кар эрегәннән соң язгы эшләргә ике-өч атна кала уздырылган бу бәйрәмнең фәнни хезмәтләрдә берничә вариантлары күрсәтелә, асылда аларның һәрберсен зур бер бәйрәмнең төрле җирләрдә төрле дәрәҗәдә сакланып калган өлешләре, дип уйларга кирәк.

Әгәр теге яки бу күренешнең атрибутлары яшәүдән туктый икән, ул инде чын мәгънәсендә шул күренеш була аламы? Юк. Сабан туе белән дә эш шулайрак тора. Совет чоры да тамырдан үзгәртеп бетерә алмаган Сабан туе, үзгәртеп кору елларына кергәч, бөтен матурлыгын, тарту көчен югалтты. Кайбер урыннарда ул элеккечә балалар көрәшеннән, картлар ярышларыннан, төрле шаярышлардан башланмый, анда вак кына бер бәйге, монда икенчесе... Көрәшчеләр саны да артык күп түгел, аларны да еш кына уртага ялына-ялына тарталар. Бүләге түгел, мәзәге дип, кызык ясап кына көрәшкә атылулар заманнары узды. Киресенчә, күпләр бары тик бүләк, машина яисә башкасы өчен бил алыша. Әле кайчан гына чиккән сөлгеләре белән дәшеп торган мәйдан да элеккечә кайнамый, бәхәсләшми, даулашмый. Борынгы ышанычларга нигезләнгән йолаларны ислам ритуаллары белән дә кушмаска иде. Мин, шәхсән, икенче Бөтенрусия авыл Сабан туенда мөфти Тәлгать Таҗетдиннең бәйге-тантананы дини бәйрәм санарга тәкъдим итүен, Җәбраил фәрештәнең кешеләрне бодай чәчәргә өйрәтүе белән бәйләп каравын аның башка ахмак гамәлләре янәшәсендә хак динебезгә салган чираттагы зыяны, дип санадым.

Рәсми аңлатмаларда бәйрәмнән беркем дә бүләксез китми, дип языла. Бу дөрес түгел, элек бүләкне җиңүчеләр ала иде. Әмма җиңелгән атлар да һичкайчан бүләксез калдырылмады, чөнки халыкта арттан килгән атның җаны елый, кимсенә, дигән ышану булды. Сабыйларны да бүләксез калдырмаска тырыштылар. Хәзер бүләкләр уңга да, сулга да болай гына таратыла. Шуңа күрә аларның кадере дә юк.

Сабан туена совет чорында кертелгән үзгәрешләр дә бәйрәмнең тарихи эчтәлегенә, мәгънәсенә зыян сала: спортчылар парады, сәнгать коллективлары чыгышы, авыл хуҗалыгы алдынгыларын бүләкләү... Шул ук вакытта, яшь киленнәр чиккән сөлгеләр, кызлар хәзерләгән кулъяулыклар өчен ярышу кебек гүзәл гореф-гадәтләр юкка чыга бара. Җиңүчеләрне милли сөлге һәм симез тәкә белән бүләкләүләр дә тарих тузанына күмелер сыман. Оештыручыларның аларны кадерсезләве, символик мәгънәгә ия булуларын онытулары халыкта милли бәйрәмнәргә карата гариплändерелгән мөнәсәбәт барлыкка китерде.

Милли бәйрәмнәребез турында яза башласаң, кәгазь битләре генә җитми икән. Бу — әлегә сүземнең башы гына булсын. Мин аны кайчан да бер дәвам итәрмен әле... ■

Р.Якупов фотолары

Әлеге альбом-китабына тупланган фоторәсемнәрдә Рифкать Якупов татар халкының чын-асыл тормыш мизгелләрен чагылдыруга ирешкән. Автор безне дә иҗатташлыкка чакыра. Һәм... Тәүге карашка тып-тын тоелган сурәтләргә чираттагы мизгелдә аһәң вә төсләр иңә. Балачакта калган тәэсир вә хатирәләр уяна. Болын буйлап чапкан аргамакның кешнәп куюын, тояк астында җирнең тетрәнүен ишеткәндәй буласың...



МИЛЛИ РУХ «АТЛАНТИДА»СЫ

Миләүшә Хәбетдинова

Шагыйрь Зөлфәт гаиләсе белән Каенлыктагы Сабан туенда. Казан, 1974 ел

Бәхтияр авылында Сабан туена бүләк җыю. Әтнә районы, 1972 ел

Наласа авылы яшьләре. Арча районы, 1974 ел

Һәм, әлбәттә, җанга якын шушы ритмга канәгатьлек илә күңелеңне күндерәсең. Мәшһүр әдибебез Аяз Гыйләҗев язганча, «авыл әле ул гомер бакый туендыручы гына булмаган, аның әле татар милләтенең гасырлар дәвамында камилләшкән әхлагы, йолалары, рухы, әкият вә риваятьләре саклана торган бик тә үзенчәлекле дөньясы да булган. Авыл татарның рухи сәламәтлеген саклаган».

Рифкать Якупов фоторәсемнәреннән янә шунысын аңлыйсың, хезмәт кылып яшәгәндә генә бәхетле була алу зирәклегенә төшенәсең. Әйе, иртә таңнан кичке караңгыгача эшләп тә, зарланмый авыл халкы, күңелен исә һич кенә дә явызлык биләми. Киресенчә, бүгенге замандашларыбыздан аермалы буларак, һәрдаим эшләп, матди гына түгел, рухи байлыкларын да ишәйтергә омтылганнар һәм, әлбәттә, табигый рәвештә яши дә белгәннәр.

...Альбомдагы һәр фотосурәт татар халкының күмәк портретына аерым бер үзенчәлекле чалым өсти. Милләтнең тормыш-яшәеш кыйммәтләре гаҗәп төгәл, сиземләү белән тотып алынган. Өмә, Сабан туена багышланган хезмәтләрендә бу аеруча сизелә. Камера объективы халкыбыздагы «кояшлы» энергиянең, бәйрәмнең һәр күзәнәген тотып алган: мәйдан түрендәге көрәшнең дә, капчык сугышының да, башкасының да үз нечкәлеге чагыла. Иң мөһиме — бу бәйрәмнең татар өчен изгелеген күрсәтү. Гаиләнең, авылның, милләтнең бердәмлеге, берлеге, берәгәйлеге — Сабан туеның изге йоласы әнә шуңа барып тоташа.

Рифкать Якупов портретларына карыйсың да, Идел-йортны, үзенчәлекле милли культураны, әхлакый яшәү рәвешен безгә мирас кылган ата-бабага ихлас рәхмәт хисләре уяна. Әмма дә, ни кызганыч, фотоаппарат объективына эләккән күренешләр инде аның сурәтләрендә генә саклана... Асылда югалганнар алар, гаип булганнар. Әнә шуларны юксыну хисеннән соң, уртак милли мирасыбыз өчен җаваплылыкның үз җилкәңә дә төшүен ачыктан-ачык аңлыйсың. Милләтебезнең рухи байлыгын барларга, кайтарырга һәм сакларга әле соң түгел ләбаса, соң түгел! ■

2015 Парклар һәм Скверлар елы

Панаев бакчасы

Заманында казанлыларның иң яраткан урыны — Панаев бакчасында ресторан, ике яруслы театр, шахмат клубы, павильон, фонтан, кегельбан булган. Театрда рус һәм татар спектакльләре, концертлары куелган.

Бакчаның исеме аның хуҗасы — статский советник Лиодор Александрович Панаев һәм улы Ахиллес Лиодоровичларга мөнәсәбәтле. Панаевлар нәселеннән шактый гына сәнгать эшлеклеләре, язучылар, шагыйрьләр, музыкантлар чыккан. Л.А.Панаев үзе дә виртуоз-скрипач, дирижёр һәм композитор булган.

Хәзерге көндә бу бакча биләмәсендә «Динамо» стадионы урнашкан.

Абдулла Дубин *әзерләде.* ■



Казань.—Kasan. № 66.
Павильонъ и ресторанъ Панаева.





ДИНАМО

ЧЫҢГЫЗ АЙТМАТОВНЫ БИРГӘН МӘЧКӘРӘ

Фәүзия Бәйрәмова

Инде Чыңгыз Айтматовның бабасы — шушы Мәчкәрә авылы кешесе, Ишмән нәселеннән булган Хәмзә Хәсән улы Габделвәлиев турында да бераз мәгълүмат биреп үтик. Аның турында да Татарстан журналистлары шактый язды, мин аларны кабатларга җыенмыйм. Барлык язмаларда да диярлек, Хәмзә Габделвәлиевның туган елы 1840 дип күрсәтелгән, әмма архив чыганаклары, метрика язулары әйтелмәгән. Безнең уебызча, ул соңрак туган булырга тиеш, моны документлар нигезендә ачыкларга кирәк булачак. Кайбер язмаларда Хәмзә Габделвәлиевның туган урыны итеп Казан каласы күрсәтелгән, бу — туганнарының соңрак «Казан ягы кешесе» дигәненнән үзгәртеп, әйләнешкә кертеп җибәрелгән хата булырга тиеш. Хәмзә Габделвәлиевның Мәчкәрәдән төгәл генә кайсы елда Урта Азия якларына чыгып китүе билгеле түгел — берәүләр 1870-1880 елларны, икенчеләр 1880 еллар уртасын күрсәтә. Хәмзә Габделвәлиевның Мәчкәрәдә беренче хатыны һәм баласы калганлыгы билгеле. Кырык яшен узган кешедә нигә бер генә бала икән? Анысы да ачык түгел. Хәмзәнең ни сәбәпле Урта Азия якларына чыгып китүе дә билгесез. Югыйсә, ул авылда нык нәселдән бит. Ни өчен әле кәрванга ияреп, туган авылында гаиләсен-баласын калдырып, дөнья читенә чыгып китәргә тиеш булган? Бу сорауларның барысы да хәзергә ачык кала. Кайбер язмаларда аның Урта Азиягә энесе һәм сеңелесе белән чыгып китүе әйтелгән, кайберләрендә аларны соңыннан гына чакыртуы турында язылган. Туганнарын үз янына алгач, нигә гаиләсен «онытты» икән? Аңа да җавап юк...

Без бу язмада Хәмзә Габделвәлиевның Кыргызстандагы тормышына анализ ясарга җыенмыйбыз, безне аның тормышының Мәчкәрә белән бәйле өлеше кызыксындыра. Алай да, хәбәрдар булмаган укучылар өчен бераз мәгълүмат биреп китүне кирәк таптык. Хәмзә Габделвәлиев кәрван белән Голҗага (Шәркый Төркестан, хәзер Кытайга керә) хәтле барып җитми, Ысык-Күл буендагы Каракол (Каракүл, Пржевальск) каласында тукталып кала. Шушында төпләнә, зур сәүдәгәр-эшмәкәр буларак таныла, яңадан өйләнә. Аларның сигез ба-

*Ахыры. Башы журналның 5 нче санында.

ласы туа, Нәгыймә апа 1904 елның 7 декабрендә дөньяга килә.

Бу урында Нәгыймә апаның әнисе турында да әйтеп үтәсе килә, чөнки ул да татар кешесе. Бирегә килгәч, Хәмзә япь-яшь татар кызына — Газизәбануга өйләнә, ул Верный (Алматы) шәһәренең данлыклы бае Исхак хаҗи кызы була. Газизәбануны Казакъстанның элеккеге җитәкчесе Кунаевның әнисе белән кардәш булган, дигән хәбәрләр дә бар. Әмма барыбер Нәгыймә апаның әнисе, Чыңгыз Айтматовның татар әбисе Газизәбануның нәселе өйрәнелмәгән килеш кала... Совет власте Каракол-дагы йорт-җирләрен тартып алгач, 1930 елда Хәмзә белән Газизәбануны Сабир уллары Ташкентка алдыра. Алар шун-да бер-бер артлы үлеп китәләр. Дүрт елдан соң Сабирның үзен дә, халык дошманы дип, атып үтерәләр. Нәгыймә инде бу вакытта кыргыз егете, компартия җитәкчесе Терекул Айтматовта кияүдә була. Соңрак аның ирен дә, халык дошманы дип, кулга алалар һәм атып үтерәләр. Ирсез, ата-анасыз калган Нәгыймә апага дүрт баласын ялгыз үстерергә, аякка бастырырга, кеше итәргә туры килә. 1928 елда туган олы улы Чыңгыз яшьли әнисенә терәк була, ул үзенең беренче әсәрләрен дә әнисе турында һәм аңа багышлап яза һәм әнисе үлгәнче, ягъни 1971 елгача, аны үзе карый, янында яшәтә...

Нәгыймә һәм Терекул Айтматовлар. Каракол, 1926 ел

Милләт каршында ничә еллар тор-ган кайбер четерекле сорауларга да кагылып узыйк, чөнки Айтматовлар темасына тотынгач, моны әйләнеп үтеп булмый. Менә ул сораулар: ни өчен Чыңгыз Айтматов үзе башлап әнисенең татар икәнлеген дөньяга белдермәгән; ни өчен ул көчле һәм гайрәтле чакла-рында туган якларын кайтып күрмәгән; ни өчен Нәгыймә апа да беркайчан әтисенең туган якларына кайтмаган? Туры һәм гадел сораулар бу. Җавап та туры һәм гадел булырга тиеш. Әйе, Чыңгыз Айтматовның әнисе — татар, әмма ул Кыргызстанда, кыргыз атасы туганнары арасында яшәгән, мәктәптә дә кыргызча һәм урысча укыган, шәхес буларак та кыргыз мохитендә форма-лашкан. Татар әби-бабасы аңа өч яшь вакытта үлгән. Татар анасы тормышны тарткан.

Инде мәгълүм затка әверелгәч, Чыңгыз Айтматовның бу бөеклекне башка халык белән бүлешәсе кил-мәгәндер, чөнки ул кыргызларның милли байрагы булды, аларның мил-ли байлыгы саналды. Айтматов аша кыргызлар үзләре дә дөньяга та-нылды. Зур мөнбәрләрдән: «Минем әнием — татар, миндә татар каны

Нәгыймә, Каракол, 1917

да ага», — дип аваз салу яисә язып чыгу — ул талант бөеклеген башка халык — татарлар! — белән дә бүлешү булып яңгырар иде. Айтматов моны эшләмәде. Шул сәбәпле, үзе аякта нык торганда, татар тамырларын да эзләп йөрмәде, туган якларына да кайтмады, ул аның Кукмара төбәге икәнлеген 2006 елга кадәр белмәде дә. Нәгыймә апа исә төпчек кызы Розаны тапканда нык чирләп кала, соңыннан гомер буе бума чире (астма) һәм буыннар шешү белән газаплана. Берсендә әтисенең туган якларына кайтырга җыенгач, аның нык авырып урынга ятканын да сөйлиләр. (Шунысын да онытмыйк — Нәгыймә абыстай үзе Кыргызстанда туган бит!)

Чыңгыз Айтматов Татарстанга, татарларга бу гасыр башында гына йөз белән борыла башлый, берничә тапкыр Казанга килә, милләтебезне күзәтә, чагыштыра, өйрәнә... Аның аңында һәм җанында татарлыкка төп борылыш Казанның 1000 еллыгын бәйрәм иткәндә булгандыр, дип уйлыйм: ул биредә татар халкының бөеклеген, матурлыгын, затлылыгын күрде, чал тарихы белән очрашты... Ә инде 2006 елның февралендә, Җәлилнең 100 еллыгына Казанга килгәч, Кукмара районы музее директоры Ләбүдә ханым Дәүләтшина аның алдына Ишмән шәҗәрәсен чыгарып сала, Чыңгыз Айтматов үз нәселенең гасырлар тирәнлегенә киткән көчле тамырларын күреп, таң кала... һәм Кукмара музеена түбәндәге хатны юллый: *«Дорогие учредители музея Кукмора! Выражаю Вам искреннюю благодарность за информацию о создании родославной Абдулвалиевых, моих предков по материнской линии. Для меня такая чудесная весть была неожиданной и исторически великой для всего нашего семейства Айтматовых, для моих предков. Вы установили нашу родославную на Кукморской земле. Теперь это место, это деревня будет для нас святым местом...»*

2007 елда Чыңгыз Айтматов Казанга тагы килә. Бер елдан, майда, үзенең татар тамырлары турында документаль фильм төшерергә, милләттәшләре белән очрашырга дип янә Казанга юл тота... Ул инде бу юлы татар булып өлгереп, сагынып, яратып бире кайта (нәкъ менә кайта!), дулкынланып, әнисенең туган якларына — Кукмара төбәгенә сәфәр кылырга җыена... Әмма Тәкъдир аның юлына аркылы баса — гасырга тиң гомерендә туган нигезгә кайтып тезләнергә бер көн вакыт җитми... Каты авырып киткән Чыңгыз Айтматовны 16 майда Казан хастаханәсенә салалар, аннан аңсыз хәлдә Германиягә дәваланырга озаталар, ул шунда, данлыклы Нюрнберг шәһәрендә 10 июнь көнне үлә... Аны

Нәгыймә абыстай балалары белән. Покровка авылы, 1953 ел

Кыргызстанның Ата-Бәет зират-комплексына, әтисе янына җирлиләр.

Чыңгыз Айтматов Татар иленә үләргә кайткан булып чыга…

Ә бабасы туган Мәчкәрәдә аны ул көнне бөтен халык көтә, Хәмзә аганың нигезендә бәлешләр пешереп, табын әзерләп каршы алырга хәзерләнәләр… Менә хәзер ул нигездә мин басып торам… Дөрес, анда инде күптән башка кешеләр яши. Хәмзә аганың беренче хатыныннан туган улы Исмәгыйль, тормышлар бик авырайгач, өен сатып, Кыргызстанга китә, әмма аны салкын каршылыйлар, дип сөйләделәр. Исмәгыйль яңадан авылга кайтып, кеше өстендә яшәп үлде, диделәр… Хәмзә аганың күршесендә генә Мәчкәрәнең данлыклы мәдрәсәсе булган, хәзер аннан зур-зур нигез ташлары гына калган…

Хәмзә аганың нигезе дә, мәдрәсә дә мәчет урамында, заманында мәдрәсәдән Беренче Җәмигъ мәчетенә кадәр ак таш җәелгән булган. Атаклы Хәсән байның йорт-кибетләре дә шушы урамда, таш келәт-кибете һаман эшләп тора. Менә Беренче Җәмигъ мәчете, аны 1791 елда Габдулла Үтәмешев салдыра, совет чорында анда ашлык складын булган, чеби дә тоталар… Хәзер ул торгызу хәлендә. Кызыл кирпечтән салынган ике катлы мәһабәт бина, түшәмнәре бизәкле, стеналары калын, ишек-тәрәзәләре атлы арба сыярлык… Биредә күп еллар инде тергезү эшләре бара, әмма эшлисе эш һаман шактый әле.

Менә Икенче Җәмигъ мәчете, анысы башта агач була, ул 1800 елда Габдулла Үтәмешевнең улы Муса Үтәмешев тарафыннан ислам диненә килгән арлар (удмуртлар) өчен төзетелә. 1871 елда агач мәчет янгач, Муса Үтәмешевнең улы Исхак 1872 елда шул нигездә таш мәчет салдыра. Совет чорында анда клуб була, үзгәртеп кору заманында көндез — мәчет, кичен — клуб… Хәзер исә Мәчкәрәдә күрше авылдан күчертеп салган яңа мәчет эшли, халык намаз укырга да, гыйлем алырга да шунда йөри. Бу урында авыл има-

мы Мөнир хәзрәт Йосыпов турында иң яхшы сүзләребезне әйтәсе килә — ул Мәчкәрәнең бәхете, иман сагында торучысы, догачысы, аңа Аллаһның рәхмәтләре булсын!

Алдагы тукталышыбыз — Үтәмешевләр йорты... Хәер, йорты гына түгел, ә утар-комплексы, Мәчкәрәнең хан сараедай милли-тарихи бизәге... Ул 1800 елда Үтәмешевләр тарафыннан салына, зур нәселнең төп йорты-нигезе булып тора. Әмма совет хөкүмәте йорт хуҗасы, зур сәүдәгәр, Казан шәһәр думасы әгъзасы Исмәгыйль Үтәмешевне 1929 елда сөргенгә озата, аның гаиләсен, туганнарын да шул язмыш көтә... Урал аръягына сөргенгә сөрелгән хатыны Зөбәйдә Үтәмешева ике баласын поезд тәрәзәсеннән ташлый, соңыннан үзе дә сикерә. Аллаһ рәхмәте, балаларын эзләп таба, алар Үзбәкстанга качалар. Соңыннан дөньякүләм галим булып танылачак Рөстәм (Үзбәк) Үтәмешев — әнә шул поезд тәрәзәсеннән тотып атылган өч яшьлек бала була... Бу вакыйгалардан соң 85 ел вакыт үткәч, Рөстәм Үтәмешевнең улы Илдар Үтәмешев Мәчкәрәгә кайтып, ата-бабасы нигезенә баш ия, зиратта дога кыла...

Чәчәкләргә күмелеп утырган ике катлы бу таш йорт хәзер дә халыкка хезмәт итә, анда ярдәмче мәктәп-интернат урнашкан. Сугыш вакытында исә бирегә Ленинградтан килгән ятим балаларны урнаштыралар, 1959 елда авыру балалар өчен шушы интернат ачыла. Без биредә булдык, мондагы матурлыкка, тәртипкә сокландык, авыру, проблемалы балаларны хезмәт белән тәрбияләүләрен белеп, сөендек. Интернат-мәктәп директоры Шәүкәт Нәкыйп улы Сабитовның бөтен җанын-тәнен биреп бу авыр йөкне тартканы сизелеп тора, аңа Аллаһның рәхмәтләре булсын!

Менә юл өстебездә — авыл башындарак челтерәп агып яткан чишмә, ул да борынгыдан калган, әмма соңгы елларда онытылган, ташланган булган. Кукмараның төбәк тарихын өйрәнү музее директоры Ләбүдә ханым Дәүләтшинаның тырышлыгы һәм тәкъдиме белән, Сандугач чишмәсе яңадан торгызыла, бу эштә Равил Ганиев зур ярдәм итә. Бу чишмәдән Чыңгыз Айтматовның бабалары да иелеп су эчкәндер, алар кыргыз далаларына да хәтер күзәнәкләрендә шул суларның шифа-көчен алып киткәндер, әдипнең иҗатына Сандугач чишмәсенең дә сулары тәэсир иткәндер, дип уйлыйсы килә...

Соңгы тукталышыбыз — зират... Авыл башында, алтын кырлар янәшәсендә, карурман кебек тын гына, моң гына шаулап утырган борынгы зират... Ул инде өч зират кушылып бер зиратка әйләнгән, тыштан — киртә, эчтәрәк таш коймa белән уратып алынган. (Мондый биек таш коймаларны минем Киров өлкәсендәге татар авыллары зиратларында да күргәнем булды.) Катнаш урман, диярсең — башлары күккә тигән төз наратлар, гасыр белән бергә картайган ак каеннар һәр кабер өстендә шаулап дога кыла... Чардуганнар беткән, каберләр иңгән, бары тик өсләренә куйган борынгы ташлар гына монда ятучыларның кемлекләренә шаһәдәтлек биреп тора...

«В ходе осенней экспедеции 1998 года только на одном кладбище села Маскара было обнаружено, учтено и и исследовано 33 арабско-графических надгробных камня, — дип яза алар. — *Надо отметить то обстоятельство, что село Маскара в истории татарского просветительства занимает особое место. Тексты надмогильных плит также ярко свидетельствуют о культурной и просветительской роли села в прошлом этого края. На них нанесены обширные сведения об основателе села Маскара, благородном старике Ишмане, о богатом роде Утямышевых».* (Кукморский край..., стр. 52.)

Бу юлларның авторлары, галимнәр Ирек Һадиев белән Раиф Мәрданов Кукмара районы зиратларындагы өч йөзгә якын борынгы кабер ташларын

Мәчкәрәдә Үтәмешевләр йорты. Бүген бу бинада коррекцион мәктәп урнашкан

өйрәнгәннәр, әлеге хезмәтләрен күптән түгел китап итеп тә бастырып чыгардылар. Аларның Кукмара төбәге тарихын өйрәнүгә зур өлеш кертүләрен әйтергә кирәк. Шулай ук тарихчы-археолог Альберт Борһанов та төбәк тарихында үз сүзен әйткән, яңа карашын белдергән. Ә инде Кукмара төбәген Чыңгыз Айтматов шәхесе белән бәйләп өйрәнүне район музее директоры Ләбүдә ханым Дәүләтшина кузгата. 1997 елда Мәчкәрә мәктәбе музеенда Ишмән шәҗәрәсенә тап булганнан соң, ул галимнәр ярдәмендә Чыңгыз Айтматовның татар бабалары тамырларына килеп чыга һәм бу турыда бөтен дөньяга белдерә. Дөрес, аның сүзләрен кабул итмәүчеләр дә очрый, кайбер бөекләребез үк бу хакта тәнкыйть мәкаләсе дә язып чыга: Чыңгыз Айтматовны тартып-сузып татар ясамакчы булалар, имеш… Әмма Ләбүдә ханым барыбер туктап калмый: 2006 елда Ишмән шәҗәрәсен Казанга килгән Чыңгыз Айтматов алдына чыгарып сала, 2008 елда, Кукмара төбәгеннән бердәнбер вәкил булып, Татарстан делегациясе составында Кыргызстанга, Чыңгыз Айтматовның 80 еллык юбилеена бара һәм анда чыгыш ясый, аннары да эзләнүләрен дәвам итә. Ләбүдә ханымны мин Кукмара районы өчен зур табыш, дияр идем, үз эшен шулкадәр яратып һәм җиренә җиткереп эшләүчеләр хәзер бик сирәк бит!

Әйе, Чыңгыз Айтматов, гасырларга тиң олы юлга чыкса да, бабасының туган авылына кайтып җитә алмаган… Күрсә, ул да Мәчкәрәне яратыр иде, чөнки мондый мәгърифәтле һәм нурлы авылны яратмау мөмкин түгел! Нәгыймә апа да атасының туган нигезен кайтып күрә алмаган… Әмма бу изге әманәтне Чыңгыз Айтматовның улы Илдар Айтматов үтәгән. Ул әнисе Мария Үрмәт кызы һәм әбисе Нәгыймәнең төпчек кызы Роза Айтматова белән Мәчкәрәгә кайтып, туган туфракка баш игән… Алар татарлыкларын таныганнар. Татар иле, туган туфрак та аларны таныган һәм кабул иткән. Ә Чыңгыз Айтматовның рухы исә өметнең ак пароходлары булып, ак боланнарга һәм язгы торналарга әйләнеп, бу очрашуны күзәткәндер. Сөенгәндер, барыбер сөенгәндер…

Һәм җаны мәңгегә тынычланып калгандыр… ■

ТАССР ОЕШУГА 95 ЕЛ

МИЛЛИ ДӘҮЛӘТЧЕЛЕК ТУГАНДА...

Рәмзи Вәлиев

Халыкның канәгатьсезлеге нәтиҗәсендә, шәһәрдә бәрелешләр башланып китү куркынычы туа. Халык мәчетләргә, базарларга, мәйданнарга чыгып Казан Советының, большевикларның мәкерле хәрәкәтләренә каршы чыгып, кулга алынганнарны иреккә чыгаруны таләп итә. Шул ук көнне иртә белән зур халык төркеме, вәисовчыларның штабы янына килеп, Гайнанетдин Вәисовның да бу мәсьәләдә ачык фикер әйтүен таләп итәләр. Нәтиҗәдә, ул большевиклар белән бәрелешүне хупламый, ә барысын да тыныч юл белән хәл итүне күз алдында тота. Моның белән канәгать булмаганнарның берсе аңа пистолеттан ата. Вәисов яралана һәм һәлак була. Халык штабка бәреп керә.

Шулай итеп, Казан кайный. Канлы бәрелешнең беренче билгеләре күренә. Гайнетдин провокациясе пожарны керосин сибеп сүндерүгә охшаган. Моны сизенгән большевиклар тиз арада кулга алынганнарны азат итеп, алардан Советларга каршы көрәшмәскә вәгъдә алып иреккә чыга. Иреккә чыгучылар, II нче мөселман хәрбиләре корылтаеның җитәкчеләре, тиз арада съездны дәвам итәләр. Әмма инде хәзер утырышлар Ратуша йортында түгел, ә Болак артында 95 нче мөселман полкының казармаларында оештырыла. 1 мартта «Идел Урал штаты»н игълан итүне өзсәләр дә, милли дәүләтчелекнең проблемалары менә шушы утырышларда каралып, нәтиҗәдә монда беренче татар демократлары тарафыннан оешкан мөселман халык комиссариаты төзелә. Составында 15 кеше була. Анда Исмәгыйль Атнагулов, Исхак Алмаев, Габдулла Габдрәшитов, Фәхрелразый Басыйров, Әкрам Биглов, Әфтәхетдин Габдуллин, Сөләйман Ловчицкий, Гали Моракаев, Фатих Мөхәммәдьяров, Сөләйман Полторжицкий, Кәшшаф Терегулов, Адәм Якубовский, Әхмәтсолтан Таһировлар керә. Комиссариатның рәисе итеп Исмәгыйль Атнагулов, рәискә иптәшлеккә И.Кәрим, И.Алмаев, сәркатиплеккә Г.Габдрәшитов, К.Терегуловлар сайлана. Комиссариат биш бүлектән тора. Чынлыкта аңа «Идел-Урал штаты»н тормышка ашыру эше йөкләнә. Комиссариат Екатерининская урамындагы Апанаев йортында урнаша.

Комиссариат «Мөхтәрәм мөселман кардәшләр!» дигән мөрәҗәгать кабул итә. Әлеге мөрәҗәгатьтә төп максатлар күрсәтелә. «Идел-Урал өлкәсе» гәзитенең әлеге мөрәҗәгате басылган 24 март санында Ф.Басыйровның «Төрки-татар демократиясенең таләпләре» исемле мәкаләсе дә урнаштырылган. Анда да шул ук фикер – «Идел-Урал»ны тормышка ашыру, бу өлкәгә кергән советларның составларын үзгәртү, чөнки алар составында төрки-татар демократлары юк диярлек дәрәҗәдә. Тиздән үтә актуаль таләп туа: Татар-башкорт җөмһүриятенә кергән советларның съездына, җир һәм милли составны искә алып, яңадан сайлаулар уздырырга. Советларны яңадан сайламый торып, съезд җыелган булса, бу съездны төрки-татар демократиясе мәҗлесе, органы итеп исәпләү мөмкин түгел.

Мөселман халык комиссариатының

Ахыры. Башы журналның 5 нче санында.

тарихын махсус рәвештә өйрәнү таләп ителәэ. Киләчәктә бу хакта язучылар булыр, дип өмет итәбез. Чыннан да кем соң ул Исмәгыйль Атнагулов? Фәхрелразый Басыйров һәм башкалар?

1918 елның 22 мартында Русиянең Милләтләр эше буенча Халык Комиссариаты «Татар-Башкорт Республикасын төзү турында декрет» кабул итә. Комиссариат җитәкчесе И.Сталин бу очракта, мөгаен, түбәндәге максатны күздә тоткандыр, ягъни: «буржуаз милләтчеләр»гә һәм гомумән «суллык» тарафдарларына, ягъни «туфракчылар» төркеменә хушсызландырырлык сугып алу, аларның милли эшләрне нык үзәкләштерүгә каршы юнәлтелгән уй-фикерләреннән ваз кичтерү.

Урындагы «Идел Урал штаты» дошманнары корал куллану юлына да басалар. Нәтиҗәдә, 1918 елның 28 мартында Казан урамнарында броневиклардан, пулемёттан атулар башлана. Бу эшне М.Вахитов һәм М.Солтангалиев «егетлеге» белән Кронштадттан килгән 300 матрос башкара. II нче Бөтенроссия мөселман съезды делегатлары куып таратыла, кулга алына, кайберләре үзләре килеп бирелә. Нәтиҗәдә, милли хәрәкәт бөтенләй сүнеп, туктап кала.

Татар милли хәрәкәтен бары тик меньшевикларның «Рабочее дело» газетасы гына яклап чыга. Газета 28 март вакыйгаларын түбәндәгечә бәяли: *«Тагын пулемётлар, тагын кан кою. Бөек Русия демократиясенең балалары берсе берсенә ярсып ташлана»*.

Халыкны тынычландырырга тырышып сөйләгән мөрәҗәгатендә большевик Милх, мыскыллап, *«Болак арты республикасы»н бетерү бара»*, дип шапырына. «Рабочее дело» газетасы үзбилгеләнү мәсьәләсенә дә кагылып: *«Үзбилгеләнү бары тик большевиклар рецепты белән генә уздырылырга тиеш булып чыга, кем дә кем алар символын кабул итми һәм үзенең эчке тормышын үзе оештырырга тели, аңа анафема – пулемётлар»*, – дип яза. *«Безнең Казанда,* – дип дәвам итә шул ук «Рабочее дело», – *каршылык күптән туган иде. Мөселманнарныщ хәрәкәте акрынлап, тыныч кына үсте... Ул татар пролетариатыннан һәм вак буржуаз демократиясеннән торган көчле хәрәкәт булып, шушы социаль нигезгә таяна иде. Булдыксыз Шейнкманнар, Грасислар, Милхлар һ.б. компанияләр тарафыннан урнаштырылган хулиганлык атмосферасы бик күп көчләрне милли хәрәкәткә китереп, аны бик көчәйтте. Хәрәкәтнең җитәкчеләре тарафыннан эшләнгән*

ТАССР оешу уңаеннан Казанда бәйрәм

милли-мәдәни мохтарият проекты (шактый гына житешсезлекләре булса да), гомумән алганда, милләтнең саф теләкләрен чагылдырып, шовинизмга каршы чыгып, күршеләр белән дустанә мөнәсәбәттә калуны таләп итә».

Үзенең хәрби көчләренә таянып, Хәрби Шура берничә тапкыр үз халкын бу оятсыз большевик тыкшынуларыннан якларга тырышып карады.

Эчке фронтта жиңүләр арткан саен, хакимиятнең кыюлыгы көчәя барды һәм, ниһаять: *«Үзбилгеләнү хокукы бары тик Советка гына бирелгән, ә милли оешмалар берсүзсез, господин Грасисның «самоопределительный операцияләр»ен күзәтеп торырга тиешләр. Әнә шулай итеп, милли оешмаларга каршы ачыктан-ачык көрәш башланды. Татарлар ачык сугыш кырында көч сынашырга теләмәделәр һәм милли гаскәри частьларны һәм Шураны тарату декретына буйсындылар. Шушы вакыттан башлап милли хәрәкәтне бастырылган дип санарга мөмкин».*

Бу мәкаләнең авторы – «Айвенго». Әлегә бу псевдонимның кемнеке булуы мәгълүм түгел. Шунысы билгеле: автор, чын демократ буларак, хакимияткә килгән большевикларның гамәлләрен бик дөрес тасвирлаган. «Болак арты республикасы» нәрсә ул?» дигән сорауны турыдан-туры куймаса да, «Айвенго»: *«Мөселманнар, Болак артына чыгып, бары тик үз-үзләрен саклап калуны гына оештыра алдылар»*, – дип яза. Димәк, «Болак арты республикасы» нииндидер явыз ният белән тудырылган нәрсә түгел, ә бары тик чамадан тыш кыланган Совет хакимиятеннән һәм, сукыр тычкан кебек, аларга ияргән мөселман «суллар»ының явызлыгыннан читкәрәк китеп, хокукларны саклап калуга омтылыш икән.

«Болак арты республикасы» беркем өчен дә куркыныч тудырмыйча, аның асылы милләтне саклаудан гына гыйбарәт иде. *«Большевикларның, бетмәс-төкәнмәс жинаятьләренә тагын берсе өстәлде. Бу эш халык исеменнән эшләнде. Килер бер заман, халык исемен файдаланып кан коюны һәм халыкларны бер-берсенә бәрелештерүләрнең эчке серен аңлап, аларны җирәнеп искә алырлар»*, – дип белдерә ул чордагы оппозицион матбугат.

«Идел-Урал штаты»н игълан итүне өзеп, II мөселман хәрбиләренең съездын куып таратып, бөтен милли оешмаларны япканнан соң, Үзәк тиз арада Татарстан Республикасын төзүне ашыктыра. «Татар-Башкорт Республикасы» турындагы декрет игълан ителү алдыннан Иосиф Сталин Галимҗан Шәрәфне телеграфка чакыра һәм «Идел-Урал штаты» мәсьәләсе белән кызыксына. Г.Шәрәф телеграф аша «Идел-Урал штаты», аның мәйданы һәм чикләре турында тәфсилле аңлатма бирә. Менә шушы сөйләшүдән соң ике көн үтүгә, комиссариатның «Татар-Башкорт Совет Республикасы» турындагы декреты игълан ителә. Шуннан соң «Идел-Урал штаты» һәйәтенең эше туктатыла, ә апрель ае башларында Г.Шәрәфне Мәскәүгә чакырып алалар. Чакырылучылар арасында З.Вәлиди, С.Покровский һәм башкалар була.

Бу махсус киңәшмәгә М.Вахитов белән М.Солтангалиев җитәкчелек итә. Киңәшмә эшендә алда искә алынган һәйәт әгъзаларыннан һәм Г.Шәрәфтән тыш, С.Атнагулов, Башкортстанның Вакытлы революцион Совет вәкиле Ф.Солтанбәков һ.б. катнаша. Анда Г.Шәрәф «Идел-Урал штаты» турында зур доклад белән чыгыш ясый. Ул үз фикерләрен дәлилләү өчен бик күп фактлар, статистик мәгълүматлар китерә. Киңәшмәдә аның төп фикерләрен хуплагандай булалар, әмма озакламый, үзәктәге бөекмәмләкәтчел шовинистларның басымы белән, башкорт, чирмеш, мукшы вәкилләре үзләренең фикерләрен капма-каршы якка үзгәртә: «Идел-Урал штаты»на гына түгел, «Татар-Башкорт Совет Республикасы»на да каршы чыгалар. Имеш, бу милләтләрнең бертигезлегенә хилафлык китерәчәк.

Г.Шәрәф үз фикерләрен никадәр якларга тырышса да, уңышка ирешә

алмый. Әйтерсең лә, әле күптән түгел генә охшаш фикерле булган кешеләрне үзгәртеп куйганнар. Әлбәттә, бу «үзгәреш»тә Милләтләр эше буенча Халык Комиссариаты җитәкчеләренең, беренче чиратта И.Сталинның һәм В.Ленинның да турыдан-туры катнашулары бәхәссез.

Татарстан җөмһүрияте әнә шулай озак тартышулардан, сәяси алдашулардан соң гына оеша алды. Татарның төрле губерналарда чәчелеп яшәве дә эшне кыенлаштырды, чөнки аларның берсендә дә татарлар күпчелекне тәшкил итми һәм шунлыктан мохтарият төзүгә нигез була алмый кебек иде. Бу мәсьәләне гадел хәл итү өчен губерналар чикләрен генә түгел, ә бәлки өяз һәм волость чикләрен дә аларда яшәүче халыкның милли составына нисбәтле рәвештә үзгәртү таләп ителде. Әлеге очракта җирле идарә, Мәскәү архив документларын һәм материалларын өйрәнеп эш итү кирәк иде. Бөекмәмләкәтчел үзәк исә бу мәшәкатьләргә баруны артык һәм кирәкмәс эш итеп санады.

Булачак Татарстан җөмһүриятенең мәйданын һәм чикләрен билгеләү мәсьәләсендә Г.Шәрәфкә Милләтләр эше буенча Халык Комиссариаты җитәкчесе И.Сталин белән еш очрашырга туры килә. Ул үзе бу хакта болай искә ала: *«В.И.Ленин һәм М.И.Калинин имзасы белән декрет (ТАССРны төзү турында.– Р.В.) игълан ителгәнгә кадәр Сталин комиссия эшендә башыннан алып ахырына кадәр бик актив катнашты. Безнең тарафтан якынча сузылган чикләр, аерым җентекләп эшләнгән кисәкләр, сәнәгатьне, авыл хуҗалыгын өйрәнү материаллары, теге йә бу төбәкнең халык составы, теге яки бу үзәктә административ төзелеш һәм шуларга охшаш башка әзерлек материаллары – барысы да Сталинга җиткерелә, ә ул аларны үзендә калдыра да икенче утырышта үз төзәтмәләре белән кире кайтара иде»*.

Нәтиҗәдә, «Идел-Урал штаты» төзеләсе төбәктә 1920 ел урталарында өч административ берәмлек – Кече Башкортстан җөмһүрияте, Татарстан җөмһүрияте һәм Уфа губернасы барлыкка килә. Беренче төзелгән план буенча Уфа, Бөре шәһәрләре һәм Бәләбәй өязе дә Татарстанга кертелергә тиеш була. Моны Зәки Вәлиди дә хуплаган. Әмма Татарстанның болай «зураюы» үзәкнең максатларына һич тә туры килми. Аларның нияте – Уфа белән Казанны Татарстан җөмһүриятенә кертмәскә. «Саллы» дәлилләре дә бар: Казанны Татарстанга кертсәң, аның фән үзәге буларак әһәмияте калмаячак, янәсе. Мондый каршылыкны университетка оялаган шовинистлар аеруча хуплыйлар. Бөтенрусия Үзәк Башкарма Комитеты аларны «тынычландырыр» өчен Казан университетының үзәккә буйсынулы булуы хакында махсус карар чыгара.

Казан губернасы Башкарма Комитетының бер төркем бөекмәмләкәтчел шовинист тарафдарлары, Татарстан җөмһүрияте төзүнең урынсызлыгын дәгъвалап, хәтта Сталин белән Ленинга кадәр барып җитәләр. Бу ачыктан-ачык шовинистик гамәл хәтта ВКП(б) Үзәк Комитетында һәм Халык Комиссарлары Советында да яклау тапмый: Татарстан җөмһүрияте төзелә һәм Казан аның башкаласы итеп раслана. Уфа губернасының язмышы референдум юлы белән хәл ителергә тиеш була. Ләкин соңыннан, 1922 елда Үзәкнең махсус указы белән генә, референдум уздырмыйча, татарларның Казаннан да күбрәк яшәгән өлешен Кече Башкортстанга кушып Олы Башкортстан ясалды.

Татарстан Республикасының дөньяга килүе — Бөек Октябрь революциясенең бер нәтиҗәсе, дип карарга кирәк. Чөнки ул аның барлыкка килүенең төп сәяси шарты булды. Алай булмаганда Казан губернасы сакланып калган булыр иде. Революция тәэсирендә көчле милли хәрәкәт белән дә Үзәк санашмый булдыра алмады — курыкты һәм ашыгыч чаралар кылып, милли автономияләр төзү юлына басты. ■

Казан губернасы Казан өязенең төньяк өлеше картасы. 1901 ел.
Себер тракты ике параллель сызык белән күрсәтелгән

Этап тәрмәсеннән калган кул богавы

«СЕБЕР ТРАКТЫ ТАРИХЫ» МУЗЕЕ

ОНЫТЫЛГАН ЮЛ

Шәмсетдин Күлтәси кебек мәгърифәтчеләре белән дан тоткан Арча районы Күлтәс авылы читеннән Балтач районы Арбаш, Карадуган авылларына таба, урман аша сузылган Себер тракты калдыклары барлыгын күпләр белмидер, мөгаен. Салынган еллары патшабикә Екатерина II заманына туры килгәнлектән, аны «Әби патша юлы» («Екатеринский почтовый тракт») дип атап йөрткәннәр. Бүген биредә тынлык. Ә заманында бу юлда ям чапкан (яки «почта чапкан») атларның кыңгырау чыңнары, Себергә сөрелгән каторжаннарның богау тавышлары яңгыраган. Шуннан сәүдәгәрләр мал ташыган, А.Н.Радищев, П.П.Семёнов-Тян-Шанский, Ф.Достоевский, Ш.Мәрҗани, М.Фәйзи кебек зыялылар узган. Киләчәктә таш юлның авылга иң якын булган өлешендә бер истәлек билгесе булыр, ул туристик маршрутка да кертелер, дип өметләник. Һичшиксез, хәзер асфальт юлларда җилдереп үскән яшь буын ата-бабалары сәфәр кылган ташлы-сикәлтәле ат юлларының да нинди булганлыгын белергә тиеш.

«Әби патша юлы»

ҖӘЛИЛ МУЗЕЕННАН СЕБЕР ТРАКТЫ МУЗЕЕНА

1976 елда Карадуган авылы мәктәбендә Муса Җәлил музее оештырыла. Бөек Җиңүнең 40 еллыгына, ягъни 1985 елда аның бер өлешендә Сугышчан дан залы ачыла. Әлеге зал туган төбәкне өйрәнүгә, ә соңрак исә 1995 елның 12 октябрендә ачылган «Себер тракты тарихы» музее оешып китүгә төпле нигезне тәшкил иткән. Музейның Карадуган авылында булуы очраклы түгел. Нәкъ менә биредә почта станциясе һәм каторжаннарны йоклатып чыгара торган төрмә, каземат булган.

Музейның беренче катында Муса Җәлилгә багышланган бай экспозицияләр (биредә шагыйрь уйнаган мандолина да бар, ә монысы инде аерым тарих), Сугышчан дан залы булса, икенче катта исә атлы почтадан алып электрон почтага кадәр булган тарихны күзәтергә мөмкин. Шулай ук музейда почта станциясендәге

Атлы почтага багышланган экспозиция

мосафирлар йорты бүлмәсен, сәүдә тормышын, авыл халкы көнкүрешен, рухи тормышын, мәгарифен, мех, мебель фабрикалары эшчәнлеген чагылдырган бай экспозицияләр бар. XX йөз башына нисбәтле хатын-кыз калфаклары аеруча күз явын алырлык.

ЯМ ЮЛЫНДА ЯЛ ЯКИ МОРТАЗА БАЙ ЙОРТЫ

Төбәктәге иң зирәк һәм акыллы байларның берсе 2 нче гильдия сәүдәгәр Мортаза Мөлеков 1911 елда иң керемле урын — почта станциясе янындагы җирне кулга төшереп таш бина сала. Бинаның беренче катында кибет, икенче катта мосафирларга ял итү өчен кунакханә оештырып җибәрә. Байның Балтачта киез итек фабрикасы була, ә анда җитештерелгән товар хәтта Германия базарларында да сатылган.

Мортаза бай йортында Совет чорында мәктәп булган, ә хәзер «Себер тракты тарихы» музее урнашкан. Музейның татар байларына багышланган почмагында Мортаза байга нисбәтле төрле документлар, фоторәсемнәр белән танышырга мөмкин. Биредә төбәк тарихында зур роль уйнаган сәүдәгәр, химаяче, ат заводлары хуҗасы Габдрахман Ишморатов турында да кызыклы мәгълүматлар бар.

Почта станциясендәге мосафирлар йорты бүлмәсе

Юл кирәк-яраклары

БАКЫЙ АГА

Гомере буе авыл балаларына белем биргән педагог, физика-ма-

«Барышня» аша ялгаучы агач корпуслы телефон аппараты

Карадуган – патша заманнарыннан бирле почталы авыл

тематика укытучысы, мәктәп директоры, милләтпәрвәр **Бакый Шәймулла улы Зыятдинов (1930-2014)**, лаеклы ялга чыккач «Себер тракты тарихы» музеен оештыру эшенә ныклап керешә. Экспонатлар туплау белән бергә туган төбәге тарихын өйрәнә, нәсел-шәҗәрәләрен барлый, бер-бер артлы унбер китап бастырып чыгара. Аның «Себер юлы серләре» (1999), «Мәгърифәтле Таузар иле» (2004), «Рәхмәт сиңа, Хәсәншәех» (2006), «Себер юлы буйлап: Карадуган һәм Арбаш авыллары тарихыннан сәхифәләр» (2010), «Тамырларыбыз Таузар илендә» (2012), «Әп-әздән башланган Апаз» (2013) кебек китаплары чын мәгънәсендә югары фәнни кимәлдә, бай архив чыганаклары нигезендә язылган[1].

Хәзерге вакытта Бакый ага башлап җибәргән күркәм гамәлләрне аның килене **Фирая Зыятдинова** дәвам итә.

Ленар Гобәйдуллин *әзерләде.* ■

«Себер тракты тарихы» музее бинасы. Беренче директор – Бакый Зыятдинов

[1] Журналның 5 санында Бакый ага Зыятдиновның мәкаләсе дөнья күрде.

КИҢӘШЛӘ ЭШ ТАРКАЛМАС!

26-29 майда Казанда төрки дөнья журналистларының II корылтае булды. Ул төрки дөнья журналистлары федерациясе һәм «ТАТМЕДИА» Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы тарафыннан оештырылды.

Төрки дөнья журналистларының II корылтае Татарстан Президенты вазифаларын вакытлыча башкаручы **Рөстәм Нургали улы Миңнехановның** тәкъдиме һәм ярдәме белән уздырылды. I корылтай исә үткән ел Төркиянең Искешәһәр каласында узган иде.

С.Исхаков фотолары

КӨТЕБЕ СИТТӘ ВӘ МӨӘЛЛИФЛӘРЕ

Ризаэддин Фәхреддин

ХӘДИС ГЫЙЛЕМЕ ҺӘМ РУСИЯ ИСЛАМНАРЫ[1]

Русия исламнарының хәдис гыйлеменә булган мөнәсәбәтләрен белер өчен гомуми рәвештә булган «гыйлем» тарихларын күзәтеп чыгу тиешле. Гыйлем тарихлары беленсә, хәдис гыйлеме хакында булган хәлләр үзеннән-үзе мәгълүм булыр.

Русия исламнарының гыйльми тарихлары безнең тикшерүебезчә, **аптырау дәвере, Дагыстан дәвере, схоластика дәвере, уяну дәвере** исемле дүрт дәвергә аерыла.

Беренче — «аптырау дәвере». Бу дәвер Казан мәмләкәте Русия кулына кергән көннән башлана. Бу дәвердә мөселманнар дин ирегенә хуҗа түгел иде. Ислам дине, рәсми дин буларак, хөкүмәт тарафыннан танылмаган иде. Моннан башка Волга (Идел) белән Урал арасында Агыйдел белән Чулман буйларында башкорт гаугалары дәвам итеп тора иде. Шул сәбәпле, исламнарның хәлләре өметсезлектә һәм аптырауда үткән, гыйлем һәм мәгърифәт юлында бер адәмгә дә йөрергә мөмкин булмаган.

Икенче — «Дагыстан дәвере». Бу дәвердә исламнар үз акылларын башларына җыеп, шулай хиссез һәм хәрәкәтсез торудан гүзәл нәтиҗә чыкмаячагын аңлап, укырга, дигән фикергә килгәннәр һәм ничә мәшәкатьләргә дучар булсалар да, Дагыстан тарафларына шәкертләр җибәреп, гыйлем алдырдылар; Дагыстан вилаятеннән кайткан шәкертләр үзләренә күрә мәктәпләр төзеп яки үз йортларына җыеп, милләт балаларын укыта башлаганнар. Бу дәвердә таралган гыйлем гарәп нәхүе (синтаксисы), сарыфы (морфологиясе) һәм дә фикыһ фәннәреннән гыйбарәт булган. Дагыстаннан килгән шәкертләрнең рәсми язулары дөрес, гүзәл булып, мәмләкәтебездә булган иске язма хезмәтләр [шул] буыннар һәм буыннарның шәкертләре тарафыннан язылган булулары мәгълүм. Боларның укыткан нәрсәләре житди, файдалы булып кешеләрнең әхлак һәм гадәтенә яхшы тәэсир иткән. Бу дәвердә Коръән һәм хәдис гыйлемнәре укылмаган булса да, кешеләр арасында гүзәл холык, ислам буенча туганлык, әдәп, инсафлылык таралу җәһәтеннән «алтын дәвер» дип саналган.

Өченче — «схоластик дәвер». Бу

*Ахыры. Башы журналның 2014 елгы 9 нчы санында.

[1] Исламнар — биредә мөселманнар мәгънәсендә.

Ризаэддин Фәхреддин. Уфа, 1899 ел

дәвердә башкорт гаугалары басылып, Оренбург шәһәре төзелүеннән алып һиҗри буенча XIV йөз башына[2] кадәр булган аралыктан гыйбарәт. Сахра халыклары Русия гражданлыгын кабул итүләре сәбәпле, Төркестан белән Русия арасында сәүдә юллары ачылып, кәрваннар йөри башлаган, моннан файдаланып, гыйлем алу максаты белән Русия исламнары Бохара тарафларына сәфәр кылдылар. Бу вакытта Русия дәүләте дин иреге игълан иткән һәм ислам динен рәсми рәвештә таныган. Бохарадан кайткан галимнәр хәтта олы мәдрәсәләр төзеп, тулы ихтыярлары белән укыта башлаганнар. Бохарада рәсми дәресләр юнан (борынгы грек) методлары, китап кереш сүзләре, шәрехләрнең һәм хашияләрнең (аңлатмаларның) бәхәс һәм сүз көрәштерүләре булган. Боларны үрнәк итеп тоткан безнең мәдрәсәләребездә Коръән һәм хәдис гыйлемнәре белән җитди рәвештә шөгыльләнә алмаганнар. Гәрчә, Курсави, шәех Гали Түнтәри, Мәрҗани кебек бөекләр кайбер хәдис китапларыннан дәрес бирсәләр дә, бу дәресләр, башкалар фикерендә игътибарсыз калудан куркып, схоластикадан башка дәресләр белән кызыксынмаган шәкертләргә булганлыктан, әһәмиятле саналмас.

Дүртенче дәвер — «уяну дәвере». Бу дәвер һиҗри буенча XIV йөз башыннан соң башлана. *«Аң-белем булдырылса, бөтен гыйлемнәр һәм фәннәр ачкычы алдыбызда булыр, дингә нинди юлдан, нинди тарафтан тыкшыну булса да, моның белән каршы тору җиңел булыр»*, — дигән дөрес булмаган фикер белән схоластика яклы булган затлар франк галимнәре тарафыннан исламга каршы китерелгән тыкшынуга җавап бирү түгел, хәтта ки мәсьәлә белән дә ачык рәвештә таныш булмаганлыктан, җиңелгәннәрен күреп, хаталарын аңладылар һәм хакыйкый гыйлем юлына керергә кирәклекне таныдылар. Тыкшынуга һәм һөҗүмнәргә җавап бирүдән элек хакыйкый ислам белән таныш булырга кирәк икәнен күрделәр. Моның нәтиҗәсе буларак, Коръән-шәриф һәм хәдис гыйлемнәрен алыр өчен юл ачылды. «Дөяләрне тавыклар базарында сатмыйлар» дигән критерий буенча бу фәннәрнең урыннары инде Бохара түгел, бәлки, Хиҗаз һәм Мисыр иде. Шуның өчен шәкертләр бу вилаятьләргә сәфәр кылыр булдылар. Бу шәкертләрдән кайберләре, фәннәр һәм яңа белемнәр алгач, бу мәмләкәткә кайтканнан соң, гомуми бер уянуга сәбәп булдылар.

Ислам мәмләкәтләреннән Коръән һәм хәдис гыйлемнәре алып кайтучылар нисбәтендә, схоластика әүвәлге куәтеннән төшеп, моның урынына шәригатебезнең нигезе булган сөннәт гыйлемнәре килде. Схоластика тәэсиреннән таралган бозык әхлак, тиз генә бетмәсә дә, иншә Аллаһ (Аллаһ теләсә), киләчәк көннәрдә әкренләп бетәр булса кирәк.

Моннан аңлашылганча, мәмләкәтебездә хәдис гыйлеме яңа бернәрсә. Кагыйдәләре һәм ысуллары белән шөгыльләнү якынча һиҗри буенча ундүртенче йөз башыннан башланган. Шуның өчендер ки, китап (Коръән) һәм сөннәт, рәсүлуллаһ һәм сәхабәләрнең тормыш юллары турындагы гыйлемнәрдә мәмләкәтебезнең карт галимнәренә караганда яшьләре алда. Моңа шөбһәсе булганнар үзләре тәҗрибә итеп күрерләр яки күренгән тәҗрибәләр белән канәгать булырлар. Яшьләр арасында «Сахих»ны түгел, хәтта тулысынча «Көтебе ситтә»не күреп, укып чыккан затларга очрар.

Мәмләкәтебездә җитди рәвештә хәдис гыйлеменә хезмәт итүчеләрнең остазы, безнең белүебезчә — Галимҗан Баруди хәзрәтләре булса кирәк. Бу зат «Көтебе ситтә»нең имамы булган «Җамигъ әс-сахих» китабын дәрес бирү программасына кертеп, үзе даими рәвештә укыткан, хәтта ки берничә тапкыр укып чыккан һәм гүзәл шәкертләр җитештергән.

[2] Хәзерге ел исәбе белән XIX гасыр азагы.

Мәдинә Мөнәввәрәдә хәдис-шәриф мөдәррисләреннән булган Сәйид Мөхәммәд Гали әз-Заһири әл-Мәдәни әл-Витри 1314 (1896) елда мәмләкәтебезгә килгәч, түгәрәккә утырып биргән дәресенә бик күп шәкертләр, мөгаллимнәр, имамнар, мөдәррисләр җыелып, хәдис-шәриф тыңлыйлар иде һәм бу мөбарәк гыйлемнең ләззәтен хыялый татып калдылар. Югарыда күрсәтелгән хәзрәтләре бу сәфәрендә Бохара шәһәренә дә барып, анда хәдис мәҗлесе булдырырга килешүгә ирешә, өмет итмәгән җирдә бер күркәм сөннәт калдырып китте.

Инде бүгенге көнебездә дини мәдрәсәләребезнең күбесендә Коръәншәриф һәм хәдис гыйлемнәре гомуми бер рәвештә дәрес буларак укытыла. *«Һәрнәрсәдә бер генә тыю булса, гыйлемдә [күп] тыюлар»*, — дигәннәр. Аллаһ Тәгалә күктән булган афәттән һәм җирдәге бәлаләрдән сакласын! Халкыбызның белем алуга теләге һәм мәхәббәте көннән-көн артсын!

ЙОМГАК

Ислам дине иҗтимагый тормыш өчен кирәкле булган гыйлемнәрне уку һәм укытудан тыймый түгел, хәтта, киресенчә, рөхсәт итә. Шуның өчен изге галим булуның сәбәбе булган гыйлемнәрне һәм һөнәрләрне ислам шәкертләре укыган вакытта һәм укыган җирләрдә ала белерләр. **Шәригатебез гыйлемле эт белән гыйлемсез этләрне бер хөкемдә санамаган, бәлки, әүвәлгесенә кайбер өстенлек биргән.** Инде адәм балаларына ни калды?! Бу сүзләребез, югарыда да әйттек, дөньяви гыйлем һәм мәгърифәт хакында. Әмма дини гыйлемнәрне алу ниятендә булганнар өчен иң беренче максат Коръән һәм хәдис-шәриф гыйлемнәрен өйрәнү тиешле булса кирәк. Галәмнәрнең горурлыгы һәм җан ияләренең патшасы булган әфәндебез хәзрәтләре: *«Сезгә ике нәрсә калдырдым, әгәр шуларга ябышсагыз, һич адашмассыз, ул — Аллаһының китабы һәм рәсүленең сөннәте»*, — дип боерган (Җамигъ бәян әл-гыйлем. — Б.168-217).

Коръән һәм хәдис гыйлемнәреннән мәгълүматы булмаган адәм үзенең тоткан шәригатен аңлы рәвештә ничек белсен?! Сәхабәләргә, табигыйннарга, изге сәләфләргә нинди җеп белән мәхәббәт багласын?! Хөрмәтле рәсүл хәзрәтләренең сира-шәрифәсе (тормыш юлы), әхлагы һәм күркәм гадәтләре белән ничек таныш булсын?!

Аннан-моннан ишетелгән яки атаанага һәм башкаларга иярү сәбәпле багланган ихласы нигезсез һәм мәхәббәте дә көчсез булыр. Хәләл һәм хәрам гыйлеме кирәк булса, Коръән һәм сөннәттә; әхлак гыйлеме кирәк булса, башы боларда; сира (пәйгамбәрнең тормыш юлы) гыйлеме кирәк булса, тагын боларда.

«Фикыһ китаплары төзелү сәбәпле, хәдис гыйлеменә ваемсызлык хасил булды, фикыһ китапларын укыган адәмнәрнең хәдис китаплары белән шөгыльләнергә хаҗәтләре калмады» — дигән кемсә бик хата сөйли. Чөнки фикыһ китабында дөньядагы вакыйгаларны ихтимал тотмаган мәсьәләләр күп булса да, монда булган мәгълүмат, хәдис китапларына нисбәт белән, бик аз. Никадәр хәдисләр, хәтта мөҗтәһидләр ишетмәгәннәре риваять ителә. Хәдисләрнең аерым мәсьәләләргә караган өлешләре булган кебек, тарих, әхлак, ахирәттә булачак бәхеткә һәм бәхетсезлекләргә караган бүлекләре дә бик күп. Хәлбуки, аерым мәсьәләләрдән башкалары фикыһ гыйлемендә телгә алынмый.

Бер гыйлем, әгәр дә аның асылы галәмнәрнең горурлыгы булган әфәндебез хәзрәтләренең эшләреннән, сүзләреннән гыйбарәт булса, нәтиҗәсе дә дөньяда һәм ахирәттә бәхеткә тоташу булса, аның кирәклеге хакында сүз сөйләргә хаҗәт юк.

Текстны басмага ***Айдар Гайнетдинов*** *әзерләде.* ■

ӘХЛАК

К. Бикколый, Г.Госмани

Авыл мәчете. XX гасыр уртасы

КҮРШЕ ХАКЫ

Күркәм эшләрнең иң гүзәле вә иң саваплысы, изге холыкларның бик олугы — күршеләрне хөрмәт итү, күршелек хакын җиренә җиткерүдер. Гакыллы вә күркәм холыклы булган кеше һичбервакыт күршесен рәнҗетмәс, даими алар хакында изгелектә, күркәм мөгамәләдә булып, рәсүлнең сөннәтен җиренә җиткерергә тырышыр. Пәйгамбәребез: *«Бер кеше Аллаһы Тәгаләгә вә аның рәсүленә иман китерсә, күршесен хөрмәт кылсын»*, — дигән. Күршесе мөселман вә башка дин кешесе булсын, аңа хөрмәт кылу мөселман кешенең бурычыдыр. Изге вә күркәм холыклы балалар күршеләрен үз кардәше кеби күрерләр. Адәм балаларының һичкайсын рәнҗетү ярамас. Күршене рәнҗетү бигрәк тә холыксызлыктыр. Сез, балалар, күршеләрегезгә яхшылыкта булып, яхшы исем алырга тырышыгыз.

ИСРАФ

Һәрнәрсәне кирәгеннән артык кылу, тапкан малны юк урыннарга туздыру — исрафтандыр.Исраф исә шәригатебездә бик зур гөнаһлы, бик яман эштер. Ис-

Дәвамы. Башы журналның 2014 елгы 9 нчы санында.

раф кылучы һичбервакыт бай булмас. Ул никадәр мал тапса да, урынсыз җирләргә сарыф кылып, фәкыйрь, мохтаҗлыкта калыр.Ахырында кеше ишеге төбендә йөреп, хурлыкка төшәр. Аңа һичкем ярдәм кылмас, аны һичкем аямас. Ул тапса да бетерә, малны юк итә, акчасын урынсыз җиргә әрәм итә, яхшылыкның кадерен белми.Аңа биргән мал да җилгә генә китә, дип һәркем аңа ләгънәт укыр. Шәфкать вә яхшылык итмәсләр. Соңрак, мондый кеше тәмам гаҗиз булыр, урлау, алдау, хыянәт кылу кебек кабахәт эшләр кылырга өйрәнеп, олуг гөнаһлы эшләр кылып, дөнья вә ахирәт хурлыгына төшәр. Аллаһы Тәгалә хәзрәтләре: *«Исраф кылучылар — шайтаннар кардәшедер»*, — диде. Шайтаннарга якын булудан да яманрак ни булыр?.. Сез, балалар, исраф кылудан бик саклана күрегез. Кирәгеннән артык ашау-эчү, кием-салымда да тиешлесеннән артыклык кылу ярамыйдыр. Боларга сарыф кылган мал бар да җилгә китәр. Андый урынсыз чыккан мал, аз-аз гына булса да барын бергә җыйгач, бик күп булыр. Ул мал илә никадәр яхшы эшләр кылып булыр! Тиешсезгә юмартлык кылуың өчен һичкем сине мактамас, беркем дә рәхмәт әйтмәс, бәлки ахмак, чамасыз, дип яманатыңны гына сатарлар. Мәшәкать илә табылган газиз малны сарыф кылып, яманат ишетүдән дә артык яманлык юктыр. Гакыллы, күркәм холыклы кешеләр һәрвакыт изге исем калдырырга тырышырлар.

Исраф кылучы һичбервакыт бай булмас. Ул никадәр мал тапса да, урынсыз җирләргә сарыф кылып, фәкыйрь, мохтаҗлыкта калыр.

ИЗГЕЛЕК

Күркәм сыйфатларның иң яхшысы, мактауга лаеклы әхлакның да иң сөемлесе — изгелек кылудыр. Пәйгамбәребез: *«Адәмнәрнең изгерәге адәмнәргә изгелек кылучы, файда итүчерәгедер»*, — дигән. Изгелектә булып гомер иткән кеше үлсә дә, теректер. Ягъни аны һәрвакыт адәмнәр яхшылык илә зикер итеп, аның изгелекләрен сөйләп рухын шат итәрләр. Һичвакыт аны онытмаслар, хәтердән чыгармаслар. Кешегә изгелек итү һичвакыт җирдә калмас. Кирәк мал илә юмартлык кылып изгелек ит, вә кирәк кул вә куәтең илә, вә кирәк яхшы тел вә нәсыйхәтләрең илә изгелек кыл. Барчасы күркәм сыйфатлардан, яхшы холыклардандыр. Берәү кешегә изгелектә булса, Аллаһы Тәгалә һәрвакыт аңа ярдәмдә булыр. Сез, балалар, изге сыйфатлар илә сыйфатланып, яхшы исем илә гомер итеп, үлгәч тә хәер илә зикер ителик дисәгез, кешегә тиюдән, кул вә телегез илә кешеләрне рәнҗетүдән, барча явыз, ярамас холыклардан сакланып, күркәм холыклар илә холыкланырга кечек вакыттан ук гадәт итегез. Кечек вакытта өйрәнгән холыклар, нинди булса да, үлгәнче сездән аерылмас. Яхшылыкка өйрәнсәгез, бөтен гомерегезне яхшылыкта уздырып, мәңге онытылмаслык изге исемнәр алырсыз. Вә әгәр кечек вакытта яман холыкта булсагыз, картайгач, никадәр мәшәкатьләнсәгез дә, аны ташлап изгелектә була алмассыз.

Дөньяда рәхәт яшәүне теләгән адәмнәр изге күңелле, башкаларга да изгелек итүче булырлар. Изге күңеллеләрнең, башкаларга изгелек итүчеләрнең һич эчләре пошмас. Даими рәхәттә дөньяда гомер сөрерләр. Изге күңелле адәмнәр Аллаһы Тәгаләгә вә бәндәләргә булган бурычларны башкарырлар. Шуның өчен күңелләре газапланмас. Тәндә булган әгъзаларның берәрсе авырса, бөтен тән хәстә булыр. Шуның кебек, адәм балаларының беренә кайгы-хәсрәт килгән вакытта, адәмнәрнең һәркайсы бергә кайгырышырга, хәсрәтләрне уртаклашырга тиешледер. Бу исә изгелек итү булыр.

Халык каршында сөекле булуны һәркем теләр. Ләкин сөекле булу өчен бер генә юл бар. Ул исә башкаларга изгелек итү булыр. Изгелек итүчеләрне һәркем яратыр вә мәхәббәт итәр. Сез, балалар, яшь вакытыгыздан ук кешегә изгелектә булырга тырышыгыз! Чөнки бабаларыбыз: *«Яшь вакытта өйрәнгән нәрсә ташка язылган кебидер»*, — дигәннәр. Ташка язылган нәрсә һичвакыт яңгыр, җил вә тузан кебиләр илә югалмый, ничә мең еллардан соң да калыр.

Тиешсезгә юмартлык кылуың өчен һичкем сине мактамас, беркем дә рәхмәт әйтмәс, бәлки ахмак, чамасыз, дип яманатыңны гына сатарлар.

УГРЫЛЫК

Угрылык — һәрбер милләт каршында да иң явыз сыйфат, иң яман холыклардандыр. Аллаһы Тәгалә үзе сакласын мондый яман эшкә гадәт итүдән.Андый кешенең угрылыгы мәгълүм булса, ул кешене адәмнәр арасында хур итеп төрмәгә ябарлар, Себер җибәрерләр. Кыяматкә кадәр начар исемдә калыр. Сез, балалар, кечек вакытыгыздан ук мондый ярамас холыкны өйрәнүдән бик саклана күрегез.

Угрылык башта бик кечек нәрсәдән башланса да, соңрак өйрәнә-өйрәнә бик зураядыр. Мәсәлән, яшь вакытта мәктәптә бер кешенең каләм, карандаш, пәке кеби нәрсәләрен сораусыз алсагыз, икенче мәртәбә аннан да зуррак нәрсәләрне алып, яман гадәткә өйрәнеп, харап булырсыз. Сабакташ балалар сезне яннарына китермәс, карак, угры, дип хурларлар.Хәлфәгез дә сезне яратмас, сездән сакланыр. Сезне бүлмәсенә кертергә дә шикләнер. Моның өчен ата-аналарыгызның да йөзе кызарып сезгә рәнҗерләр. Бәс, балалар, тугры исем чыгарырга тырышып, сораусыз кеше нәрсәсенә кул сузмагыз, кечкенә генә нәрсә булса да. Яшерен рәвешчә кеше нәрсәсен алу — хыянәт, угрылык булып, яман холыклардандыр. Яманат илә йөргәнче үлүең мең мәртәбә артыктыр.

СЕР САКЛАМАУ

Кешенең яшерен серен күреп яки ишетеп тә аны эчеңдә сакламый адәмнәргә фаш итеп сөйләп йөрү — бик яман вә ярамас холыклардандыр. Адәмнәрнең серен сөйләп йөрү гаурәтләрен ачу илә бәрабәр. Гакыллы кеше, һичвакыт карендәшенең гаурәтен ачарга риза булмас. Сер сакламый торган кешенең адәмнәр арасында һич кадере калмас. Аның авызында сүз тормый, дип, ул кешене киңәш мәҗлесләренә кертмәсләр, аның янында сүз сөйләмәсләр, сөйләшеп торган җиргә барса да, фәлән килде, сакланыгыз, сүзегез дөньяга җәелер, дип, сүзләрен туктатып, бу кешене мәсхәрә итәрләр. Ул кеше игътибардан төшәр, ышанычсыз булып калыр. Һәм аның күп сүзләренә ышанмаслар, ул сүз йөртүче, ул шайтан ялчысы, кеше боздыручы, дип, аңардан нәфрәтләнеп, яхшы кеше аны янына китермәс. Шулай итеп, мондый сүз йөртүче дөньялыкта күп дусларыннан аерылыр, яман холыклы кешеләрдән булып калыр. Кешеләргә хыянәт итүе өчен ахирәттә дә олуг газапка дучар булыр. Чөнки кешенең серен кешегә сөйләү — хыянәт кылудыр. Мондый явыз холыклардан бик саклана күрегез! Аеруча үзегезне дөрес вә якын күреп сер сөйләсәләр, аны үлгәнче эчегездә саклагыз, дустыгызның серен сөйләп йөзен кызартмагыз! Бу эш шәригатебездә дә бик зур гөнаһ вә ярамас эштер.

ИНТИКАМ (ҮЧ АЛУ)

Бер кешегә ачу итеп, аңардан үч алыр өчен аның зарарына эш итү — бик явыз холыклардандыр. Кеше сиңа

теле яки кулы илә җаныңа тиярлек эш кылса, нәфесеңә булышып, син аңардан кару кайтарырга* тырышма, бәлки аның файдасында бул. Кеше сиңа никадәр зарар итсә дә, син яхшылыкта булсаң, шаять бервакыт ул инсафка килер. Әгәр ул инсафка килми, даими сиңа усаллыкта булса да, аның инсафсызлыгына карап син инсафсыз булма. Бабаларыбыз: *«Яхшылыкка — яхшылык һәр кешенең эшедер, яманлыкка — яхшылык ир кешенең эшедер»*, — дигәннәр.

Бәс, гакыллы вә чын ир кеше буласың килсә үч алу, кару кайтару дигән нәрсәне хәтереңә дә китерми, галиҗәнап олуг ир-егет булырга тырышыгыз. Олуглык күркәм киемнәр кию, яхшы ашамлык җыю илә булмыйча, күркәм холыкта, изге сыйфатта йөрү илә булыр. Мөселманлык яманлыкны оныту, яман холыклардан ерак булудан гыйбарәттер. Кешедән үч алу исә үзең кеби адәм баласына усаллык нияте итү — аның һәлак булуын теләүдер. Бу исә мөселманлыкка гына түгел, инсанлыкка да ярамас. Мондый сыйфатлардан ерак булыгыз!

АШЫГУ

Һәр эштә сабырсызлык итеп эшнең ахырын уйламый, ягъни яман булуын тикшерми эш кылу — бик начар холыклардандыр. Һәр эштә дә сабыр вә вәкарь булу кирәктер. Бер сүзне ишетсәк, әүвәл ул сүзнең гакылга охшап-охшамавын тикшерми, дөрес вә ялган булуын уйламый ышанырга да, ялганга чыгарырга да ашыгып җавапка керешмә, оятка калырсың! Шулай ук, үзең бер сүз сөйләсәң дә, ашыгып авызга килгәнне әйтә биреп адәмнәр алдында көлкегә калма. Сөйлисе сүзеңне әүвәл күңелдән кичереп, гакылга ярашлымы, түгелме идеген игътибар кылып, бер дә ашыкмый, һәркем аңларлык итеп, сабырлык илә генә ачык итеп сөйләргә гадәт ит. Шулай ук, бер-бер эш кылсаң да, *«Тисә — тияккә, тимәсә — ботакка»* дигән кеби алдың-артың исәпләми ашыгып эшләмә, үкенечтә калырсың. Бабаларыбыз: *«Ашыккан — ашка пешәр»*, — дигәннәр. Бик дөрес сүздер. Ашыгычлык һичвакыт хәер китерми, зарар вә үкенечкә генә китерер. Шуның өчен пәйгамбәребез: *«Ашыккан — шайтаннан, сабырлык — Аллаһы Тәгаләдән»*, — дигән. Күрә торгансыздыр, олуглар һичвакыт ашыгып, каушап эш кылмаслар, һәр эшне сабыр, вәкарь илә генә кылып, яхшыны яманнан, хәерне начардан аерып эшләрләр. Безгә олугларга иярү тиештер. Ашыгу-каушау күпвакыт адәмне һәлак итә. Мәсәлән: бер начар хәбәр килсә, аннан куркып яки кайгырып «уф-ах» дип, үзеңне-үзең әллә нинди куркынычлы авыруга салу ихтималы була. Яки мондый вакытларда ашыгып, каушап, сикереп, чабып, егылып утка-суга төшеп харап булуың ихтимал. Чын кеше һичнәрсәдән курыкмас вә һич дөнья бәласе өчен кайгырмас. Андый куркынычлы хәбәрләр ирешкәндә, сабырлык илә генә каршы алып, эшнең әүвәлен вә ахырын күңелдән кичереп, әүвәл акрын гына чарасына керешеп, мөмкин булмаса, хәерле булсын, Аллаһ ярдәм бирер әле, дип Аллаһка тапшырып сабыр итәр. Мондый кешеләр — чын кешеләрдер. Болар һичвакыт юкны кайгыртып үзләрен харап итмәсләр, тиешсезгә ашыгып, вакытсыз картаймаслар. Бәс, балалар, сез дә яхшы вә күркәм холыклы буласыгыз килсә, җир вә торуларыгызда, эш вә хезмәтләрегездә олугларга ияреп, алар холкында булырга тырышыгыз. Сабырлык — пәйгамбәрләр, изгеләр сыйфатыдыр. Әмма ашыгу-каушау — шайтан сыйфатыдыр. Башында гакылы булган кеше, әлбәттә, изгеләр холкыннан аерылып, шайтан сыйфатына кермәс, ничек тә олугларга ияргә тырышыр. Сез, балалар, моны бик игътибарга алып, һәр эшегездә сабырлы булыгыз.

Текстны басмага ***Ленар Гобәйдуллин*** *әзерләде.*

*Кару кайтару — үч алу.

ЮГАЛМАСЫН ҖИРДӘ ЭЗЛӘРЕ...

Әрибә Айтуганова

МӘҢГЕ ЕГЕРМЕ БЕР ЯШЬЛЕК АБЫЕМ

Абыем Ягъсубның каберен аның сугыш кырында батырларча һәлак булуына 70 ел тулып килгәндә таптым. Шатландым да, сагышландым да, бу якты дөньядан бик яшьли китүгә карамастан, җирдә лаеклы эз калдыра алуы белән горурландым да. Күңел түрендә саклаган хатирәләр яңарды.

Ягъсуб абый Айтугановлар гаиләсендә 1921 елда, икенче бала булып дөньяга килә. Әнкәебез Әминә Ягъсуб абыйны сентябрьдә туды, дип әйтә иде, әмма көне хәтерендә калмаган. Документларында (аттестат, хезмәт кенәгәсе һ.б.) да елы гына язылган. Көне юк.

1930 елның көзендә Ягъсуб башлангыч мәктәпкә укырга керә. Ул вакытта ул инде укый-яза белгән була. Шуңа күрә аны, бер чирек укыганнан соң, икенче сыйныфка күчерәләр. 1919 елгы Нәкыйп өченче сыйныфта була бу чакта. 1933 елда Ягъсуб башлангыч мәктәпне тәмамлый, көзен Девәтернә тулы булмаган урта мәктәбенә (җидееллык ТБУМ) күчә. Алар Нәкыйп абый белән бергә бара. (ТБУМ 1933 елда ачыла, шуны көтеп Нәкыйп абый бер ел укымый тора.) Анда өч ел укып, икесе дә 1936 елда мәктәпне «бик яхшы» билгеләренә тәмамлыйлар. Шул елларда Ягъсуб абый кыска хикәяләр, шигырьләр язу белән дә шөгыльләнә. Язганнарының кайберләрен Красный Бор район газетасы — «Колхоз ярышы»нда бастыра.

Ягъсуб укытучы булырга хыяллана. 1936 елның көзендә әткәебез Мөхәммәткәрам үзенең ике улын һәм авылның тагын өч егетен ияртеп Казанга укырга кертергә бара. Алар барып җиткәндә педагогия техникумына алу төгәлләнгән була. Шуңа күрә, бик теләп булмаса да, Ягъсуб белән Җәвит исемле егет документларын Совет сәүдә техникумына (Карл Маркс урамы, 9 йорт) тапшыра. Техникумны икесе дә 1939 елда тәмамлыйлар.

Ягъсуб техникумда укыганда, 1937 елның ноябрендә, комсомолга керә, җәмәгать эшләрендә актив катнаша, отличник, группаның комсомол җитәкчесе була. Техникум юлламасы

[1] Ахыры. Башы журналның 5 нче санында.

буенча 1939 елның 15 августында Гастрономнарның Республикаара конторасында икътисадчы булып эшкә урнаша. Анда алты ай эшләгәннән соң, үзенең балачак хыялына тугрылык саклап, 1940 елның мартыннан укытучылар хәзерләү курсларында белем эсти. Августта аны тәмамлап, Казан педагогия институтының физика-математика факультетына читтән торып укырга керә. Красный Бор РОНОсына укытучы итеп тәкъдим ителә. Мәгариф бүлеге аны Нарат авылыннан алты чакрымдагы Үтәгән авылы мәктәбенә физика-математика укытучысы итеп билгели. Сугышка киткәнче (1942 елның октябре) шунда эшли.



Айтуганов Ягъсуб. 1941 ел

Ягъсуб абый кечкенәдән үк бик шаян, шук, җор телле, зирәк бала була. Бер колагының начаррак ишетүен дә әнкәй шуның белән аңлата иде: кечкенә чакта чабып йөргәндә башын күмер чүлмәгенә бәрә... Аның минем хәтердә калган шуклыклары да шактый. Ул уйнарга чыкканда гел аңа иярәсем килә, ә ул ияртергә теләми, төрле хәйләләр уйлап таба. Берсендә, өй тәрәзәсе аша чыгып качканда, үзе белән бергә тәрәзәне дә рамы-ние белән кубарып алды. Пыяла чәчелгән тавышка йөгереп килүебездә Ягъсубтан җилләр искән иде инде. Көне буе өйдә күренмәде, төнлә эзләп кенә алып кайттылар.

Сугыш алдыннан, Үтәгән мәктәбендә укытканда, ялларын өйдә уздырды. Дуслары белән авылда спектакльләр, концертлар куеп йөрде. Ул чорда Мифтахов Сәхәветдин белән дус иде. Сәхәветдин дә, үзе кебек, оста гармунчы иде. Бервакыт болар кызларга шаян мәхәббәт хаты язган да, авыл советына барып, шуңа мөһер (печать) суктырганнар. Кызларның һушы киткән! Кызыгы шул: ул вакытта секретарь булып эшләгән Наһарттәй укый-яза белми иде, болар сүзенә ышанып, әһәмиятле документ дип, шалт итеп мөһер баскан. Алар икесе дә 1942 елның язында сугышка китте. Икесе дә әйләнеп кайтмады. Сәхәветдин 1943 елның 14 февралендә Ленинград фронтында һәлак булган.

1940-1941 елларда Ягъсуб абыйны берничә мәртәбә училищега хәрби хезмәткә җибәрделәр. Соңгы мәртәбәсендә — Куйбышев (Самара) шәһәрендәге хәрби очучылар училищесы иде. Анда баргач, шул колагы аркасында борып кайтардылар. 1942 елның апрелендә сугышка алдылар. 25 июльдә ахыргы хаты килде. *«Бүгенгә исән-сау, иртәгә әйтә алмыйм»,* — дигән сүзләр бар иде. Үзе турында урысча язганнан соң, татарча болай дип өстәгән: *«Тату торыгыз. Әрибә,*

Айтуганов Нәкыйп.
1945 ел

Юв. Вх №-03788
31.3.45 Н

Все графы заполнять полностью

...АДНОЙ ЛИСТ

...туганов Николай Кириллович

3. Должность, часть Командир батареи ...ого противотанкового дивизиона ...ской дивизии.

...ександра Невского"

...ональность татарин. 6. Партийность чл. ВКП(б) с 1943 г.

...оследующих боевых действиях по защите СССР и в

...а) В Отечественной войне: Южный фронт с 3.10.41 по 26.12.41 г. ... Западный - 3 Белорусский фронт с 12.7.43 года.

...Отечественной войне Ранен. 26.12.41 г.; 10.9.42 г.

...мии с 1939 года. 10. Каким РВК призван

...к Татарской АССР.

...личия) медалью "За оборону Сталинграда" У/н 295137. ... от 19.12.43 г. орденом "Красная звезда" приказом 31 армии ... приказом по 36 ск №0119/н от 29.10.44 г. орденом Отечест. войны ... 042 от 27.2.45 года.

...ставляемого к награждению и адрес его семьи

...ткое конкретное изложение личного боевого подвига или заслуг

...Айтуганов Н.К. работая командиром батареи прошел боевой ...епра до Восточной Пруссии, показывая пример управления ...сочетанием личной отваги.
...последних боях по уничтожению восточно-прусской группи... ...тареей уничтожено 4е 75мм орудия, 9 пулеметов и ...ерцев, подавлен огонь одной минометной батареи и ...точек. Действуя все это время (с 13.03. по 21.03.45 г.) ...ких немцев и ведя огонь только прямой наводкой ...ее, капитан Айтуганов сумел с малыми потерями ... большой урон противнику. Его батарея при зах... ...х пунктов Хайсвальде и Рефельд врываясь ... наводя страх и смятение среди гитлеровцев. ... отважен. В любых условиях и видах боя бата... выполняет поставленную задачу.
...ительственной награды ордена Александра Невского.

Командир 179 ОИПТД
майор ... /Сухоруков/

...о о награждении орденом "Александра Невского" ...отличившийся 174 стрелковой дивизии
...дир (начальник) ...
Полковник (звание) ... /Мишин/



205

Обязательно все графы заполнять полностью.

НАГРАДНОЙ ЛИСТ

Фамилия, имя и отчество Айтуганов Ягсуф Каримович
Воинское звание Рядовой
Должность, часть Стрелок 2ой стр. роты 1го О.С.Б. 257 отд. стр. Бригады

Представляется к медали "За отвагу"

1. Год рождения 1921 2. Национальность Татарин
3. С какого времени состоит в Красной Армии с III-1942 4. Партийность чл. ВЛКСМ
5. Участие в боях (где и когда) с 11-16.08.42 в районе дер. Перерум Запад. фр.
6. Имеет ли ранения и контузии Не имеет
7. Чем ранее награжден (за какие отличия) Ранее не награждался
8. Каким РВК призван Красноборским Р.В.К., Татарской А.С.С.Р.
9. Постоянный домашний адрес (представляемого к награждению или его семьи)

I. Краткое, конкретное изложение личного боевого подвига или заслуг

За время боев с 11-16.08.42 ходил несколько раз в контр-атаку и в общей сложности уничтожил 12 гитлеровцев.

Командир 1 ОСБ капитан ... Военком ...

Әдилә, сез эшләгез, әнкәйне борчымагыз. Ләбиб, артык иркәләнмә. Ә сез, Әрибә, Әдилә, Ләбибне какмагыз. Ярый, хушыгыз. Пока, до свидания. С желанием чтобы приехать домой с победой. Ваш сын и брат Ягсуб. 25 / VII — 42 г»[2]. Мин бу хатны бүгенгәчә кадерләп саклыйм.

Шуннан соң ике айдан артык хаты булмады. Ноябрь урталарында әнкәй исеменә Аерым чаңгы бригадасы идарәсе исеменнән белешмә килде. Анда кызылармеец Айтуганов Ягъсуб Кәрам улының «Батырлык өчен» медале белән бүләкләнүе хәбәр ителгән иде.

Бу белешмәне алгач та, без аларга Ягъсубның хаты-хәбәре юклыгын, аның турында тикшереп, нинди дә булса мәгълүмат җиткерүен үтенеп хат яздык.

1942 елның декабрь азакларында җавап алдык. Алар безгә Ягъсуб абыйның 25 августта Ватан өчен сугышта каһарманнарча һәлак булуын хәбәр итте. Рәсми извещение дә җибәрделәр. Анда да шул ук сүзләр: *«Айтуганов Ягъсуб Карамович в бою за Социалистическую Родину, верный воинской присяге, проявив геройство и мужество был убит 25 августа 1942 г., похоронен у деревни Передель, Ульяновского р-на, Орловской области»*. «Ай, шушы сугыш чыкмаса, абыебыз егерме бер яше тулар-тулмас җир куенына керер идемени!» — дип үксеп-үксеп елавыбызны хәтерлим...

Мин дистә еллар буена Ягъсуб абыйның каберен эзләп, үлгән хәбәрендә күрсәтелгән адреска — Орёл өлкәсенә, авыл советларына, мәктәп һәм музейларга хатлар яздым. Җавап алмадым. Бары тик 1997 елда Татарстанда «Хәтер китабы» чыккач кына белдем: Ягъсуб абый җирләнгән урын хәзер Орёл түгел, Калуга өлкәсенә керә икән. Инде хатларымны шунда юллый башладым. Ниһаять, 2012 елның 29 мартында миңа Калуга өлкәсе хәрби комиссариатының гражданнар белән эшләү бүлеге начальнигы В.Неведомскийдан мондый хат килеп төште. «На Ваше обращение сообщаю, что согласно учёту погибших и захороненных на территории Калужской области в существующих границах значится: «Айтуганов Якуп (Ягсуб) Карамович (1910 (1921) — 25.08.1942), красноармеец, 51 отдельная лыжная бригада, 61 А, родился: Татарстан, с. Сосново, призван: Красноборский РВК Татарстана, погиб: Ульяновский район, д. Верхняя Передель. Перезахоронен в братскую могилу с. Уколица Ульяновского района Калужской области».

Хатта мондый мәгълүмат та бар: Уколица авылындагы туганнар каберлегенә 2963 сугышчы күмелгән. Каберлек биредә 1956 елда барлыкка килгән. Аңа һәлак булган сугышчыларны тирә-юньдәге Блиново, Громоздово, Краснополье, Передель, Уколица һәм тагын унбишләп авыл янындагы аерым каберләрдән, кечкенәрәк туганнар каберлекләреннән күчереп җирләгәннәр. Һәйкәл куйганнар. 2001 елда ул һәйкәл яңартылган: «Здесь захоронены воины Советской Армии, погибшие в боях с немецко-фашистскими захватчиками при освобождении Ульяновского района в 1941-1943 годах». Ул елларда биредә аеруча аяусыз, каты сугышлар барган.

Хатка туганнар каберлегенә ничек барырга икәнлеге дә язылган. Бәлки, Ходай кушып, шул җиргә барырга, абыем рухына дога кылып кайтырга насыйп булыр әле, дип яшим. Һәрхәлдә, абыемның җәсәде үз вакытында ук җир куенына кергән. Миңа моны белү мөһим. Исемлекнең «А» хәрефенә башланган фамилияләр кергән бер өлешен дә җибәргәннәр, араларында татар фамилияле яки сугышка Татарстаннан киткән кешеләр дә бар. Күчермәсен «Безнең мирас» редакциясенә дә җибәрәм — бәлки, кем дә булса үзенең озак еллар эзләгән туганын табар...[3]

[2] Хатлар, документлар оригиналдагыча бирелә.
[3] Күчермә редакциядә саклана. Кызыксынучылар булса, мөрәҗәгать итегез.

ҖИҢЕП КАЙТТЫ

Нәкыйп абыебыз исә Кенигсбергка кадәр барып җитеп, каты яраланып, сугышта бер аягын калдырып булса да исән кайтты, җиңеп кайтты. Батырлыгы өчен Кызыл Йолдыз ордены, I һәм II дәрәҗәдәге Ватан Сугышы орденнары, Александр Невский орденнарына лаек булган иде. Медальләре сигезгә тула. Шулар арасында — «Батырлык өчен», «Сталинград оборонасы өчен»…

Ул 1919 елның 14 июнендә хәзерге Актаныш районының Иске Бикчәнтәй авылында туган. (Айтугановлар гаиләсе шушы яклардан Әгерҗе районына 1929 елда гына күченгән.) 1940 елның 1 февралендә, яше җитеп, армиягә алынган. Бераз вакыт Украинада, Винница өлкәсенең Хмельник шәһәрендә хезмәт иткән. Аннан артиллерия училищесына җибәрелгән. Аны 1942 елның гыйнварында тәмамлаган. Шуннан соң лейтенант Айтуганов үзенә часть җыю өчен Башкортстанга, Красноусольск шәһәренә җибәрелгән һәм шул часть командиры булып сугышка киткән.

Беренче мәртәбә утка 1942 елда, Көньяк фронтта, Миус һәм Дон елгалары буенда кергән. Сталинград оборонасында катнашкан, атаклы трактор заводы өчен сугышта каты яраланып, госпитальгә эләккән. Терелгәч, кабат фронтка киткән, аннан соң тагын берничә тапкыр җиңелчә яраланып, госпитальләрдә ятып, кире яуга киткән. Капитан званиесе биргәннәр. Фронтта аны, татарча исемен әйтү кыен санап, күрәсең, Николай Кириллович дип йөртә башлаганнар. Хәрби документларында да шулай язылган. 1943 елдан башлап Өченче Белоруссия фронты составында сугышкан, танкка каршы батарея командиры булган, Смоленск өлкәсен, Белоруссияне, Польшаны, Көнчыгыш Пруссияне азат итүдә катнашкан.

1945 елның апрель азагында Кенигсберг (хәзерге Калининград) шәһәре янында аларның полкы чолганышта калган. Командирлары һәлак булгач, капитан Айтуганов командалык итүне үз өстенә алган һәм аны, полк байрагын да югалтмыйча, чолганыштан алып чыккан. Бу сугышта ул сул аягын югалткан һәм Тбилиси шәһәренә госпитальгә озатылган.

1945 елның декабрь аена кадәр дәваланганнан соң ул, II группа инвалид булып, Нарат авылына кайтты. Бер елдан Татарстанның Красный Бор районы статистика идарәсе инспекторы итеп билгеләнде, 1948 елның декабреннән Красный Бор РК ВКП(б) инструкторы булды. 1950 елда үз авылына — Карл Маркс исемендәге күмәк хуҗалыкка рәис итеп җибәрелде. Колхозлар берләштерелгәч, рәис урынбасары, агроном, бригадир булып эшләде. Нәкыйп абый тәвәккәл, көчле рухлы иде. Авыр заманнарда яшәде, сугыш ветераны буларак, бүгенге кебек кадерхөрмәт күрә алмады. Сугыш яралары да һич тынгылык бирмәде аңа. Протезлар ул вакытта бик тупас, уңайсыз иде, аягының протез беркеткән җире сызлап интектерде. Ул 60 яшькә җитеп, 1979 елның сентябрендә вафат булды.

Нәкыйп абый ике тапкыр өйләнде, беренче хатыныннан ике кызы Людмила, Лидия һәм улы Владимир хәзерге вакытта Коми республикасында гомер кичерәләр. Аллага шөкер, соңгы елларда күрешеп-аралашып торабыз, алар Нарат авылына кайтып, әтиләре каберен зыярат кылдылар. Икенче хатыныннан туган кызлары Диләрә белән Гөлнара да әтиләренең истәлеген саклап яши.

…Уем гел шулар турында: абыйларым, туганнарым, кадерлеләрем (ә ил буйлап күпме җыела алар!) бүгенге якты көннәрне күрә алмады. Адәм баласы күп авырлыкларны кичерергә мөмкин, ләкин сугыштан да коточкычрак афәт юк. Шуңа күрә, җирдә беркайчан да сугышлар булмасын, Раббым киләчәк буын балаларына безнең кебек әтиләренең, абыйларының каберләрен чит-ят җирләрдән эзләп йөрергә язмасын иде, дип телим. ■

Төп горурлыгы бөек сугышлар, шул сугышларда теләсә кайсы дошманны да бер-бер артлы җиңүләр белән мактанган һәм рухланган бик зур империядә – СССРда үтте без картларның күп гомере... Хәтта ачтан үләрдәй чакларыбызда да коммунистлар партиясенең җиңүләрдән-җиңүләргә алып баруына, тормышны чәчәк аттыруына «куанып» куллар чаптык, ура кычкырдык, аның зирәклегенә мәдхияләр укыдык.

КАДЕРЛЕЛӘР ҺӘМ КАДЕРСЕЗЛӘР

Фәнзаман Баттал

Д.Наурузова коллажы

Ялангач чакларыбызда да КПСС генсекларының портретларын күтәреп, демонстрацияләрдә күкрәк киереп атладык. Бигрәк тә кырык миллионлап халыкны канга батырып җиңгән Бөек Октябрь революциясен, утыз миллионлап халыкның кырылуы белән яуланган Бөек Ватан сугышында җиңүне зурларга өйрәттеләр. Азык талоннары тотып, ипи, ярма, шикәр, тәмәке, аракы, колбаса кебек товарларга су буе чират торган чакларда да ул җиңүләр белән горурландык. Әйе-әйе, башка җәһәттән халыкны куандыра алмаса да, СССР безне «бөек» сугышлар, «бөек» җиңүләр белән рухландырды, «канга — кан, үлемгә — үлем» дигән шигарьләр барыбызны да патриотизм рухында үстерергә тырышты. Һәм патриотлар булып үстек тә! Бөек Ватан сугышында җиңгән буынның уллары Венгрияне, Чехословакияне, Польшаны канга батыру максатына ирештеләр, Әфганстанда ун ел сугыштылар, Вьетнам, Кореяга барып керделәр…

Дөрес, инде ул биниһая зур империя таркалгач, аның урынында Россия генә калгач, кайбер бәйрәмнәр бетте дә… Хәтта Октябрь инкыйлабы да кешелек дөньясындагы зур җинаять дип бәяләнде. Әмма Бөек Ватан сугышы китергән Бөек Җиңүне без елдан-ел тантаналырак, шаулатыбрак үткәрәбез. Быел ул, үзенең 70 еллык юбилеенда, эйфория дәрәҗәсендә бәйрәм ителде: атналар буе шул сугыш турында телевизор каналларыннан бихисап кинолар карап куандык, совет халкының (хәзер инде Россиянең) җиңелмәслеге турында күптөрле пафослы нотыклар тыңладык.

Мин дә читтә калмадым әле. Тарихта, архивларда казынырга яратучы буларак, йөзләрчә документларга нигезләнеп, бу сугышның аерым катлам кешеләренә — язучыларга (дөресрәге, Язучылар берлеге әгъзаларына) тигән зәһәре турында шушы язмамны әзерләдем.

Матбугатка бирер алдыннан бер искәрмә ясап үтәм: язмамны иң әүвәл укыячак мөхәррирләр дә, журналның меңләгән укучылары да язу рәвешемә бәйләнмәсен, «хаталар» табып аптырамасын: текстта да, бер-бер артлы китереләчәк документ күчермәләрендә дә аббревиатураларны (ССП, ТГАП кебегрәк кыскартылган кәлимәләрне), Табаксоюз, райсовет, обком, домоуправ, гостиница кебек атамаларны, урысча сүзләрне дә шул заманча калдыруны, чор рухын саклап калуны хуп күрдем. Хәтта кайбер хатларны да оригиналдагыча калдырдым. Тәрҗемә итә белмәгәннән түгел икәнен үзегез дә сизенерсез…

***

Сугыш башлану хәбәре килеп ирешкәч, илнең барлык ирләре кебек үк, татар язучылары да юлга җыена. Берәүләре — военкомат чакыруы буенча, берәүләре — үз теләге белән фронтка китә. Әлбәттә, башкалар кебек үк саубуллашалар, гаиләләреннән аерылганда елашалар, илне җаннан кыйммәтрәк күреп сакларга вәгъдәләр бирешәләр. Сугыш чорында фронтка 117 язучы китеп бара. Рәсми тел белән әйткәндә, барлык каләм ияләренең 70 проценты… Сугыш башлануга ук «кара хәбәрләр» килеп төшә башлый: үләләр, һәлак булалар, хәбәрсез югалалар…

Ләкин шунысы гаҗәп: сугышның башында ук Казанга, Татарстанга Мәскәүдән урыс һәм башка милләтләрнең язучылары агылырга тотына. Төрле сәбәпләр белән тылда калдырылган безнең язучыларыбызга, дөресрәге, инде бетә язган Язучылар берлегенә телеграммалар, хатлар, күрсәтмәләр, боерыклар ява…

«Сезгә Лев Соломонович Ларскийны җибәрәбез. Сәламәтлегенең торышы аркасында ул Казанда яшәргә мәҗбүр. Аны әдәби эшчәнлектә файдаланыгыз. Сезгә файдалы булыр, дип ышанабыз.

СССР ССП агитация һәм пропаганда бүлеге мөдире Скосырев».

Уң кулның ни эшләгәнен сул кул белми, дигән сыман, бу хатларны СССР Язучылар союзының аппаратында эшләүче һәркем яза кебек. Хәер, башка оешмалардан да агыла алар.

«Сезгә, Татарстанга, РСФСР халык мәгарифе комиссариатыннан аспирантура тәмамлаган Кратова-Лейбович юнәлтелә. Ул талантлы, сәләтле, үз эшен белүче кеше. Яхшы лектор. Горячо рекомендую её Вам.

Мәскәү дәүләт педагогия институтының кафедра мөдире профессор И.Нусинов».


=КАЗАНЬ СОЮЗ ПИСАТЕЛЕЙ
=СРОЧНАЯ КАЗАНЬ БАУМАНА 19 СОЮЗ ПИСАТЕЛЕЙ=
Народный Комиссариат Связи СССР
::СРЧ АРЗАМАСА 2 ПО 1269 30 14 2225
ДЕТИ ЖЕНА ПИСАТЕЛЕЙ НАХОДЯЩИХСЯ ФРОНТЕ ПРЕСТАРЕЛЫЕ ЛИТЕРАТОРЫ ПОЕЗДЕ 1606 ВЕЧЕРОМ ПЯТНАДЦАТОГО БУДУТ КАЗАНИ ТЧК ПРОСЬБА ВСТРЕТИТЬ СВЯЖИТЕСЬ ИСХАКОВЫМ ПРИВЕТ =УПОЛНОМОЧЕННЫЙ ПРЕЗИДИУМА ПАРТКОМА ССП БЕРЕСТИНСКИЙ+

Ответ.секр.Правления ССП ТР:

Секретарь первич. организ.

«Фронттагы язучыларның балалары, хатыннары, карт язучылар поезд белән унбишендә кичке 16 сәгать 08 минутта Казанга киләчәк. Каршы алуыгыз сорала. Исхаков белән элемтәгә керегез. Сәлам.

ССП партком президиумы уполномоченные Берестинский».

Монда фамилиясе телгә алынган Исхаков, һичшиксез, Әхмәт Исхак. Чөнки ул 1939 елдан ук СССР Язучылар союзы Әдәби фондының Татарстандагы вәкиле итеп билгеләнгән. Шуңа күрә аңа мөрәҗәгать итәргә кушу аңлашыла. Шушы Мәскәү кадерлеләрен кайгырту, урнаштыру өчен, сораганнарын, боерганнарын тәэмин итү өчен аңа «өстән» акча да килә тора...


=СРОЧНАЯ КАЗАНЬ СОЮЗ ПИСАТЕЛЕЙ=
Народный Комиссариат Связи СССР
МОСКВЫ 69/119 37 18 1536
ПРЕЗИДИУМ СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ СССР ПРОСИТ СРОЧНО ОБРАТИТЬСЯ ТОВАРИЩУ АЛЕМАСОВУ ДОБИТЬСЯ РАЗРЕШЕНИЯ ПРОПИСАТЬ КАЗАНИ СЕМЬЮ ПОЭТА ОРДЕНОНОСЦА ПЕНЬКОВСКОГО СОСТАВЕ ЧЕТЫРЕХ ЧЕЛОВЕК КВАРТИРЕ ЕГО БРАТА УЛИЦА ОСТРОВСКОГО ДОМ 23 ВЫЕХАЛИ КАЗАНЬ РАЗРЕШЕНИЯ СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ=ПАНФЕРОВ+

ПРОВЕРИЛ КОРРЕКТОР ТЕЛЕГРАФА

Ответ.секр.Правления ССП ТР:

Секретарь первич. организ. ВКП/б/ при ССП

«СССР Совет язучыларының Президиумы ашыгыч рәвештә иптәш Алемасовка мөрәҗәгать итүегезне, орденлы шагыйрь Пеньковскийның дүрт кешедән торган гаиләсен Островский урамындагы 23 нче йортта яшәүче абыйсына пропискага кертүегезне сорый. Ул гаилә союз рөхсәте белән Казанга чыгып китте.

Панферов».

Өстән-өстән генә укып китсәң, бигрәк тә Алемасов дигән фамилиягә игътибар итеп тормасаң, аның кемлеге белән кызыксынмасаң, бу телеграмма да гади һәм башкаларыннан аерылмый кебек. Әгәр дә ошбу журналны укып яшәүчеләрнең ата-бабалары, туган-тумачалары, авылдашлары һәм башка якыннары дәһшәтле утызынчы еллар тегермәненә эләккән, кызыл концлагерьларга ташланган, НКВД подвалларында гарипләнгән яки эзсез-нисез юкка чыгарылган икән, беренче чиратта шушы Алемасовны искә алып каһәр яудырсыннар! Ул — Татарстан, бигрәк тә татарлар өчен чын мәгънәсендә кеше сурәтендәге Газраил була. Дистәләрчә мең адәм баласы шушының имзасы, боерыгы белән фани дөньядан гүргә күчә.

Аны, ВКП(б)ның Воронеж шәһәр комитетында икенче секретарь булып утырган Алемасовны, коточкыч

репрессияләргә куәт бирсен өчен, 1937 елда Татарстанга эчке эшләр комиссары итеп куялар. Нәкъ менә ул килгәч, каршылык күрсәтүгә хокукы да булмаган гөнаһсыз бәндәләрне, төрле ялалар ягып, күпләп кыру башлана! Мондый репрессияләр вакытында, гадәттә, халыкның милли рухын көчәйтүче, китаплары аша һәр өйгә кереп, кешеләрне уйландыручы, акыл бирүче, яшәү мәгънәсен ачып салучы әдәбият әһелләренә ныграк ябырыла карательләр... Чөнки яхшы беләләр: язучылары кимегән саен милләт үз йөзен югалта, шанлы тарихын оныта, горурлыгы коргаксый, кыюлыгы сүрелә, сүзсез, ләм-мим буйсынучы көтүгә әверелә һәм бетүгә юл тота... Сүзне артык озайтмыйча әйтсәк, менә шушы Алемасовлар чорында татар язучыларының кимендә өчтән бере үтерелә, шактые республикадан чыгып кача... Мөгаен, ВКП(б) Алемасовның безне канга батыруын зур да, мактаулы да батырлык дип таныгандыр, чөнки аны шул ук елда Татарстан обкомының беренче секретаре итеп куялар. Татарстандагы «каһарманлыклары» өчен, күрәсең, шул елларда ук Кызыл Байрак орденына, бераздан хәтта Ленин орденына лаек табалар, күкрәгенә медальләр тагалар...

Хәер, телеграммадан ераграк киттелгән... Орденлы Пеньковскийның хәлен кайгыртып кайсы татар язучысы Алемасовка баш иеп керде икән? Ул хакта кул астымда документ юк. Әмма сизенәм, бик сизенәм: Газраил тупсасын атлаганда йөрәге дә, аяклары да калтырагандыр бахырның...

«23 июльдә, иртәнге сәгать 7дә 204 нче поезд белән егерме бер бала, утыз дүрт өлкән кеше Казанга чыгып китте. Каршы алуны, пароход белән Чистайга утыртып җибәрүне тәэмин итегез.

Брайнина, Хотимский».

=КАЗАНЬ СОЮЗ
=СРОЧНАЯ КАЗАНЬ
БАУМАНА 19
ДОМ ПЕЧАТИ
ЛИТФОНДА
ИСАХАКОВУ=
МОСКВЫ 2849 31 23 1632=
=ДВАДЦАТЬ ТРЕТЬЕГО ИЮЛЯ СЕМЬ УТРА ПОЕЗДОМ 204 ВЫЕХАЛА КАЗАНЬ ЧИСТОПОЛЬ ДЕТЕЙ ДВАДЦАТЬ ОДИН ВЗРОСЛЫХ ТРИДЦАТЬ ЧЕТЫРЕ ТЧК ОБЕСПЕЧЬТЕ ВСТРЕЧУ ОТПРАВКУ ПАРОХОДОМ ЧИСТОПОЛЬ=
ШКОЛЬНАЯ 6 КВ 1=БРАЙНИНА ХОТИМСКИЙ

Килә торучыларның һәркайсына хезмәтче кирәк: каршыласыннар, пароходка утыртып җибәрсеннәр, сәламәтлеген кайгыртсыннар, багажларын күтәреп йөрсеннәр, фатирга урнаштырсыннар, теркәсеннәр, ризык-кием юнәтсеннәр... Шушы урынга җиткәч, көлми түзмәдем: ярый әле «абзар артында тәпи дә тотсыннар», димәгәннәр... Ә хезмәтчеләре кемнәр соң? Татар язучылары!


=КАЗАНЬ СОЮЗ
15/33+
=МОЛНИЯ КАЗАНЬ ДОМ ПЕЧАТИ СОЮЗ ПИСАТЕЛЕЙ ИМАМУДИНОВУ
МОЛН МОСКВЫ 69/0101 19 29 1422=
=ПРОШУ ПОЗАБОТИТЬСЯ СЕМЬЕ МАРШАКА НАХОДЯЩЕЙСЯ КАЗАНИ ГОСТИНИЦА ТАТАРСТАН СООБЩИТЕ КАКОМ ПОЛОЖЕНИИ=ПАНФЕРОВ+

«Казандагы «Татарстан» гостиницасындагы Маршак гаиләсен кайгыртуыгызны сорыйм. Хәлләренең ничек леген хәбәр итегез.

Панферов».

Ошбу телеграмманың астына Язучылар союзы башлыгы Төхфәт Иматдинов мондый искәрмә язып куйган: *«Маршак гаиләсе Островскийдагы 9 нчы йортның 5 нче квартирына урнаштырылган».*



=ОТВЕТ 400 КАЗАНЬ УЛИЦА БАУМАНА СОЮЗ ПИСАТЕЛЕЙ ИМАМУТДИНОВУ

АЛМА АТА 2202 25 25

УМОЛЯЮ РАЗЫСКАТЬ ТЕЛЕГРАФИРОВАТЬ ЗДОРОВЬЕ СЫНА ИМАННУЭЛЯ МАРШАКА МОЙ АДРЕС АЛМА АТА УЛИЦА ЧАЙКОВСКОГО 69 КВАРТИРА 4=МАРШАК

«Улым Иммануэль Маршакны эзләп табуыгызны, сәламәтлеген белүегезне, телеграф аша хәбәр итүегезне ялварып сорыйм. Минем адрес: Алматы, Чайковский урамы, 69, квартира 4. Маршак».



КАЗАНЬ ДОМ ПЕЧАТИ СОЮЗ ПИСАТЕЛЕЙ ИМАМУТДИНОВУ

МОСКВЫ 69/0103 25 8 1105=

ПРОСИМ ЗАБОТЫ СЕМЬЕ ПИСАТЕЛЯ ОРДЕНОНОСЦА МАРШАКА ПРОЖИВАЮЩЕЙ ОСТРОВСКОГО 9/5 ОРГАНИЗУЙТЕ СИСТЕМАТИЧЕСКУЮ МЕДПОМОЩЬ БЫТОВЫЕ УСЛОВИЯ=СЕКРЕТАРЬ ПРАВЛЕНИЯ ССП СССР КИРПОТИН+

«Островский урамы 9/5 яшәүче орденлы язучы Маршакның гаиләсенә карата кайгыртучан булуыгызны сорыйбыз. Системалы рәвештә медицина ярдәме оештырыгыз, көнкүреш шартлары тудырыгыз.

СССР ССП секретаре Кирпотин».

Укучыларыбыз игътибар иткәндер: Мәскәү кадерлеләренең бер генә гаиләсенә хезмәт күрсәтү өчен генә дә күпме татар язучысы йөгерергә, мәшәкать чигәргә, турысын әйткәндә, тәлинкә тотарга тиеш булган! Язып үткәнемчә, йөзләрчә документларымда андый мисаллар күп, бик күп…



Дорогой тов. ИМАМУТДИНОВ !

Жена Секретаря Правления ССП СССР тов. КИРПОТИНА В.Я. Анна Яковлевна КИРПОТИНА, живет в настоящее время в г. Чистополе. Ей необходимо привезти свою дочку в Казань для операции. У ней нет никого знакомых в Вашем городе. Я посоветовал ей обратиться к Вам. Уверен, что Вы поможете ей устроиться с жильем на несколько дней и укажете хорошего врача в хорошей больнице для девочки.

Заранее благодарю Вас за все, что Вы для нее сделаете, благодарю и от лица т. Кирпотина.

Между прочим, давно не получал от Вас никаких вестей. Мы послали в Ваш Союз большое письмо о перспективах и планах работы. Хотелось бы узнать, как работают писатели Татарии.

Пишите мне

Ваш (Косырев)

"25" сентября 1941 г.

«СССР ССП секретаре В.Я.Кирпотинның хатыны хәзерге вакытта Чистайда яши. Ул үзенең кызын операция ясату өчен Казанга китерергә тиеш. Аны берничә көндә тораклы итүегезгә, яхшы врач табып яхшы больницага урнаштырып, ярдәм итәчәгегезгә ышанам. Алдан ук барысы өчен дә рәхмәтлемен. Кирпотин исеменнән дә рәхмәт белдерәм».

Имзасы танырлык түгел. Шул ук Кирпотин үзе генә әфтәрләгәнгә охшый бу хат…

Табылган документларның берсе — танылган шагыйрә Марина Цветаева хаты. Аны укыганда авторын кызганып та куйдым. Әле ике ел элек кенә, ягъни, 1939 елда татарны эткә тиңләп шигырь язган Марина бит инде бу! Татарстан Язучылар союзына шушы хатны язганда ниләр уйлады икән ул? Бик каушаган, ахрысы, хәтта Имаметдинов фамилиясендә ике хата җибәреп, кат-кат төзәткән. Хатының юллары, өметен югалткан һәм кайгыдан бетеренгән кешеләргә хас булганча, кәгазь читенә таба аска бөгелеп-бөгелеп төшкән. Эчтәлеге дә кызганыч…

«16 август. Сезгә язучы-тәрҗемәче Марина Цветаева яза. Мин Литфонд эшелонында Кама буендагы Алабуга шәһәренә эвакуацияләндем. Миндә


16го августа.

Уважаемый тов. Имамутдинов

Вам пишет писательница-переводчица Марина Цветаева. Я эвакуировалась с эшелоном Литфонда в гор. Елабугу на Каме. У меня к Вам есть письмо от и. о. директора Гослитиздата Чагина, в котором он просит принять деятельное участие в моем устройстве и использовать меня в качестве переводчика. Я не надеюсь на устройство в Елабуге, потому-что, кроме моей литературной профессии, у меня нет никакой.

У меня, за той же подписью, есть письмо от Гослитиздата в Татгосиздат, с той же просьбой.

На-днях я приеду в Казань и передам Вам вышеуказанное письмо.

Очень и очень прошу Вас, и через Вас Союз Писателей, сделать все возможное для моего устройства и работы в Казани. Со мной едет мой 16летний сын.

Надеюсь, что смогу быть очень полезной как поэтическая переводчица.

Марина Цветаева

Сезнең исемгә Гослитиздат директоры вазифасын башкаручы Чагинның мине урнаштыруда эшлекле катнашуыгызны, тәрҗемәче итеп файдалануыгызны сорап язган хаты бар. Мин үземнең Алабугада эшкә урнаша алуыма өмет багламыйм, чөнки әдәби һөнәремнән башка бернинди дә һөнәрем юк. Шулай ук миндә шул ук имзалы һәм шул ук үтенечле икенче хат та бар. Анысы Гослитиздаттан Татгосиздат исеменә.

Шушы көннәрдә мин Казанга барам һәм әлеге хатны тапшырам.

Сездән һәм Язучылар союзыннан мине Казанга күчерүегезне һәм шунда эшкә урнаштыруда мөмкин булганның барысын да эшләвегезне бик тә, бик тә үтенеп сорыйм. Минем белән 16 яшьлек улым да бара. Шигъри тәрҗемәче буларак бик файдалы булачагыма ышанам.

Марина Цветаева».

Укучы игътибар иткәндер, Цветаева Литфонд эшелонында эвакуацияләнүен язган. Ә эшелон ул, күпләребез белгәнчә, дистәләрчә вагоннар таккан поезд, ягъни бик озын состав. Кайчак аларның буе чакрымгача сузыла. Һәр вагонда 50-60 кеше дип исәпләсәк тә, «чакырылмаган кунаклар» саны меңнән артып китә. Димәк, СССР Язучылар союзының Әдәби фонды — барлык әдипләрнең уртак акча капчыгы — бай булган, шулкадәр язучыны Мәскәүдән, сугыш барган яки фронт якынлашкан төбәкләрдән җыеп, илнең тыныч һәм хәвеф-хәтәрсез якларына озату өчен «өлеш» чыгара алган.

Инде менә ярты гасырдан артык гомердә без Сталинны тиран дип бәялибез, каргыйбыз, сүгәбез, фаш итәбез. Чөнки хакыйкать шундый. Ләкин аның күп очракта дөрес сәясәт белән яшәвен дә онытмыйк. Әйтик, ул язучыларны илнең акыл чүлмәкләре, халыкның рухи тәрбиячеләре, иҗатлары белән йөзләрчә милләтләрдән укмашкан ватанның бербөтенлеген, бердәмлеген алыштыргысыз саклаучылары, көрәшчеләре итеп күрә белгән. Театр, кино һәм, гомумән, сәнгатьнең башка төрләре дә язучыларсыз яши алмавын аңлаган. Менә мондый эшелоннарны оештыру һәм аларга каләм ияләрен утыртып озату да Язучылар союзы яки Литфондның гына хәленнән килә торган торган эш түгел. Юкса, мондый гамәл дезертирлык, зур җинаять буларак бәяләнер иде. Шуңа күрә тыныч якларга озатылучылар исемлеге, һичшиксез, Сталинның үзе белән килешенгән, дип уйларга кирәк. Инде Цветаевага килсәк, совет власте урнашуга ук чит илгә китеп, унҗиде ел гомерен Чехословакиядә, аннары Франция башкаласы Парижда үткәргән (кыскасы, рәхәт, назлы тормышта көн иткән) шагыйрәгә коммунистик режим үгисетебрәк караган. Бәлки, бу эвакуация аның өчен үзенә күрә сөрген дә булгандыр? Бер көн килеп, татар язучылары хозурына елый-елый (хатта тамчы эзләре сизелә) үтенечле хатлар да язармын, татар җирендә асылынып үләрмен, каберем дә шунда булыр, дип уйладымы

икән ул бәгырькәй? Шушы хатын язып төгәл ике атна үткәч, элмәккә менә…

Моннан егерме еллар элек, Алабугага командировкага баргач, аның каберен күрү өчен зиратка да кердем мин. Ташына карап торганда, җир астыннан калыккандай, көянтәдәй бөгелгән, картаюның чигенә чыккан, каралып кипкән марҗа әби пәйда булды:

— Ни карыйсың, улым?

— Бөек шагыйрә Марина Цветаеваның каберен карап торам менә, әби. Аның җәсәде шушында бит, — дип җаваплады. Карчык кыркылдап көлде генә.

— Ташы гына монда аның, сы-ы-но-ок! Ә гәүдәсен шул төндә үк казып алдылар да, әнә тегендә күмеп куйдылар. Белә идем мин ул хатынны, — дип сөйләнә-сөйләнә, инде җире иңгән, чардугансыз, таш-мазар кую түгел, казык та кагылмаган ятим каберне күрсәтте. Шул кабер янында торганда, тагын бер яңалык әйтте карчык: — Малаеннан да зур казалар күрде инде, мәрхүмә…

Шулай… Карчыкның сүзе хак булса, Цветаева гәүдәсенең кайда булуы да шикле икән бит әле. Әх, язмышлар… Дөнья — куласа, бер әйләнә, бер баса, дигән мәкалебез дә искә төшә.

Язучылар союзына килгән телеграммаларның берсе Приморскидагы Фроловкадан. «Срочно» диелгән һәм болай дәвам ителгән:

«Телеграф аша ашыгыч рәвештә Яковлеваның Казандамы-түгелме икәнен минем адреска хәбәр итегез.

Баталов».

Исеме күрсәтелмичә, фамилиясе бер генә «т» белән язылган булса да, монысының кем икәнен чамалау кыен түгел. Ул, әлбәттә, горур һәм берчакта да вакланмаган, һәр җәһәттән кыю, башбирмәс Салих Баттал булырга тиеш! Яшьлегендә үк очучылар мәктәбен тәмамлаган, үзе әйтмешли, күп елларын күктә — бөркетләр белән янәшә уздырган, гел биектә булуы аркасында репрессиягә дә эләкми калган, шул чорда әдәбият мәйданында да талантлы шагыйрь сыйфатында танылган Салих Баттал! (Җәя эчендә булса да бер искәрмә ясап үтим әле: әдәбиятны әйлешәйле белгән танышларым мине аның туганы яки кардәше, дип уйлап ялгыша. Кем әйтмешли, капка баганаларыбыз да бер урманда үсмәгән…) Ул сугыш чыгуга ук фронтка китә һәм Тын океан флотында очучы булып хезмәт итә башлый, күп батырлыклар күрсәтә, бүләк-медальләргә лаек табыла. Әле Гитлер Германиясе җиңелгәч тә каһарман очучы сафта кала — япон империалистларына каршы яуда катнаша.

Белгәнемчә, Салих Баттал дүрт мәртәбә өйләнеп, бер-бер артлы Мәрьям, Ольга, Кадрия, Мәдинә исемле хатыннар белән яшәгән. Башкаларын тагын кем белгән… Язучылар союзыннан менә шул Ольга дигәнен барлатмады икән?

Күпчелек язучыларның сугыш башлануга фронтка озатылуын, шунда кырылуын, хәбәрсез югалуын искәрттем инде. Ләкин тылда калганнары да иҗат итүдән мәхрүм икән ич. Шуның бер сәбәбе: болай да тарлыкта, кысрыклыкта яшәүче татар әдипләренең фатирына эвакуацияләнгән Мәскәү язучыларын тутыра башлау… Һәм аларны гына да түгел…

«Бауман райсоветының Башкарма комитеты председателе иптәш Коршуновка.

Совет язучыларының Татарстан союзы идарәсе Сездән киләчәктә Каcаткин урамындагы 35 нче йортның 2 нче квартирында яшәүче профессиональ язучы М.Галинең (Мөхәммәт Галиевнең) квартирын моннан гайре тыгызлатмавыгызны сорый. Чөнки хәзер иптәш М.Галинең ике бүлмәле квартирында 4 кеше яши. Бер бүлмәсен тулаем шул килүчеләргә биргән. Икенчесендә үзләре икәү. Йортлар идарәсе тагын 2 кешене кертергә ниятли. Ул очракта яшәүчеләр 6 кеше булачак һәм профессиональ язучы иптәш М.Гали иҗат итәр өчен мини-


Председателю Исполкома Бауманского райсовета тов. Коршунову

Правление Союза Советских Писателей Татарии просит Вас в дальнешим не уплотнять квартиру писателя-профессионала М.Гали /Мухамета Галеева, прож. по ул. Касаткина, д.35, кв.2, Домоуправление 81./ Тов. М. Гали в порядке уплотнения уже вселина 4 человека, т.е. тов. М. Гали, имея две комнаты для двоих, уступил одну комнату, а к себе в следующего комнату вселил двух лиц. В настоящее время Домоуправление хочет вселит к нему дополнительно еще двух чел. Таким образом в комнате где живет тов. М. Гали будут уже 6 человек, и тов. М. Гали, как профессионал – писатель, человек творческого труда будет лишен в минимальных условии творческого труда. Поэтому Правление Союза Советских Писателей Татарии настоятельно просит Вас ограничиться уже произведенным уплотнением и не допускать дальнейшим уплотнения. квартиры тов. М. Гали/Мухамета Галеева/.

маль шартлардан да мәхрүм калачак. Шуңа күрә Совет язучыларының Татарстан союзы идарәсе катгый төстә Сездән иптәш М.Галинең квартирын ары таба тыгызлауга юл куймавыгызны сорый.

2 декабрь, 41».

Өч көннән соң язучыларның иҗади рухын сакларга тырышучы, аларга иҗат шартлары тудыруны армыйталмый, өзлексез кайгыртучы Төхфәт Минһаҗетдин улы Имаметдинов агаебыз шундый ук хат белән өстәрәк утыручыларга да мөрәҗәгать итәргә тәвәккәллек кыла. Ләкин бу юлы берике каләм иясенең язмышы турында язу белән генә чикләнми. Тылда калган татар язучыларының иҗат итәргә шартлары булмавы турындагы «зар»ын Казан шәһәре Башкарма комитеты рәисе Муринга адреслый. Хаттан күренгәнчә, ул чордагы каләмдәшләребезнең хәле тәмам коточкыч булып тоела...

Мәсәлән, Островский урамындагы 15 нче йортның классик әдибебез Шәриф Камал биләгән 2 нче фатирында, 40 квадрат метрлы торак мәйданда, 7 кеше яшәгән. (Адресларына кадәр күрсәтүемнең хикмәте шунда: хәзерге һәм киләчәк буын кешеләре дә олуг язучыларыбызның кай тирәдә, кайсы йортларда гомер кичереп, кайсы урамнар буйлап йөри-йөри фани дөньядан китүләрен тыштан карап булса да белсен, кызыксынулары уянса, кереп карарга да мөмкинлек тапсын, диюем...)

Мәшһүр драматургыбыз Таҗи Гыйззәт шул ук Островский урамындагы 4 нче йортның 9 нчы фатирында торган. 38 квадрат метрда 6 кеше... Комлев (хәзерге Мөштәри) урамы, 13 нче йорт, 10 нчы квартир адресы буенча яшәгән Нәкый Исәнбәтнең торак мәйданы иркенләп иҗат итәрлек булган — 48 квадрат метр! Ләкин Мәскәүдән һәм тагын әллә кайлардан эвакуацияләнгән, сугыш афәтеннән качырылган-яшерелгән күпләрне тутыра торгач, анда яшәүчеләрнең саны да унбергә җиткән! Базар түгелмени?!.. Имаметдинов төзегән бу исемлектә дүртенче булып бая игътибарга алынган Мөхәммәт Гали теркәлгән. Аны сыннан без хәбәрдар инде... Хәер, исемлеккә Төхфәт үзен дә керткән: язучылар башлыгы дип тормаганнар, аның да 24 квадрат метрында 5 кеше яшәп яткан... Шәйхи Маннурның (Островский урамы, 9, кв. 23) 28 квадрат метрына 7 кеше «сыйган»... Мәгълүм ки, Гомәр Бәширов-Разин соңгы ярты гасыр дәвамында яхшыдан-яхшы фатирларга лаек булды, күпләр көнләшерлек шартларда гомер итте. Баксаң, мондый кадерләүләр аңа да бик иртә килмәгән икән: шул ук 1941 елда 15 квадрат метрлы фатирында (Ак ком асты урамы, 8, кв. 9) 5 кеше яшәгән алар!

Гази Кашшаф (Тукай урамы, 87, кв. 5), Кави Нәҗми (Международная, 18, кв. 23), Гадел Кутуй (Комлев урамы, 33, кв. 1), Әхмәт Исхак (Тукай урамы, 32, кв. 7), Афзал Шамов (Тельман урамы, 13, кв. 8), Фатих Хөсни (Островский урамы, 9, кв. 30), Мирсәй Әмир (Бутлеров урамы, 4, кв. 6)... Барысының да фатирларына ким дигәндә эвакуациядәге ике-өч кешене тыкканнар, ягъни адәм башына күп дигәндә 3-4 квадрат метр туры килгән!

Шушы ук исемлектә Михаил Бубеннов дигән урыс язучысы да бар. Бу исем балачагымны, мәктәп елларымны искә төшерде. Аның «Ак каен» дигән романын татарча тәрҗемәдә һай яратып укый идек без! Шул Бубеннов булыр-

га тиеш инде бу... Татарстан Язучылар союзы аның фатирын да тыгызламауны сорый. Ул да Казанда яшәп яткан икән: Дзержинский урамы, 1 нче йорт, 20 нче фатир. 18 квадрат метрда 8 кеше. Ышанырлык түгел-түгелен, әмма акка кара белән баскан документка ышанмый да булмый...


156 28

В ГЛАВНЕФТЕСБЫТ

Союз Советских Писателей Татарии просит отпустить для нужд творческого кабинета им. Тукая и членов Союза керосина 500 литров.

Ответ. секр. Правления ССП Татарии: /Имамутдинов/

Управделами /Сунчелеева/

«28 ноябрь, 41.

Главнефтесбытка.

Совет Язучыларының Татарстан союзы Тукай исемендәге иҗади кабинетка һәм союз членнарына 500 литр керосин бирүегезне сорый».

Язучылар — төнге хезмәт кешеләре. Алар, гадәттә, тирә-як мохит тынып калгач, көндезге ыгы-зыгылардан, яшәеш матавыкларыннан арынгач, балалары, оныклары йокыга талгач иҗат итүчән. Әгәр төн икән, язасың икән, һич югы сукыр лампа яктысы кирәк... Бу документтан күренеп торганча, Сталин җитәкчелегендә чәчәк аткан, муллыкта утырган Татарстанда сугыш башлануга ук керосин да сатылмый башлаган. Үзеңне шул чор язучысы урынына куеп карасаң, хәл бөтенләй харап. Фатирың чит-ят кешеләр кереп тулган булса да, ятагың тирәли чаршау корып, азмы-күпме язар да идең әле, бәлки. Әмма яктылык юк...

Шулай да керосин бирделәр микән, бирсәләр һәр язучы өлешенә күпме литр тиде икән, дип уйланып йөргәндә,


4. М. Гали /Галеев/ – Косаткина, 35, кв. 2.

27 155

В Наркомторг Татарии

Правление Союза Советских Писателей Татарии просит Вас отпустить керосина для писателей Татарии всего на 60 человек 600 лит[ров]. Писатели, как работники творческого труда не имеют никакой возможности получить керосин в обычно установленном порядке, и поэтому Правление ССП Татарии ходатайствует перед Вами о наискорейшем разрешении этого вопроса.

[Отв. с]екр. Правления [С]СП Татарии / Имамутдинов

шушы ук ихтыяҗга бәйле тагын бер документка юлыктым. Монысы инде ачыргаланып язылганга охшаган һәм ул Татарстанның Наркомторгына, хәзергечә әйтсәк, сәүдә министрлыгына адресланган:

«Совет Язучыларының Татарстан союзы идарәсе 60 язучыга 600 литр керосин бирүегезне сорый. Язучылар, иҗади хезмәт работниклары булуга карамастан, гадәти билгеләнгән тәртип нигезендә керосин белән тәэмин ителүгә ирешә алмыйлар. Шуңа күрә Язучылар союзы бу мәсьәләне бик тиз арада хәл итүегезне үтенеп сорый».

Димәк, беренче гозергә уңай җавап алынмаган. Бусыннан соң да вазгыять үзгәрмәгәндер, ахры — ялварулы хатлар якын атналарда да кат-кат язылган...

«8 декабрь, 41.

Табаксоюзга, иптәш Повелкинга.

Совет язучыларының Татарстан союзы татар шагыйре Һади Такташның үлеменә 10 ел тулу кичәсенә, акчалата түләп алу шарты белән, Сездән 300 кап папирос бирүегезне сорый.

Имаметдинов».

Шундый ук үтенеч Наркомторг башлыгы Мөхәммәтҗанов исеменә дә җибәрелә. Бу юлы инде тәмәке кирәклегенә Такташ үлеме генә түгел, ә 5 декабрьдә билгеләп үтеләсе Сталин Конституциясе көне (кичәсе)

Бер төркем Мәскәү әдипләре һәм аларның хатыннары Чистайда. Беренче рәт (сулдан уңга): Б.Я.Сельвинская, Л.И.Исаковская, Ш.Ш.Сидаев, М.Л.Сидаева, Т.М.Леонова. Икенче рәт: М.В.Исаковский, Л.М.Леонов. 1941 ел

дә «сәбәпче» була... Бәлки, Сталин исеменә, аның Конституциясенә таянып сорасаң, бирми калмаслар, дип өметләнү...

Һай ул тәмәке!.. Тарткан кеше өчен ул, Тукайчарак әйтсәк, җан ашы! Валлаһи, көненә ике телем ипи һәм өч бәрәңге белән яши алырыма ышанам, әмма бер кап тәмәкесез калсам, кояшым да сүнәр, иҗатым да бетәр сыман. Язып утырган чакта алай-болай тәмәкем бетеп китсә, төн уртасында ларёкка чыгып йөгерәм...

Шаярта бу, дисезме? Һич юк! Татар әдәбиятын үстергән, алга тарткан иң зур кодрәт — тәмәке икән бит, җәмәгать! Бөек Тукаебызны, Такташны, Хәсән Туфанны, чордашларыбыз Гамил Афзалны, Зөлфәт белән Мөдәррис Әгъләмне дә галиҗәнап Тәмәке иң зур, иң сөекле шагыйрьләребез иткән! Яле, әйтегез, шулардан башка милли әдәбиятыбызны күз алдыгызга китерә аласызмы?

Инде җитдиләнсәк, теге елларда татар язучылары тәмәке булып тәмәкедән дә мәхрүм калган. Дөрес, Мәскәү «путёвкасы» белән татар җиренә килеп тулганнары һәр җәһәттән махсус складлар аша тәэмин ителгән. Шул исәптән, тәмәке белән дә. Татарлар исә шуларның тартуына кызыгып, төтеннәрен иснәп куанган. Ара-тирә «аткалаганнар»дыр да. Урыслар аратирә биргәләгәннәрдер. Ни дисәң дә, «милләтләр дуслыгы чәчәк аткан» илдә яшәгәннәр ләбаса! Моны «килмешәк» язучылар да аңлаган. Әйтик, гаиләсе белән эвакуацияләнгән драматург Константин Треневның Татарстан Язучылар союзына язган хатында мондый җөмләләр бар:

«Многоуважаемый тов. Имамутдинов! По поручению группы Московских писателей (в том числе и лично от меня), я хотел бы выразить признательность за то внимание и ласку, с которыми Вы встретили в Казани наших жён и детей. Этот трогательный прием не лишнее свидетельство той великой дружбы народов...»

Ләкин, үзләре әйтмешли, «дружба

дружбой, а табачок — врозь» булган шул. Бер генә як «ласкать» иткән…

Язган үтенечләренең уңай нәтиҗә бирмәвен аңласа да, Имаметдинов тынмый. Шул ук көнне Совнарком башлыгыннан эвакуациядәге язучыларның балаларына алты пар киез итек бирүне сорап яза. Ләкин үзебезнең танылган язучыларыбыз Әхмәт Фәйзи, Әхмәт Ерикәй һәм Риза Ишморат та аяк киемсез калган… Алар кышкы зәмһәрирләрдә республика колхозларына һәм хәрби госпитальләргә әдәби хезмәт күрсәтеп йөрергә тиеш икән, югыйсә. Әлбәттә, бу исемлекне Мәскәү язучыларының балаларыннан башлау да хәйләнең бер төре генә, аларга итек биргәндә, татар язучыларына да бирерләр, яланаяк калдырмаслар, бәлки, диюдән генә…

Никадәр гаделсезлек, кадерсезлек! Оят һәм хурлык! Нинди генә түбәнлекләр кичермәгән безгә кадәрге әдипләр?!

Бәй, соңгы ике-өч җөмләмне язгач, сискәнеп куйдым һәм… үземнең, үз чорым каләмдәшләренең хәлен барлый башладым… Баксаң, үзебез дә ил һәм түрәләр хозурында кадерсез икәнбез бит! Соңгы егерме елда шулкадәр гарьлеккә, түбәнлеккә юлыктык ки, кайбер язучыларыбыз хәтта каләмен дә ташларга мәҗбүр булды. Әйе, югарыда утыручы түрәләрнең әдәбиятны да, әдипләрне дә бөтенләй санга сукмавы сер түгел. Әле туксанынчы еллар уртасында ук Татарстан радиосы аша иҗади хезмәтебезгә Башкортстан язучыларыннан унҗиде мәртәбә кимрәк гонорар түләнүе хакында сөйләгән идем. Ул теманы матбугатта да күтәреп чыктым. Соң, адәм көлкесе бит, башкорт язучыларына китаплары өчен машиналар алырлык, коттеджлар салырлык гонорар түләгәндә, бездә, шундый ук күләмдәге китапларга, базардан ике-өч мәртәбә тамак ялгарлык азык-төлек алып кайтырлык кына түлиләр иде. Бүгенгедәй хәтердә: күренекле язучыбыз Нияз Акмал, йодрыгын күтәреп, Матбугат йортының дүртенче катында — китап нәшрияты коридорында — әрле-бирле үкереп, сүгенеп йөрде: «Күгәрчен сөте» исемле китабы өчен гонорар алгач, малаена велосипед бүләк итмәкче иде ул, мәрхүм… Ләкин велосипедка җитәрлек акча тимәгән. Хәер, шул ук вакытта минем дә «Гөнаһ шомлыгы» исемле йөзләп юморескам тупланган китабым басылган иде. Арзанлы гына җәйге пальто алырлык булды. Кызыма кунакка барганда күчтәнәчкә чәкчәк белән ярты кило карамель дә алдым әле. Тагын… Тагын Мөдәррис Әгъләм искә төште. Аңа акча курслары җилфердәп уйнаган елларның берендә, махсус указ нигезендә, Тукай премиясе бирергә тиешләр иде. «Акча юк» сылтавы белән шактый айлар көттерделәр аны, акча чүпкә калып беткәч кенә бирделәр… Шуннан базарга киткән бу. Сыер башына беркетелгән бәя кәгазенә күзе төшсә, ни күрсен: Тукай премиясе шуны алырга да җитми икән ич! Сатучыдан:

— Бәясен төшермисеңме, — дип сораган.

— Төшерүен төшерәм, ләкин телен кисеп алам, — дип җаваплаган сатучы.

— Үз телен югалткан милләтнең кадере булмаган кебек, телсез калган сыер башы да — баш түгел, — дип, нәни гигантыбыз китеп бармакчы булган. Шулвакыт мәгълүм шагыйрәбез Нәҗибә Сафина килеп чыккан да җитмәгәнен үзе өстәп түләгән!

Болар хакында язуым кемгәдер кызык та тоелгандыр, бәлки. Ләкин мин милли әдәбиятыбыз әһелләренең шундый кадерсезлеккә калуын уйлый-уйлый күз яшьләремне сөрткәләп утырдым язганда…

Ахыры киләсе санда ■

А.Дубин тупланмасыннан



ПАРОХОДТА ИКЕ СӘЯХӘТ

Хәбибрахман Рәфыйков

1917 елның июнь аенда Фатих абый Әмирхан минем белән бергә Уфадан йөреп кайту теләген изһар итте*. Мин ул вакытта «Сорокин» исемле пассажир пароходында капитан ярдәмчесе идем. Безгә бер төркем яшьләр кушылды: Гомәр Ихсанов, Фатыйма, Мөхәммәт һәм Әхмәт Галиевләр[1], Гомәр Әмирханов[2], Әминә Рәфыйкова[3], Рабига һәм Габдулла Иштирәковлар.

Ниһаять, без юлда! Көннәр бик матур торды. Ашапэчкәч, Фатих абый, икенче кат палубасында аңа билгеләнгән качалкага чыгып утыра иде. Үзен сырып алган яшьләргә ул тормышта була торган төрле мәзәк хәлләр турында сөйләп бик тә көлдерә иде. Урыс пассажирлары

*Изһар итү — теләк белдерү — *ред.*

[1] ...Фатыйма, Мөхәммәт һәм Әхмәт Галиевләр... — Салихҗан мулла Галиев балалары. Фатыйма



да Фатих абыйны тыңларга җыела башладылар. Күңелле кеше, тәмле телле, мәгълүматлы зур әдип дип, мактап сөйлиләр иде.

Пассажирлар бик туйдыра башласа, Фатих абый югары палубага, капитан рубкасы янына менгерергә үтенә һәм анда утырып, журнал укый, аргач йоклап та ала иде. Кичләрен еш кына капитан үзе дә аны югарыга, штурвал рубкасына чакыра иде.

Табигатьне ярата торган Фатих абый, Агыйделгә кергәч, тирә-якның матурлыгына бөтенләй гашыйк булды һәм югары палубада таң аттыра башлады.

Урманлы яр буйларын узганда сандугачлар сайраганы ишетелә, бүтән төр кошлар да чыр-чу килә. Аталы-әнкәле аккошлар парлап йөзә, акчарлаклар, ризык ыргытмаслар микән дигәндәй, пароходтан калмый очалар, су өстенә төшеп, балык тотып алалар. Авылларны узганда сыер, бозау, сарык тавышлары ишетелеп кала.

Кояш әле үзе күренми, әмма урманнар артыннан нур чәчә башлаган. Аннары үзе дә күренә, күтәрелә. Кояш бөтенләй чыгып беткәч, Фатих абыйны каютасына кертеп куялар. Ул, капитан сыман төнге вахтада булган кеше кебек, әйтер иде: «Хезмәтемне үтәдем, инде ял итәм, туганкайларым. Иртәнге чәемә рәхим итегез. Сәгать тугызда, Хәбиб туганкай, син мине уят». Әгәр йокысы туймаса, болай ди иде: «Хәбиб, мин тагын бер станциягә хәтле киттем», ягъни бер сәгать йоклап алам.

Уфага җиткәч, Гомәр Әмирханов һәм Әхмәт Галиев, Фатих абыйның үтенече буенча, аның язучы дусларына телефон аша хәбәр бирделәр. Бер сәгать тә үтмәгәндер, язучылар һәм газета хезмәткәрләре, дүрт-биш ат белән килеп, Фатих абыйны шәһәргә алып менеп киттеләр. Гомәр Әмирханов та, иптәшкә дип, алар белән китте. Икенче көнне, пароход кузгалырга ике сәгать калганда, дуслары һәм танышлары китереп куйдылар. Утыз-кырыклап кеше булгандыр. Команда да, пассажирлар да — урысы, татары — бу хәлгә гаҗәпләнеп калдылар. Кузгалып киткәндә, капитаныбыз Борис Григорьевич Иванов (Спас шәһәрендә туган), Фатих абыйны ихтирам итеп һәм озатучыларның күңеле булсын дип, сузып-сузып, аерылу салюты — өч мәртәбә гудок бирде. Шунысын да әйтим, капитан Фатих абыйга зур илтифат һәм хөрмәт күрсәтеп, пароходтагы барлык уңайлыклардан файдаланырга мөмкинлек тудырды. Хәтта бер тапкыр ул аны, Гомәр белән мине, буфеттан кирәк-ярак китертеп, каютасында сыйлады. Соңыннан, без Түбән Новгородтан әйләнеп килгәч, Фатих абый шул хөрмәтләргә рәхмәт йөзеннән, капитанның

(1897-1957) — хезмәткәр; Мөхәммәт (1899-1960) — педагогия институты укытучысы; Әхмәт (1901-1967) — ветеринария институты укытучысы.

[2] Гомәр Әмирханов (1899-1942) — Зариф мулланың энесе Нәҗип мулла улы, Фатих Әмирханның туганнан туган энесе. Хезмәткәр.

[3] Әминә Рәфыйкова (1899-1979) — Хәбибрахманның сеңлесе. Укытучы.

хатыны Александра Александровнага, Гомәр Әмирханов аркылы, чиккән матур башмак бүләк итте.

Чистайда Фатих абыйны туганнары[4] каршы алды. Чаллы пристаненда күп итеп иген төягәнлектән, пароход Чистайда бер генә сәгать торды.

Казанда Фатих абый үземә һәм мине каршы алган әти-әнигә[5] рәхмәтләр әйтте, пароход кузгалмыйча китмәде. Егетләр һәм кызлар да мине озатып калдылар. Соңыннан әниебез әйтте: «Фатихның шулхәтле күңеле булган, әтиең Яңа бистәгә барып, аның янына керсә, һаман шул турыда сөйли икән».

...Идел ябылды. Пароходыбыз Түбән Ослан затонында кышлаганга күрә, Бөек Октябрь инкыйлабын мин шунда каршыладым. Идел каткач, без, пароходта эшләүчеләр, Казанга, хәзерге Ирек мәйданына килдек. Казан шау-гөр килә. Митингта хөкүмәт эшчеләренең, авыл хезмәтчеләре вәкилләренең, Ленин соратникларының чыгышларын тыңладык. Кояш тагын да куәтлерәк яктырткан кебек булды. Иптәшләр белән бер-беребезне тәбрикләшеп, кочаклаштык.

***

Идел ачылу белән мин — тагын шул үз эшемдә. Навигациягә чыгып китәр алдыннан һәрвакыт Фатих абый янына барып, хәл белеп һәм саубуллашып китә идем. Ул да хәерле юл теләп кала иде. Әстерханнан Казанга килгәч, әтием аркылы аңа паюсная икра, осетрина балыгы җибәрә идем. Ә беренче фруктылар чыккач, анысыннан да авыз иттерәдер идем.

Үләр алдыннан берничә ел Фатих абый Жуковский урамында яшәде. Театрга барсам, ул әйтер иде: «Бишбалтага кайтып йөрмә, кунарга миңа кер». Мин рәхәтләнеп риза булам. Ашатып-эчермичә яткырмый. Спектакльнең ничек үткәнен, нинди артистлар уйнаганын сораша иде.

1923 ел навигациясендә мине «Год Октябрьской революции» исемле теплоходка билгеләделәр. Ул Түбән Новгород, хәзергечә әйтсәк, Горький белән Әстерхан арасында йөри иде. Әти аркы-

[4] Чистайда... туганнары... — Нәҗип мулла, аның хатыны һәм балалары күздә тотыла.

[5] ...мине каршы алган әти-әнигә... — Габдрахман Вәли улы Рәфыйков (1873-1954) — танылган укытучы-педагог, Хезмәт Герое (1928) Рабига Шакир кызы Иманкулова (1879-1962).

лы мин Фатих абыйга тәкъдим ясадым: теплоходта йөреп кайтырга теләге юкмы, булса, кай вакыттарак? Ул июнь ахырын билгеләде. Түбәннән менгәндә Казанда утырып, Түбән Новгородтан Әстерханга кадәр алып барырга һәм, кире кайтканда, Казанда төшереп калдырырга, дигән карарга килдек.

Х.Рәфыйков. 1925 ел

Июньнең 25ендә безнең теплоход Казанга килеп туктады. Хәйран калдым: әти, әни, Фатих абыйдан гайре, пристаньда безне профессор Әбүбәкер абзый Терегулов белән Зыя әфәнде Ваһапов[6] көтеп торалар иде. Аларны 1 класстагы өч урынлы каютага урнаштырдым. Әти белән әни минем каютада өйдә пешкән ризык белән сыйлый башладылар, үзем исә аларны Иделнең түбән ягында өлгергән яшелчәләр белән сыйладым һәм өйгә дә биреп җибәрдем.

Теплоход икенче свисток биргәч, әти һәм әни кунакларым белән саубуллашырга менеп киттеләр. Өченче свисток бирелгәндә, махсус беркетелгән матрос, Фатих абыйны палубага күтәреп алып чыгып, качалкага утырткан иде. Әбүбәкер абзый һәм Зыя әфәнде, аның янында басып торган килеш, әти-әни белән сөйләшеп алдылар.

Теплоход кузгалып киткәч, мин вахтадан бушап, хөрмәтле пассажирларым янына кердем. Зыя әфәнде, рестораннан китереп, кичке аш әзерли башлады. Фатих абыйның «Йа, Алла, бу саф, тузансыз һаваны иркенләп сулый торган сәгать тә җитәр икән» дигәне хәтердә калган. Һәммәсенең дә рухы күтәренке иде, көлешеп, гөрләшеп, ашый-эчә башладылар.

«Нинди генә рәхмәтләр укырга сиңа, Хәбиб туганкай, бу пароходта бару безгә бик рәхәт!» — диештеләр.

Ашап-эчкәч, палубага кереп утырдылар. Кич бик матур иде. Козловка пристанен узгач, Казан бөтенләй күздән югалды. Сәгать 2дә Чабаксарны да уздык. Мин йокларга төшеп киттем, хөрмәтле кунакларым да каюталарына кереп киттеләр.

Икенче көнне, Түбән Новгородка җиткәч, көндезге икеләрдә Фатих абый белән Әбүбәкер абзый извозчик яллыдылар да, күрергә, танышырга дип, шәһәргә юнәлделәр. Зыя әфәнде, берәр столовойда ашап чыгар өчен дип, Свердлов урамындагы театр янында аларны көтеп торырга булды. Кичке сәгать сигезләрдә

[6] Зыя Ваһапов — Әмирханнарның күп еллар дәвамындагы күршесе.

Габдрахман Рәфыйков хатыны Рабига, Нәфисә Имәнкулова һәм балалары – Әминә, Хәбибрахман белән. Казан, 1913 ел

алар, шәһәрнең күп җирләрен, тарихи урыннарын карап, арыпталып кайтып керделәр. Шәһәрнең төзеклеген, чисталыгын мактадылар. Откостан[7] карап, Идел күренешенең матурлыгына хәйран калганнар икән.

Теплоход икенче көнне сәгать 12дә кузгалып китте. Пассажирлар күп булып, каюталарда буш урын калмаган иде. Пассажирлар арасында артистлар да, галимнәр дә, бүтән төр һөнәр ияләре дә бар иде. Алар, рөхсәт сорап, Фатих абый янына килеп утыралар һәм аның белән дә, Әбүбәкер абзый белән дә сүзгә керешеп китәләр иде. Бик артык туйдырмасыннар дип, үзем вахтада вакытта, мин аларны рубкага чакырам. Алар диванга утырып, табигатькә сокланып баралар.

Казанда безне минем әти белән әни, Гомәр Әмирханов,

[7] Откос — Түбән Новгород шәһәренең Кремль урнашкан төшендәге Иделгә карый торган иң биек урыны.

Шушы үрдән заманында Фатих Әмирхан Иделне күзәткән...

А.Дубин тупланмасыннан

Әбүбәкер абзыйның җәмәгате Әминә ханым, Зыя әфәнденең хатыны Нәфисә һәм кызы Сафия каршы алдылар. Минекеләр дә, аз вакытка булса да, хәл белү өчен, хөрмәтле пассажирлар янына менеп төштеләр.

Казанда ике сәгать ярым торгач, теплоход тагын баруы-кайтуы ун көнлек булган юлга чыгып китте. Яңа бистә яныннан узганда, Фатих абый — ничек дип әйтергә — моңаеп калды, шактый вакыт сөйләшмичә барды. Яңа бистәнең зираты тәэсир иткәндерме, белмим...

Аяклары йөрмәгән Фатих абыйның йомышларын Зыя әфәнде Ваһапов үтәде. Әбүбәкер абзый да ярдәм итә иде. Әмма аңа күбрәк матрослар хезмәт итте. Һәр сменадан бер матросны беркетә идек. Фатих абый аларга тиешле вазифаларын** бирде.

Менә Әстерханга барып җиттек. Көннәр бик матур иде. Фатих абый, Әбүбәкер абзый һәм Зыя әфәнде, ат яллап, шәһәр белән танышып йөрделәр. Ә кичен мин дә кушылып, Әстерханның данлыклы фонарик бакчасына киттек. Анда ресторанның балконында ашап-эчеп, күңелләрне тагын да күтәреп, төнге сәгать беренчедә генә теплоходка әйләнеп кайттык. Әбүбәкер абзый бакчада вакытта музыкага биеп тә алды. Бу миңа бик кәмит тоелган иде.

Кире кайтканда, Казанга кадәр барлык пассажирлар Фатих абыйны бик тә ихтирам иттеләр, һаман аның янында булырга тырышалар иде. Һәммә кешедә, шул исәптән, теплоход командасында да, ул бик матур хатирә калдырды. Үзе төшеп калгач та, еш кына әйтәләр иде: «Нинди матур, нинди сөйкемле, нинди зур сезнең Фатих Әмирхан дигән әдибегез!»

Әбүбәкер Терегулов (1885-1966) – медицина өлкәседә татарлардан беренче профессор, күренекле табиб

Редакциядән

Бу истәлекнең авторы — Хәбибрахман Рәфыйков (1897-1972) — күренекле мәгърифәтче Габдрахман Рәфыйковның (1873-1954) улы. Ул озак еллар дәвамында елга транспорты инженеры, капитан ярдәмчесе, капитан булып эшләгән, соңрак Казан елга техникумында белем биргән. Мәсәлән, легендар шәхес, Советлар Союзы Герое Михаил Девятаевны (1917-2002), язучы Сафа Сабировны (1915-2004), тарихчы Булат Солтанбәковны (1928) әлеге уку йортында Хәбибрахман Рәфыйков укыткан.

Истәлекне, тәртипкә салып, редакцияләп һәм искәрмәләр белән тәэмин итеп, күренекле галим һәм әдип Ибраһим Нуруллин заманында «Казан утлары» журналына тапшырган булган. Шуннан бирле ярты гасыр чамасы вакыт үткән... Ниһаять, Татарстанның халык шагыйре Равил Фәйзуллин, «Казан утлары» архивыннан әлеге язманы табып, безнең журналга тәкъдим итте. ■

**Вазифа — эш хакы.

**Сулдан уңга:
Зөлфәт һәм мин.
1980 нче еллар**

СҮЗ ҺӘМ СУРӘТ

Рафаэль Сәхәби

«Зөлфәт белән Разил Вәлиев таныштырды мине (Разил — якташым, авылдашым; Казанга килгәч, мин гел аның янында булдым). Шуннан соң без гомерлек дусларга әверелдек. Мин аның күп кенә җырларын башкардым. Гомумән, каләм ияләре белән һәрдаим дустанә мөнәсәбәттә яшәдем, Аллага шөкер. Хәзер дә шулай...

Хәтерләүчеләр бардыр: теге заманнарда ай саен диярлек Мәскәүгә концерт куярга йөрү гадәте бар иде. Язучылар, шагыйрьләр, җырчылар җыелып, «аккаланы» шау-гөр китереп кайта идек. Бу фото шундый сәфәрләрнең берсендә, концерттан соң төшерелде».

***

«Хәйдәр Бигичев белән консерваториягә бергә укырга кердек. Аннары озак вакыт бергә Муса Җәлил исемендәге Опера һәм балет театрында эшләдек, бергә концертлар куеп йөрдек. Күз ачып йомган арада үтеп киткән ул озын-озак елларның бер истәлеге: Жорж Бизеның «Кармен» операсында Хосе (Хәйдәр Бигичев) һәм Моралес (мин фәкыйрегез) партияләрен башкарабыз».

Сулдан уңга: Хосе һәм Моралес... 1980 нче еллар

Оныгым Нариман белән. 2010 ел, 30 август

***

«Оныгым Нариман — горурлыгым да, өметем дә. Бик күп дөньякүләм конкурсларда катнашып җиңү яулый тора, һәрдаим чит илләргә (Алмания, Канн кинофестивале, Нью-Йорк һ.б.) җырларга чакырыла. Казан музыка училищесы шәкерте. Тавышы — бас-баритон. Әлеге сурәттә — Шәһәр көнендә (Татарстан Республикасының бәйсезлек көне — Суверенитет бәйрәменең кай арада шулкадәр «тыйнакланып» калуын абайлап та өлгермәдек, ә!) Тукай һәйкәле каршында икәү чыгыш ясаганнан соң». ■

Әсәр филология фәннәре докторы, профессор **РИФКАТЬ ӘХМӘТҖАНОВ**ның шигъри тәрҗемәсендә бирелә.

КУТАДГУ БИЛИК

(Котайткыч белем)

Йосыф Баласагуни
(Йосыф Хасс-Хаҗиб)

«Ходай», дип бер әйтсәң, кача шайтаның,
«Ахирәт» дисәң, бар гаме китә дөньяның.

Әмма тәннән ничек азат булырга?
Тик үлгәндә генә китә бу дөнья.

Ни шәп әйткән, әнә, белекле белкә
(Кирәктер белкәләр сүзен белергә):

«Моңа дучар итә мине тән-җаным:
Беразга көлдергәч, елата тагын.

Дөнья дәрте мине сала газапка:
Бер ач калдыра ул, бер сый ашата.

Бер теләгәнең бар, юк икенчесе,
«Тагын бере булса иде, һай», дисең.

Бу дәрт-теләкләрне мин баса алмыйм;
Үзең генә инде бастыр, Илаһым».

Тән дигән нәрсә ул артык азучан:
Симереп тилерә, бераз ашатсаң.

Нәкъ аучы эт кебек ул тәнең, баксаң,
Симерсә иясен танымый башлар.

Ауга йөрмәс булыр, йоклап, тук ятып,
Аңар бернәрсә дә булмас аңлатып.

Тән охшаш яшь кенә тинтәк сабыйга:
Ашый да кача ул һәм табылмый да.

Рухсыз, хәрәкәтсез ятачак тәнең,
Теләгәнен биреп аздырсаң аны.

Яшәү төгәл өч көн дәвам итәдер
(Ә калганы төш-төн белән бетәдер):

Берсе көнә көн[1] һәм берсе иртәгә.
Бүгенең дә әле исән үтәрме?

Шулар үткәч, берни калмыйдыр шуннан.
Яшәүгә ышанма, сүземә ышан.

Хатын белән сөхбәт – иркәклек утын
Бер сәгатькә генә үчермәк өчен.

Бу утны һәрничек үчерсәң дә бер.
Матурмы, түгелме.. үчә[2], китәдер.

**Тән дигән нәрсә ул артык азучан:
Симереп тилерә, бераз ашатсаң.**

* Дәвамы. 2013 елның 10 нчы санынннан басылып килә.
[1] Көнә көн монда «кичәгенәк», хәзерге телдә көнәгең «бүгенгедән элек өченче көн». Көнә — фарсыча куһнә — «үткән, иске».
[2] Үчү «сүнү», үчерү – «сүндерү»: без бу сүзләрне татар сөйләшләрендә дә таралганлыгы өчен оригиналдагыча калдырдык.



Тамагың рәхәте – карын туйдыру.
Ниләр ашасаң да бердәй булыр ул.

Тамак туйса, арпа ни дә, хәлвә ни?
Кирәгеннән артса бөялә, керми.

Шикәр-хәлвә ашап яшим, дигәннәр
Төн үткәч, ач була тагын иртәнгә.

Ни ди, ишет, уйчан бер ярлы – чигай[3]
(Үзе чигай ләкин күзе-күңле бай).

«Шикәр-фәлән ашап син ләззәтләндең,
Кибәк ашап та мин канәгатьләндем.

Икебез тиң туеп яттык кичләрен,
Һәм үтте гомерем – көн, сәгатьләрем.

Һәм үлем каршында тиңбез икебез:
Сиңа да, миңа да ике кисәк бүз![4]

Чигаймы-баймы тиң үлем соңында,
Ята череп кара туфрак куйнында.

Ике көнлек булган бу гомереңдә
Ни дип кукраясың тереклегеңдә?

Тамак туйса, арпа ни дә, хәлвә ни?
Кирәгеннән артса бөялә, керми.

Тозак корасың мал-мөлкәт эзенә.
Үлем тозак кора синең үзеңә.

Көн дә бер яфрагың өзелеп төшә,
Ә кәүсәңне үлем пычкысы кисә.

Тереклегең булгач, үлемең шиксез,
Бары үлер көнең генә билгесез…

Үсәр чак – исәр чак, сакал көтәсең,
Сакал агарганын өмет итәсең.

Сакалың агарды… Үлем – алдыңда,
Яшәү дәверләре юк ич тагын да!

Фани дөнья өчен юкка көенмә,
Күрә торып зур йөк алма үзеңә.

Дөнья малы – агар сулар шикелле,
Ләкин бәндә канмас, гел эчәр, тиле.

Коры ком шикелле бәндәнең үзе:
Күпме су керсә дә, сок булыр күзе.

[3] Чигай – ярлы, фәкыйрь (татар телендә бар).
[4] Ягъни – «кәфенлек». Бүз — «ак мамык тукыма».

**Тозак корасың мал-мөлкәт эзенә.
Үлем тозак кора синең үзеңә.**

Дөнья сагым[5] кебек багып күргәндә:
Юкка чыга бәндә «тоттым», дигәндә.

Сагым ул, карасаң, оча да бетә,
Артыннан иярсәң, кача да китә.

Җиңелмә син тәннән, аны буйсындыр,
Аның бар теләге – нәфес, уендыр.

Кичергән гомерең китә килгесез,
Киләчәк көннәрең әле билгесез.

Кадерләп тот Алла биргән һәр көнне,
Үлем көт, калдырма гыйбадәтеңне.

Ни ди, әнә, рухан уянган бер ир,
Пычрактан арынган, көр бер баһадир:

«Кичердем бу төнне, – дип уйлан иртән, –
Иртәгә дә нәкъ бер көн килер микән?
Кичергән һәр көнең бер рабат[6] дип бел,
Нишлисең, гомер бер авыр юл икән».

– Зая булды монда яшәвем, – дидем, –
Иң шәп чагым үтте, – диеп үкендем.

Бүген башкалага чакырасың син,
Полын булса нәфсем, коткаручың кем?

Тәнең теләгәне – шайтан ул, шайтан,
Бөтен җиргә алтын тозагын җәйгән.

Тәнең теләгенә игътибар итмә:
Кырыс булыгыз сез, аңа егетләр.

Ни ди үз-үзенә хуҗа булган ир,
Мин-минлеген җиңеп акыл алган ир:

Тәнеңә бер тоткын булма, гыйлемдар,
Әгәр тоткын булсаң, дин юкка чыгар.

**Тәнең теләгәне – шайтан ул, шайтан,
Бөтен җиргә алтын тозагын җәйгән.**

Белдекле дип булмый шундый кешегә –
Нәфес нигез булса һәрбер эшенә.

Билгеле, белдексез бер зат ул бәндә,
Тән дәртенә һәрчак өлеш биргәндә.

Уйсыз кеше үлек була, и, кардәш,
Һәвәс-нәфесенә булалмаса баш.

Менә, дөнья хәле шулай ләбаса,
Бу әйткәннәремне ихлас тыңласаң.

ҮГДЕЛМЕШНЕҢ ҖАВАБЫ

Җавапта Үгделмеш әйтте: – Сүзеңне
Ишеттем син әйткәч, и, җаны изге.

Алай икән, белдек бу дөнья хәлен:
Тозлак итмә икән гомерең юлын.

Үзеңә дөньяны кылма авыр, тар,
Языклы колны да Тәңре ярлыкар.

**Фани дөнья өчен юкка көенмә,
Күрә торып зур йөк алма үзеңә.**

Газабы зур булса, рәхмәте чиксез.
Языклыга рәхмәт капкасы биксез.

Газабыннан курык, рәхим өмет ит,
Гыйбадәт кыл «мин бер тугры колың», дип.

Ләкин халык барча авыл-шәһәрдән
Гыйбадәткә чапса мәгарәләргә.

Яшәү-тормыш хәле бозылыр иде:
Барсы үлгәч нәсел киселер иде.

Шулай ук, бар халык дөнья эчендә
Йөгереп туктагач, көн дә, көнендә

Гыйбадәт кылмаса, тәмуглар тулып,
Калыр иде оҗмах кешесез булып.

Ике өй бар барча дөнья әһленә:
Берсе – оҗмах, берсе тәмуг диелә.

[5] Сагым – «мираж».
[6] Рабат – борынгы сәүдә юлларында станца, кунып китү урыны.

Илаһ бәндәсенә биргән күз-колак:
Бер ахирәткә һәм бер тәмугка бак.

Ике кул бирелгән шундый гадәткә:
Бер эшкә тотасың, бер гыйбадәткә.

Ике аягың бар шундый хаҗәткә:
Бер эшкә барасың һәм бер мәчеткә.

Ни шәп әйткән уяу бер укымышлы:
Гафил булма, саклан, сөймә кыешны.

Түрәткәндер Тәңре ике дөньяны,
Игътибарсыз куйма берсен дә аның.

Адәм балаларын кодрәтле Тәңре,
Ачлы-туклы итеп түрәтте мәңге.

Иңеңә кием һәм тамагыңа җим
Кирәк, и карендәш, яшәүгә шул им.

Бәндәгә шуларсыз яшәү юк, иптәш,
Иңең капларга тун, тамакка — икмәк.

Хәләл дөнья көтеп, эшләп ашасын,
Фәкыйрьгә өлеш тә чыгара алсын.

Булмаса иде ул ашау хәстәре,
Адәм җәзасы ул – тамак хәлләре.

Ходай каһәреннән куркып кына тор,
Рәхименә өмет итеп кенә тор.

Шул ике – Аллага хезмәт юлыдыр,
Шул юлдан адашма, Тәңре колы бул.

Ни шәп әйткән берәү – белем бирүче –
Белексезгә үгет биреп йөрүче.

Өмет белән хәвеф – ике канатың,
Шулар илә юлда оча аласың.

Илаһ сүзен тотып яшәсәң, үзең
Сәрайга керерсең, рәхәт сөрерсең.

Өмет, хәвеф, гүя, канат кебек ул
Шулар илә очкан таба күккә юл.

Җиңелмә син тәннән, аны буйсындыр,
Аның бар теләге — нәфес, уендыр.

Языкларым күп, дип өметең өзмә,
Саваплымын дип тә ваемсыз йөрмә.

Гыйбадәт кыл – шулдыр Аллага хезмәт,
Исмен Алла колы, хезмәтче, димәк.

Ходай боерыгын кадерсезләмә,
Хәерсезләр белән хәерсезләнмә.

Кешенең яманы дип бел үзеңне,
Изге дисәләр дә эш вә сүзеңне.

Менә белгәнемне әйттем сиңа мин,
Шуны эшкә тотсаң, файда килер, дим,

Әгәр ризасызлык тудырса сүзем,
Мин тыңлыйм, и, егет, әйтеп бак үзең.

Бауның озыны шәп, сүзнең кыскасы,
Шуңа күрә килми артык сузасым.

УЙГЫРМЫШНЫҢ ҖАВАБЫ

Башын тотты – уйга Уйгырмыш талды,
Озак торгач, башын күтәрде тагын.

Әйтте: – Кардәш, салдың тәшвишкә, гәрчә
Сөйләсәң дә миңа син кардәшләрчә.

Син изге нияттә хәлемә кердең,
Сүзең өчен Ходай бирсен әҗерен.

Багып күрдем инде, ләкин бу эштә,
Мәгънә күренмәс кебек ничек тә.

Күңелем теләми, кача бу эштән,
Күңел теләмичә эш итсәң – хәтәр.

Ни ди изге белкә акыллы сүзен
(Сөйгән-сөелгәнгә күңеле сөзек)[7]:

Кадерләп тот Алла биргән һәр көнне,
Үлем көт, калдырма гыйбадәтләреңне.

[7] Оригиналда сүзүг – татар диалектларында сөзек «чиста, саф, үтә күренмәле».

**Өмет белән хәвеф – ике канатың,
Шулар илә юлда оча аласың.**

«Нинди дә бер эшне кылмакчы булсаң,
Күңелдән киңәш көт, күңлеңә ышан.

Иң тәүдә мәгълүмат алырга кирәк.
Күңел теләмәгән эштән бул ерак.

Үзеңә иң якын кеше — син үзең
Җан теләмәс эштән баш тарт, кис сүзен.

Күңел теләмәгән эш булмас юньле,
Файда чыкмас аннан, и, заты динле».

Бу эшне теләмим күңлем минем дә,
Тора алмыйм инде әйткән сүземдә.

Ләкин синнән сорыйм – шулдыр гозерем –
Мине калдыр инде, илдә кадерлем.

Илбиккә ярарлык фазыйләтем юк,
Коллыгым – холкым һәм бүтән рәтем юк.

Шул дөньядан качтым, килдем бирегә,
Хәзер ничек итеп кайтыйм кирегә.

Ходайга хезмәткә багышладым мин,
Кешеләргә хезмәт итә алмыйм мин.

Мине бер Тәңрегә, зинһар, куя бир.
Сиңарга да дога кылыйм, баһадир.

Икәү курешергә ашкынсак инде
Миңа килмә, үзем барачакмын мин.

Михнәтләрне – миңа, сиңа – тынычлык;
Синнән файда күрсен илбик вә халык.

Ни ди миһербанлы бер кеше, ишет
(Якынлык һәм хезмәт сөючән кеше):

Ерактан караса кеше эшенә,
Авыр мәсьәләләр җиңел чишелә.

Теләгәнен табыр, күр, әнә халык:
Аптырамый авыр бер хәлдә калып.

Ни шәп әйткән илдә сөекле кеше
(Мәхәббәт-дуслыкта белдекле кеше):

«Якын булса күңлең, ерак җир якын
(Ә кем якын дисәң, күңлеңә багын).
Шәрыкътән гарепкә бер генә үрләм,
Кыйммәтле дип белсәң якынлык хакын»

Җавапта Үгделмеш әйтте: – Инде син
Тыңла, син сөйләгәч мин дә сөйлимен.

Әйтеремне әйттем. Син хәзер инде
Илбиккә җавап яз. Кызартма мине.

Үз кулыннан язды илбик сиңа хат,
Һәм бирергә тиеш син язма җавап.

Мин китәргә исәп. Җавап хатыңда,
Сүзләреңне үлчәп, аңлат барсын да.
Сөйләгәндәй итеп, уеңны белгерт.
Мин илбиккә илтим, и, белкә егет.

**Ходай боерыгын кадерсезләмә,
Хәерсезләр белән хәерсезләнмә.**

УЙГЫРМЫШНЫҢ ҖАВАБЫ

Җаваплап Уйгырмыш әйтте: – Әфәндем,
Кирәк булгач, мин хат язып җибәрим.

Дәвәт, кәгазь сорап, каләм тибрәтте,
Илбиккә тәфсилле сүзен төбәлтте.

Илаһ исме илә сүзен йөргезде,
«Түрәтмеш-үстермеш бер Тәңрем, – диде –

Аңар сансыз мактау ошбу телемнән,
Табынам Аллага чын күңелемнән.

Бар итте бәндәне, сансыз мәхлукны,
Яшәтә, җибәрми кытлык-ачлыкны.

Үзе бер, бүтәннәр ике дөньялы
Һәм һичкем уйлап та беләлми аны.

Дәвамы бар

Байназар Әлмеев рәсеме

«КИҢӘШСЕЗ СҮЗ БАШЛАМА...»

Марсель Әхмәтҗанов

(Әсән Кайгының тормыш юлы һәм иҗаты)

---

*Ахыры. Башы журналның 5 нче санында.

Әсән Кайгы кыргыз халкына аларның авыр вакытларында акыллы киңәшче була. Борынгы кыргызларга жунгарлар һөҗүм иткән дәвердә алар Обь елгасы буйларына күчеп утыралар. Анда беркадәр аучылык, игенчелек белән көн күрәләр, ләкин кышкы салкыннарны, җәен черкиләр талавын авыр кичерәләр.

Соңрак кыргызлар, Обьтан күчеп килеп, Җидесу якларында төпләнә. 1459 елда мангыт биләре булып торган Гәрәй хан белән Җанибәк хан Арал буйларыннан Могулиага (Җидесу өлкәсе) күчеп китә. Әсән Кайгы алар белән шулвакытта якыннан таныша. Алда әйткәнемчә, фәндә Гәрәй хан белән Җанибәк ханны казакъ дәүләтен төзүчеләр дип карыйлар. Гәрәй белән Җанибәк ханнар — Чыңгыз нәселеннән булган Борак хан балалары, Ак Урданың Сыгнак шәһәрендә идарә иткәннәр. Җанибәк хан, Гәрәй хан үлгәннән соң, 1466-1470 елларда дәүләт башлыгы булып тора. Башкала итеп ул Сарайчыкны сайлый. Аңарчы ул Уел елгасы буйларында казакълар белән күрше булып яши.

Әсән Кайгы Җанибәк ханның Уел буйларын калдырып китүен яратмаган. Аңа ризасызлык белән язган шигырендә дә бу ачык күренә. Шагыйрь Җанибәкнең башка гамәлләрен дә хупламаган:

Кырында кийек җәйләгән,
Суында балык уйнаган,
Урмандай тук игеннең
Уеңа килгән ашың җитүен,
Җимдә киңәш кылмадың,
Җимнән дә илне күчердең.
Уел дигән — уенлы,
Утын тапсаң — туенлы,
Уел күзнең яше иде,
Уелда киңәш кылмадың,
Уелдан илне күчердең.
Дулкын-дулкын йөгергән,
Бүтәкә утка симергән,
Ике симез кулга алып,
Ирләр җуртып көн күргән,
Идел дигән еракка,
Иңеп килдең тар җиргә,
Монда да киңәш кылмадың —
Киңәшнең төбе казадыр.
Суында балык уйнаган,
Урмандай тук игеннең
Уеңа килгән ашың җитүен,
Җимдә киңәш кылмадың
Җимнән дә илне күчердең,
Уел дигән — уенлы,
Утын тапсаң — туенлы,
Уел күзнең яше иде,
Уелда киңәш яше иде,
Уелда киңәш кылмадың.
Уелдан илне күчердең.
Дулкын, дулкын йөгергән,
Бүтәкә утка симергән,
Ике симез кулга алып,
Ирләр җуртып көн күргән.
Идел дигән еракка,
Иңеп килдең тар җиргә,
Монда да киңәш кылмадың
Киңәшең төбе казадыр.

***

Акылны билдән алдырдың,
Күңелне җаман калдырдың,
Нәләт безнең йөрешкә.
Идел белән Җаекның
Берен җазга җәйләсәң,
Берен кышка кышласаң,
Ал кулыңны манарсың
Алтын белән көмешкә.

Әсән Кайгы әлеге шигырьдә Җанибәкне илне мәгънәсез рәвештә күчереп йөртүдә гаепли. Башта Мангыт иле Уел елгасы буйларында урнашкан булган. Шагыйрь Җим буендагы киекләрнең, елгадагы балыкларның күплеген, Җим тугайларында игеннең урман кебек мул булып үсүен яшәү өчен уңай иде, дип бәяли. Ул ханны Җим буеннан киңәшми күчеп китүдә гаепли, Уел елгасы буйларында төпләнеп калмауга да ризасызлык белдерә. Шигырьдән Уел буенда яшәү күңелле, елганың суы күз яше кебек чиста, утын тапсаң, тамак туйдырып була, дигән фикер аңлашыла. Моннан Әсән Кайгының утрак тормыш белән яшәүгә йөз тотуы күренә. Ул Казан янындагы авылларның ямենә күңел

салып, утрак тормыш турында уйланып йөргән, күрәсең.

Әсән Кайгы Идел буена күчеп килүне дә өнәмәгән. Бу җирләр аңа тар күренә. Әлеге шигырендә ул Идел буен гына түгел, Идел белән Җаек елгаларына кушыла торган вак елгалар белән тармакланган җирләрне алуны да алга сөрә. Шагыйрь Идел белән Җаек буйларының берсен — кышлау, икенчесен җәйләү өчен файдаланырга өнди, шулвакытта гына кулыңда алтын, көмеш күп булыр, ди.

Әсән Кайгының икенче бер шигыре дә алда мисал итеп китерелгән әсәрнең дәвамы булганга охшый. Анда Идел белән Җаек елгаларының яшәү өчен мөһимлеге темасын дәвам итә:

Идел бул да Җаек бул,
Һичкем белән сугышма.
Җулдашыңа җау тисә,
Җаныңны аяп торышмы?!
Ирнең коны булса да,
Алдыңа килеп калгачтын,
Кул кушырып баргачтын,
Аша — кич тә, куя бир,
Узган эшне куышма.
Хакың булса бирәүдә,
Гаебен тап та ала бир,
Чәнчелеп китеп орышма.
Сүзләрең җүн булса да —
Исмең чыкмас дөрескә.
Мәнесе җаман адәмгә —
Инде кайтып җөрешмә.
Табип күрер кешеңмен,
Җалган әйтеп суынышма.
Үле туган тай өчен,
Урамда туган сай (табылдык) өчен,
Җилкә тирең кырышып,
Һичкем белән сугышма.
Ачу — дошман, артыннан
Төшеп китсәң үләрсең
Төбе тирән куышка.

Шигырьдә әхлак проблемалары да күтәрелә. Ыру-кабиләләр эчендә дә халыкны әхлакка, сабырлыкка өндәү мөһимлеге аңлашыла. Кешедән аласың булса, аңа барысын да яхшылап аңлат һәм кирәгеңне ала бир, ди җырау. Ул

Без алда Идел буенда, Болгар шәһәрендә туып үскән, гыйлем алган бер татар шагыйренең XV гасыр урталарында Җидесу, Сарайчык якларына китеп, андагы нугайлар (мангытлар) – татарлар, казакълар, кыргызлар арасында яшәп, Әсән Кайгы җырау буларак, даладагы кардәшләребезгә рухи кыйммәтләр чәчкәнен күрдек. Әсән Кайгы, әлбәттә, ул якларга китеп, 70-80 яшьләренә җиткәч кенә шагыйрь, фикер иясе булмаган. Аның иҗади таланты Идел буенда – балалыгы, яшьлеге, картлыгы узган җирдә үк ачылган. Юкка гына аны кайберәүләр «Идегәй» дастанының авторы дип санамыйлар. «Идегәй»дәге вакыйгалар, нигездә, Әсән Кайгы дәверендә булып узган. Ул дастанда Идел буе географиясе фонындагы тормыш, көрәш тасвирлана.

кан үче алу гадәтен ташларга өнди. «Әгәр гаепле кеше яныңа тилмереп килгән икән, син иске үчләр белән яшәмә, аңа ярдәм ит», дип киңәш бирә.

Җырау мәнсез кешеләр белән аралашып, булашып йөрергә киңәш итми. Күршегә ялган әйтеп, араларны суытуны гаепли. Ул тар күңелле булмаска, комсызланмаска өйрәтә. Кеше арасында ачу чыгуның үлем белән бер икәнен искәртә.

Әсән Кайгының мәгърифәтчелек идеяләре аның укымышлы, гуманист шагыйрь булуын күрсәтә. Әхлакый темага бәйле шигырьләре, һәркемгә таныш булган табигать күренешләре белән чагыштырылып, тормыштан алынган мәкаль-әйтемнәр, афоризмнар белән көчәйтелә. Мәсәлән:

Күлдә җөргән коңгырт каз
Кыр кадерен ни белсен,
Кырда йөргән дуадак
Су кадерен ни белсен!

Монда су һәм кыр кошларының яшәешен сурәтләү кешеләр тормышын ачып бирү өчен язылa. Дәвамы буларак:

Ауылдагы җаманнар,
Ил кадерен ни белсен!
Күчеп-куным күрмәгән
Җир кадерен ни белсен!

Шагыйрь Казан-Болгар хакимлегендә утырган Әсән солтан һәм Олуг Мөхәммәд ханның якын кан кардәше булып чыга. Шуңадырмы, ул үзен ханнардан түбән күрмәгән, аларның кимчелекләрен, ялгышларын күрсәтеп бирә алган.

Әсән Кайгы тәрбиянең бөтен ил, авыл өчен кирәклеген, тәрбиясезлектән җәмгыятьнең зыян күрүен ассызыклый.

***

Без алда Идел буенда, Болгар шәһәрендә туып үскән, гыйлем алган бер татар шагыйренең XV гасыр урталарында Җидесу, Сарайчык якларына китеп, андагы нугайлар (мангытлар) — татарлар, казакълар, кыргызлар арасында яшәп, Әсән Кайгы җырау булырак, даладагы кардәшләребезгә рухи кыйммәтләр чәчкәнен күрдек. Әсән Кайгы, әлбәттә, ул якларга китеп, 70-80 яшьләренә җиткәч кенә шагыйрь, фикер иясе булмаган. Аның иҗади таланты Идел буенда — балалыгы, яшьлеге, картлыгы узган җирдә үк ачылган. Юкка гына аны кайберәүләр «Идегәй» дастанының авторы дип санамыйлар. «Идегәй»дәге вакыйгалар, нигездә, Әсән Кайгы дәверендә булып узган. Ул дастанда Идел буе географиясе фонындагы тормыш, көрәш тасвирлана.

Казакъ, кыргыз, каракалпак һәм нугай халыклары мирасында сакланып калган риваятьләр Әсән Кайгы иҗатын тулырак күз алдына китерерлек мәгълүмат бирә.

Шагыйрь Казан-Болгар хакимлегендә утырган Әсән солтан һәм Олуг Мөхәммәд ханның якын кан кардәше булып чыга. Шуңадырмы, ул үзен ханнардан түбән күрмәгән, аларның кимчелекләрен, ялгышларын күрсәтеп бирә алган. Моннан тыш, Әсән Кайгының татардагы күчмә тормышның бөтен нечкәлекләрен анализларлык зур тәҗрибәсе дә булган, шуңа күрә хакимнәр аның сүзенә колак салганнар. Моның мисалы Җанибәк ханның чакырган туйларына Әсән Кайгының бармау сәбәпләре ачылган риваятьтә чагыла.

Җанибәк хан рәттән өч туй уздырган. Аның беренчесе ханның иң түбән нәселле карчыгасы да аккош тота ала дип мактану өчен ясалган туй* булган; икенчесе Әстерхан шәһәре салынып бетү мөнәсәбәте белән оештырылган; өченчесе — ханның бертуган сеңлесе Каныбитне Мыгалы бай улы Таштимергә кияүгә бирү өчен үткәрелгән туй. Шагыйрь боларның берсенә дә килми.

Әсән Кайгы дүртенче мәртәбә чакыргач кына Җанибәк хан янына бара һәм ханның «Нигә туйларыма килмәдең?» дигән соравына, «Син аккошка ерткыч карчыга җибәреп үтерттең», ди. Аннан дөньяда аккошны үтергәннәрен күрүдән дә ачы хәсрәт булмавын, ханның үзенә дә бервакыт шундый шәфкатьсез кеше табылачагын әйтә.

Җанибәк хан, куркып: «Җитте, җитте, мин бит сине сеңлем туена да чакырдым», — дип, аны туктата. Шагыйрь тагын ханны тәнкыйть итә. «Син ул сеңлеңне Гайсә улы Әмәткә ярәшкән идең бит, нигә вәгъдәңне үтәмәдең, икенче кешегә бирдең? Син йоланы боздың, шуңа туйга килмәдем», — ди.

Бу сүзләрдән соң Җанибәк уйга кала һәм сеңлесен Әмәткә бирергә карар кыла.

Әсән Кайгы — XIV йөз татар әдәбияты традицияләрен XV йөздә, ягъни татар тормышында күчмә тормыш белән яшәү өстенлек алган дәвердә үстерүче зур шагыйрь. Чокан Вәлиханов әйтмешли, «ул нугайның (казакълар татарны нугай дип атый) бөек акыл иясе булган». Аның шигырьләре, канатлы сүзләре, нигездә, казакъ, кыргыз, каракалпак, нугайлар арасында таралып, биш гасыр буена кардәш халыкларның күңел хәзинәләрен баетуга хезмәт итеп килгән. ■

* Җанибәк хан суга шәраб сала һәм аккошны, эчертеп, исертә. Аннан аңа саз карчыгасы җибәреп үтертә.

ТУКАЙ ЭНЦИКЛОПЕДИЯСЕ

Сәхифәне филология фәннәре докторы, профессор ЗӨФӘР РӘМИЕВ алып бара.

ЙОСЫПОВ ИБРАҺИМ (1929-2008), каракалпак шагыйре, драматург. 1960 елда каракалпак телендә Тукайның 87 шигырь һәм поэмасы җыентык булып басылып чыга. Җыентыкның «Татар поэзиясенең кояшы» исемле кереш сүздә автор Ибраһим Йосыпов Тукайның шигъри биеклеккә үрмәләвендә рус әдәбияты йогынтысы булуына басым ясый, Пушкин, Лермонтов, Толстой, Жуковский, Крыловлардан өйрәнүен әйтә. Аныңча, шагыйрь революцион демократ, гади кешеләрне (рабочийларны), эштән куылган татар кызын яклап яза, социаль золымлыкның сәбәпчесе итеп «сары шайтан»ны күрсәтә, гомеренең соңгы елларында өметсезлек тойгыларына бирелгән, дип саный. Җыентыкта 5 әсәрне Йосыпов үзе тәрҗемә иткән. Ул Тукай шигырьләренең һәр юлын өлгергән һәм тук бодай башагы белән тиңли; аларда бернинди дә бушлык, кысыр бөртек юк, бодайдан пешерелгән ипи кебек Тукай шигырьләре һәркемгә тәмле, кадерле, аның иҗатының асылын халыкчанлык тәшкил итә, дип яза. К.Ходайбиргәнов фикеренчә, И.Йосыпов үз тәрҗемәләрендә оригиналдагы «образларны, ритм, рифманы», хәтта урыны белән аерым татар сүзләрен дә саклаган. Мәсәлән, «Шүрәле» каракалпакча «җезтырнак», әмма тәрҗемәдә ул Тукайдагыча калдырылган.

Йосыповның иҗат мирасында Тукайга багышлап язылган шигырьләр дә бар. Аларда авторның бөек шагыйрьгә тирән ихтирам-хөрмәт хисләре бөркелеп тора. Аның М.Шабаев тәрҗемә иткән «Тукайга» шигырендә: *«...Тукай дөнья шигъриятен / яңартып алга әйдәдең, // Шигъри ике материкны / тоташтырып бәйләдең. // Байрон, Лермонтов Шәрекъкә / танылды синең аша, // Сәгъди, Хафизлар белән / хәзрәте Пушкин сөйләшә»*. Шигырь бик тә оригиналь сүзләр белән төгәлләнә: *«... Нәләт әйтеп син яшәгән / заманның җәберенә, // Әгәр син терелер булсаң, / ятар идем кабереңә»*. И.Йосыповның Казанда Тукай чараларында катнашканы, шигырьләр дә укыганы бар.

Хатыйп Миңнегулов ■

Әсәр.: Юсупов И. Татар поэзиясенең кояшы // Г.Токай. Шгармаларынан. Нокис, 1960. — Б.3-6.
Әдәб.: Сагитов И.Г. К вопросу о татарско-каракалпакских культурных связях и роли в них Тукая// Габдулла Тукай. К.,1968. — С.95-99; Худайбергенов К. Тукай и каракалпакская советская поэзия // Габдулла Тукай. К., 1979. — С.190-194.

ТУКАЙ ТУРЫНДА ИСТӘЛЕКЛӘР

Вафа Бәхтияров

ЯПОН МӨСЕЛМАННАРЫ

1906 елның җәендә Рәшит казый Ибраһимов (шул вакыттагы тәрәккыйчы имамнарның берсе, җиңелрәк уйлаучы, үзен бик зур итеп танучы бер кеше иде) Япониягә сәяхәт итә. Татарлар арасында: «Япон халкы һәм аларның патшалары ислам динен ярата икән. Ислам динен өйрәнер өчен төрле мөселман илләреннән дин галимнәрен чакырткан икән, шул мөселман галимнәре белән аңлашкач та, иң элек япон патшасы (микадо) ислам динен кабул итәчәк, аннан соң бөтен япон халкы ислам динен кабул итеп, япон иле мөселман иле булып әвереләчәк!» — дип шау киләләр.

Рәшит Ибраһимов

Бу — үзара мәҗлесләрдә бердәнбер зур мәсьәлә булып китә. Тукай шул җүләрлекләрне күрә дә, үзенең «Японияне мөселман идәчәк голәмә нәрәдә?» («Японияне мөселман итәчәк кешеләр кайда?») дигән чәнечкеле шигырен яза.

«ДОН КИХОТ»

Минһаҗ Йосыф мулла улы Кадермәтов элеккеге Саратов губернасы Хвалын өязе Иске Мастаф авылында туган. Ул, татар мәдрәсәләрендә укып, нindидер юл белән Һиндстанга барып чыга. Берничә ел Һиндстанда укып үткәрә. Анда нинди уку йортында укуы билгеле түгел. Нинди эш белән вакыт үткәргәне дә мәгълүм түгел. Менә шул Минһаҗ яңадан үз иленә, Русиягә кайта. Үзен Һинди Минһаҗ дип атап, бик зур кеше итеп күрсәтергә тырышып йөри. Хвалын шәһәренә зур уку йорты салам, дип, Баку байларыннан акча туплаган булып, Хвалын шәһәренең

*Дәвамы. Башы журналның 4 нче санында.

читенә кирпеч ташытып куя. Казанга килеп, Апанаевлар кызларының берсенә өйләнә. Тиктормас Тукай «Дон Кихот» Минһаҗның болай халыкны алдап йөргенә чыдап тора алмый, «Минһаҗ» исемендә дүрт юллык шигырен язып чыгара:

Таш ташыйлар. Анда Минһаҗ «Галия»[1] нигезен сала.
Туй ясыйлар. Монда Минһаҗ гаилә нигезен сала.

Салыныр да, төпләнер дә, бик уңайдыр соңгысы;
Шикләнәм мин әллә ник: булмас кеби әүвәлгесе.

Шул ук Минһаҗ Кадермәтовка карата, халык җырларын үзгәртеп, болай дип җырлый:

Каф тавы артында үсә самарау-кош баласы;
Һинди Минһаҗ шул җирләрдә дарелфөнүн саласы.
Ала карганың баласы әрсезләнә — тук була;
Һинди мәдрәсә салганда, Рәшит[2] — мәчет Токиода.

Минһаҗ төсе-рәвеше белән әллә кемне дә үзенә каратырлык бер көчкә ия иде. Кыскасы, дин-милләт исеменнән афёра ясап йөрүче Дон Кихот зур башлы, зур гәүдәле, киң җилкәле, киң күкрәкле, үзе таза, сүзгә, куык очырырга бик оста, матур итеп вкус белән киенә, башына фәс киеп, кулына көмеш башлы таяк тотып йөри торган иде. Нәкъ Истанбул төрекләренең отставкага чыккан яшьләредәй, үзен Көнчыгыш һәм Көнбатыш культурасы белән таныш зур бер галим кеше итеп күрсәтергә, ышандырырга тырыша иде.

«Дон Кихот» Минһаҗның халыкны алдап, дарелфөнүн салдырам, дип халыктан акча туплавын, бу эшнең барып чыкмавын, бу эшнең хыял гына икәнен белгән «ислахчы»лар берничә тапкыр чыгыш (хисап) сорады, әмма ул җавап бирмәде. «Ислахчы»ларның чыгышларына да игътибар бирмәде, колак салмады. Шулай да, Тукайның матбугат аркылы югарыда күрсәтелеп үткән чыгышларыннан соң, бу «шәригать айгыры»ның халык арасында бөтенләй авторитеты бетте. Базары төште. Татар байлары аның алдап, ялганлап йөрүче кеше икәнен аңладылар. Шуннан соң Минһаҗ теләнеп йөрүдән туктады, бөтенләй күздән югалды.

АЕРЫМ ЯЗМАЛАР КАЛДЫГЫ

Син дисең, имеш ки, шагыйрьгә барам;
Барма, барма — син әрәм аңгар, әрәм!

Үз уеңча, шагыйрь ул җырлый, дисең,
Җыр исә тыңларга күңелле, дисең.

Син алай иткәнче, и кашың һилал!
Бар да бер кош кибетеннән былбыл ал.

---

[1] Галия — югары уку йорты.
[2] Рәшит Ибраһимов — җәмәгать, сәясәт һәм дин эшлеклесе, публицист, нашир. Тукай инануынча, Рәшит казый, имеш, юк эш белән шөгыльләнә. Ләкин чынбарлыкта исә аның Японияга барып чыгуы шактый саллы эз калдыра. Башта татарлар төзегән мәчетләр пәйда була. Соңрак, японнар үзләре мәчет төзеп, чыннан да, ислам кабул итәләр. Бүген Япониядә 500000 мөселман яши. Болар — Рәшит казый шәкертләренең тарафдарлары.



Таң йолдызы газетасының бер саны

Ал да читлеккә куеп сайрат аны;
Мактасын хөснеңне —
син саргайт аны.

Буррәтова туташ шулвакытта зур уку йортларында укучы кызларның берсе иде. «Әл-ислах» идарәсенә һәрвакыт килеп-китеп йөрүче һәм «Әл-ислах» идарәсе тарафыннан ясалган әдәбият кичәләренә якыннан торып катнашучы, аңлы һәм укымышлы туташларның берсе иде. Хәзерге вакытта врач булып хезмәт итә. Шул туташка Казанның мәшһүр бае Бәдретдин Апанаевның улы Гали Апанаев кызыга. Шул турыда хәбәр тарала. Тукай бу тигезсезлеккә эче поша һәм түбәндәге ... хак шигырен язып чыгара...[3]

«ТАВЫШ»

1905 елгы революциядән соң татар яшьләре арасында эсерлар партиясе мәйданга чыга. Шул татар эсерлары тарафыннан «Таң» газетасы чыгарыла башлый. Озак та үтми, бу газетаны патша хөкүмәте яптыра. «Таң» газетасы урынына «Таң йолдызы» газетасын чыгарырга рөхсәт алалар. Бу газетаның да гомере бик кыска була. Хөкүмәт моны да тарката. Шул ике газета урынына шул ук «таңчылар» «Тавыш» газетасы чыгаралар.

ТАТАР «ТӘРБИЯ»НЕ КИРӘКСЕНМИ?

1906 елның кышында Заһид Шамил (мәшһүр Кавказ Шамиленең оныгы (улының улы)) Петербургтан Казанга килеп, атасыннан калган бик яхшы йортны (Тукай урамы, 74) Троицк бае Яушевларга 120 меңгә сатып, Мәскәүгә ... китә. Шул акчага, татар халкына хезмәт итү теләге белән, «Тәрбиятел-әтфал» исемендә балалар өчен журнал чыгарырга рөхсәт ала. Фатих Әмирханны журналга секретарь итеп алдыра. Журналны 4-5 ай чамасы дәвам иттерә дә һич сәбәпсез-нисез ... туктата. Халыкка «хөкүмәт тарафыннан туктатылды» дип күрсәтә. 1908 елда, үзара сөйләшкәндә, Фатих бу журналның тукталуын подписчикларның саны аз булу, аның табыш-файда китерә алмавы белән аңлата. Берничә көн үткәч, Тукай бу җырны җырлады:

Ак та була, күк тә була буяучының буявы;
«Хөкүмәт яптырды», — дидер нәширләрнең уявы.

САБЫН СӘҮДӘСЕ

1908 елның «Сабах» көтепханәсе хуҗалары Әхмәдуллин, Зәбиров, Әхмәровлар китапчылыктан файда аз дип, сабын остасы алып, сабын кайнату эшен башлап җибәрделәр. Үз сабыннарын көтепханәнең бер ягында сата башладылар. Бу капма-каршы булган эшне Тукай күрде дә, «сабахчы»лардан көлеп, болай дип җырлады:

[3] Кулъязма шушы урында өзелә.

Япуннар туп атмыйдыр, төтене җиргә ятмыйдыр,
Ялган сүздер, ышанмагыз: «Сабах» сабын сатмыйдыр.

ТАБЫЛГАН ЯЛГЫШ

Октябрь революциясенә чаклы бөтен татар халкы өчен Кәримовлар һәм урыс Харитоновлар тарафыннан Коръән бастырылып таратыла иде. Бу ике зур сәүдә фирмасы шул эштән йөз меңнәрчә файда итәләр иде.

1908 елны Мөхәммәтзаһир Бигиевнең энесе Муса Бигиев Харитонов бастырган Коръәннән бер хата сүз таба. Бу турыда Муса бик зур эш, дип, газеталарда чыгыш ясый. Бөтен татар халкы шау килә. Тукай, Мусаның бу эшеннән көлеп:

Арыслан белән юлбарыс яратылган бер каннан,
Безнең Муса һич тиктормас: ялгыш тапкан Коръәннән, — дип язды.

ЯМЬСЕЗ МАТУР

Казанда татарлар өчен ачылган Учительская школаны бетергән, Казанда күп еллар урыс теле укыткан, үзен бик зур белем иясе итеп таныган, әмма дә үзүзен аңламаган Шакирҗан Таһиров татар мәктәпләре өчен «Бәдәел мәгариф» исемендә уку китабы язып чыгара. Бу китап тәҗвид мәктәпләрендә яхшы дип табыла. Берничә тапкыр басыла.

Соңга таба искеләр бу «Бәдәел мәгариф»тән берничә сүз табып «бу сүзләр дингә, шәригатькә каршы» дип сөйләп, цензурага барып шикаять итәләр. Шул вакыйгадан соң, ярамас сүзләр бозылып, кеше танымас хәлгә китерелеп, китапны яңадан сатарга рөхсәт алына. Тиктормас Тукай шул вакыйганы күрде дә:

Ямьсез матур булалмыйдыр, күмер белән каш тартып;
«Бәдәел мәгариф» саталар, алты сүзен башкартып, — дигән җыр язды.

ДОШМАНЛЫК

Тукайның үз гомерендә иң зур дошман дип санаган кешесе Галимҗан Ибраһимов булды.

Боларның бер-берсенә дошман булулары бик кечкенә булган бер эштән килеп чыкты. Сүз озынга киткәнлектән, бу урында язмый китәм.

Болар бервакытта да бергә утырышмадылар, сөйләшмәделәр, фикер алышмадылар. Галимҗан «Әл-ислах» редакциясенә килсә, Тукай редакцияне ташлап чыгып китә торган иде.

Галимҗанның «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы» дигән әсәрен «Әл-ислах»ка кертмәс өчен Тукай тавыш күтәрде, сүз көрәштерде. Фатих: «Мәдрәсәләрдә булган хәлләрне, шәкертләр тормышын сурәтләгән бер әсәр, безнең тоткан юлыбызга кирәкле, кертәбез», — диде.

Мондый эшләр зур скандал белән үтә торган иде. Тукай Галимҗан Ибраһимов турында түбәндәге шигырьләрен язды: «Интикадка мәтәгалликъ» , «Монафикъка», «Мөнтәкыйд», «Дошманнар», «Җавап»...[4]

---

[4] Вафа Бәхтияров шигырьләрдән үрнәк китерми. Ләкин без шул әсәрләрдән өлгеләр күрсәтергә булдык. Галимҗан Ибраһимов мәшһүр әсәрендә: «Тукай шагыйрьме, түгелме?» — дигән сорау куя. Шуңа җавап рәвешендә язылган «Интикадка мәтәгалликъ» шигырендә Тукай: «Куркыталмый чын талантны тәнкыйть», — дип яза. «Монафикъка» әсәрендә исә: «Шаярма, дошманым, пешкән, җитешкән пәһлеван берлән; монафикъ! яхшы саклан! Аударам беркөн ояң берлән!» — ди.

ИЛҺАМ КАЯН КИЛӘ?

«Тукай ничек, кайда язды?» — дигән сорауга җавап язсаң, хәзерге яшь буын һич тә ышаначак түгел. Бәлки: «Син ялган язгансың», — диячәкләр. Тукайның илһам урыны күбрәк «Болгар» убырныенда һәм «Болгар» номеры белән янәшә «Суворов» пивноенда, яки үзе торган кырыгынчы номерда булды. Шунда язды.

Тукай, төннәр буе ике кулы белән башына таянып, илһам килүен көтеп утырмый һәм көчәнеп язмый иде. Илһам Тукайны ... язарга мәҗбүр итә иде. Тукай кайда туры килде, шунда язды. Бик яхшы беләм «Театр», «Безне урынсызга яманлыйлар» һәм «Алтынга каршы» шигырьләрен «Болгар»ның бер кешелек тынчу бүлмәсендә язып чыкканын.

КИРЕБЕТКӘН

Казанда бай малайларының яшьләрне чакырып, кунак итү гадәтләре бар иде. Тукайны, Сәгыйть Рәмиевне чакыралар иде. Ләкин ике олыҗан болар белән ваклашмый, чакырган җиргә бармыйлар иде. Фатихтан башка кешегә һичбервакыт бармадылар. Галиәсгар абзый Тукайның якын кешесе булса да, Галиәсгар өендә Тукай бер тапкыр да булмады. Кайвакыт безгә тарихчы Газиз Гобәйдуллин килеп утыра иде. Газиз Гобәйдуллин керүгә, Тукай өйдән чыгып китеп, бакчада утырып вакытын үткәрә иде.

Кирелек, үзсүзлелек Тукайда искиткеч рәвештә көчле иде. Аның үз файдасы өчен генә әйтелгән сүзләр дә аңа ярамый торган иде. Бик тиз кәефе китә. Шул сүзләр өчен ул: «Бик акыллы баш икәнсең, Печән базары чатына чыгып, Мөхәммәтҗан Хафизлар белән бергә акыл сатарга тиешсең!» — ди иде.

Авырган хәлдә Нижний (Горький) ярминкәсенә китеп баруы, докторның һәм үзе якын күргән иптәшләренең сүзләрен колакка алмавы — боларның барысын да «үзсүзлелек, кирелек» дип әйтми хәлең юк.

СУРӘТ

Тукай кечерәк буйлы, тәнендә ит юк диярлек ябык. Сул күзендә беленер-беленмәс кечкенә ак тап бар иде. Куллары 13-14 яшьлек кызлар кулы кебек кечкенә һәм йомшак иде. Кәефле чагында шул кечкенә кулы белән кинәт аркага яки култык астына төртү гадәте бар иде. Шул начар эшеннән уттан сакланган кебек сакланырга туры килә иде. Китереп төртсә, тәнеңә кадак каккан кебек була иде.

Тукай белән сөйләшеп танышыр өчен килгән чит кешеләр аның сүзсезлегенә, салкын каравына, сүз таба алмавына аптырыйлар, күңелсезләнәләр иде.

Бервакыт читтән килгән Б.Ильясовны Тукай белән таныштыру өчен кырыгынчы номерга алып мендем. Тукай караватына яткан хәлдә иде. Без кергәч тә, торып утырды. Мин аңар: «Менә бу мосафир — читтән килгән Ильясов була. Синең белән танышасы, утырышасы килә», — дип тәкъдим итеп чыгып киттем. Берничә минут үтмәде, мосафир-кунак идарәгә төшеп тә җитте. Мин: «Нихәл? Нигә бик тиз төштең?» — диюгә, ул гарәпчә: «Тәсмагы бил Мөгайди хәйрен мин ән тәраһе»[5], — дип җавап кайтарды.

ХОЛЫК

Тукайда үз-үзен сөю көчле, ул үзенең татар арасында зур урын тотуын аңлый иде. Язган шигырьләренә зур бәһа бирә иде. Мин-минлеге зур һәм көчле икәне кайбер

[5] Могайдине күреп белүгә караганда, ишетеп белү яхшырак. Гарәп мәкале.

шигырьләреннән Пушкин, Лермонтовлар рәтенә үзен куюыннан ук билгеле. Замандашлары — шагыйрь Сәгыйть, шагыйрь Дәрдемәнд һәм Мәҗит Гафурилардан үзен бик өстен икәнен тыштан белдермәсә дә, эчтән үзенең өстенлеген аңлата иде. Боларның шигырьләре турында берни дә язмавы, болар белән бер төрле дә (Сәгыйтьтән башка) мөнәсәбәттә булмавы, фикер алмашмавы ... минем сүзне раслый булса кирәк.

Тукайда ялкаулык юк түгел иде. Кая гына барса да, ятып тору ягын каера. «Әл-ислах» идарәсенә төшсә дә, өстәлгә яки мин ята торган бүлмәгә кереп, минем караватка ята. Газета чыккан кич типографиянең контора өстәленә менеп ятып йоклый яки үзенең шигырьләрен бөтенләй икенче калыпка салып, җырлап утыра торган иде. Мисал өчен:

Аһ, гөнаһым шомлыгы, бу кучеры бик тын тагын,
Җырламыйдыр бер матурның балдагын йә калфагын!

Шул шигырен үзгәртә:

*И анаңны с*ккере, бу кучеры бик тын тагын,*
Җырламыйдыр бер матурның балдагын йә калфагын!

Башка шигырьләрен дә шулай үзгәртеп җырлау гадәте бар иде. Күп вакыт ул:

Беттем мин — яшь малай, беттем гомергә дә;
Эссе кан, иске шан, кайтмый гомер дә.

Бар микән дөньяда миннән бәхетсезләр?
Хатыным, йортым юк, — ятам номерда,

Саргайдым, зәгъфраннан сары мин.
Бу чокырлы йөзләр тулмас гомер дә, — дип урысларның халык мотивына — «Все говорят»ка салып җырлый иде.

УЕН ДӘРТЕ[6]

Тукай карта, кузна уйнауларны бик ярата иде. Яратып, бирелеп уйный иде. Картадан яратып уйнаган уеннары — «Шестьдесят шесть», «Преферанс» һәм «Тысяча» иде. Бу карта уеннары «Әл-ислах» идарәсендә, Яңа Бистәдә Фатихларда, җәйге фатирыбызда була иде.

Тукай уйнауда отмаса, яки алдан меңгә тутырмаса бик кәефсезләнә, ачулана. Шуның өстенә Фатихның әче сүзләр кушып көлүе Тукайны хурландыра. Кызарып, бүртенеп, кычкырышка кадәр алып бара торган иде.

Кузна уйнаганда (җәйге фатирыбызда) шул ук хәл була торган иде. Тукай отарга тиеш. Чөнки Уралда ул яхшы, төз атучы булып саналган һәм ота торган булган. Казанда Тукай үзеннән кала да төз атып отучылар барлыгына кәефсезләнә, бәйләнә. Кузна уенына Галиәсгар Камал, Тукай һәм башкалар катнашалар. Фатих эскәмиягә утырып, карап кына тора иде. Фатихның карап торуын бер дә яратмый. Фатихның көлеп торуын яратмый. Ничек булса да Фатихны ишегалдына чыгартмаска тырыша иде.

[6] Бу урында, аерым сәбәпләр аркасында, истәлекнең бер өлешен төшереп калдырабыз. Кызыксынучылар булса, текстны хәзерге хәрефләргә аударган Рабит Батуллага мөрәҗәгать итәргә мөмкин. — *Редакция.*

Ике яшьти, ике дус – Габдулла Тукай һәм Фатих Әмирхан. К.Җәмитов эше. 1980 ел

ЯНГЫН

1908 елның март башында кичкә таба Тукай минем номерга кәефле хәлдә килеп керә. Кызыклы сүзләр сөйләп көлдерә. Үзенең кайда булганы, кемнәр белән утырганын сөйли-сөйли минем караватка барып ята. Шул яту белән ул йокыга да китә. Мин Тукай өстеннән бикләп, ачкычны официантка биреп, берәр сәгатьтән кайтачагымны, Тукайның номерда йоклап калганын белдереп, үз эшем белән чыгып китәм. Бервакыт коридорга төтен чыкканы, төтен куерганы беленә. «Бу нинди эш?» — дип шау килә башлыйлар. Минем номерны ачып карасалар, караватка җәеп куелган простыняның пыскыганын, Тукайның йоклап ятканын күрәләр.

Мин кайткач, официант вакыйганы аңлата, сөйләп күрсәтә. Мин номерны ачып кергәндә идәндә җәймә, мендәр, одеал ята иде. Җәймәнең бер почмагы янган, одеалның почмагы саргайган, мендәрнең дә бер почмагы аз гына янган. ... Баш абзый (номер хуҗасы) мине чакыртып бу эш өчен каты итеп тәнбиһ (кисәтү) ясады.

Мин, бүлмәне рәтләп бетергәч, Тукай янына менеп киттем. Ул йоклап ята. Мин йокысыннан уяттым. Ул, берни дә булмагандай, ярым йокылы хәлдә, бик кызык итеп, номерда пожар булганын, пожарга бөтен шәһәр пожарныйларының, пожарный майорларның, бутышникларның (татарлар арасында постовой полицейскийлар шулай йөртелә иде), Гобәйдулла унтерның да килеп, сүндерүләрен матур итеп сөйләп көлдерде.

Бу вакыйга болай булып чыга. Тукай, йокысыннан торып, папирос кабыза. Яңадан йоклап китә. Сүнмәгән папиросы җәймәгә тиеп яки төшеп, җәймә пыскып яна башлый, җәймәдән ут одеалга, мендәргә үрли.

Ахыры киләсе санда ■

ИЛҺАМ КАНАТЛАРЫНДА

Фоат Галимуллин

Билгеле булганча, егерменче гасырда татар халкының телен рәсми даирәләрдә гамәлгә кертүдә, ул үтәгән вазифаларны киңәйтүдә, әдәбиятыбызны үстерүдә, тарихыбызны өйрәнүдә зур уңышларга ирешелде. Моңа әле инкыйлабка кадәрге елларда ук ныклы нигез салына башлады: Г.Тукай, Г.Исхакыйлар чорына күз салу да җитә. Сүз дә юк, бу алгарышка 1925 елда Казан Көнчыгыш педагогия институтында татар теле һәм әдәбияты кафедрасының оештырылуы да зур этәргеч ясады.

Беренче рәттә: Фәнис Яруллин һәм әнисе Гафифә апа КДПИның тарих-филология факультеты студентлары белән. 1970 нче еллар

Аның юл башында күренекле галимнәр Г.Сәгъди, Г.Рәхим, Җ.Вәлиди, Г.Шәрәф, Н.Мөхетдинов, Г.Нигъмәти, М.Корбангалиев, М.Фазлуллин, Г.Алпаров, Х.Бәдигый, Н.Хәкимов, бераз соңрак М.Гайнуллин, Х.Госман, М.Мамин, Җ.Вәҗиева, Я.Агишев, Л.Җәләй, Х.Ярми, А.Сайганов, М.Сәгыйтов, Ф.Вәлиева, М.Җәләлиева һәм башкалар тора. Институт эшчәнлегенең беренче елларыннан ук алар татар бүлегендә иҗади мохит булдыруны максат итәләр. Бу яктан Гали Рәхим аеруча тырышлык күрсәтә. Әдәби түгәрәк оештырып, яшь егет-кызларның иҗат белән мавыгып

Беренче рәттә: Ф.Хатипов, М.Җәләлиева, С.Хәким, И.Юзеев, (...), М.Сәгыйтов. Икенче рәттә (сулдан өченче): Р.Сверигин. Һәм II курсның 208 нче төркеме кызлары. 1977 ел

китүләренә этәргеч бирергә тырыша. 1924 елда (әле кафедра оештырылганчы ук) биредә дивар газетасы чыгарыла башлый. Аңа Гадел Кутуй тәкъдиме белән «Укы-төзе» исеме бирелә. Беренче санын тулысынча Хәсән Туфан яза. Газета айга ике тапкыр чыгарыла. 1924 елда унике саны дөнья күрә. Һәр санында Х.Туфан актив катнаша. (Казан утлары. — 1987. — №2. — Б.179-181.) 1926-1929 елларда татар бүлеге үзенең иҗтимагый-сәяси һәм әдәби журналын чыгара. Ул «Яшь педагог» дип атала. Басмада Г.Кутуй, Г.Кашшаф, Ә.Еники, Ф.Даутов, М.Богданова, М.Кашафетдинова үз әсәрләрен бастыра. 1928-1929 уку елында, мәсәлән, биредәге фәнни-әдәби түгәрәктә иллегә якын студент шөгыльләнгәне мәгълүм. 1926-1927 уку елында институтта Һ.Такташ, Г.Бакир белем ала. Һади Такташ кулларына иҗат каләме алган яшьләр белән даими очраша, аларны үзенең әсәрләре үрнәгендә рухландыра. Г.Кутуйның да әлеге түгәрәктә еш чыгыш ясавы билгеле. 1932-1933 уку елыннан биредә булачак шагыйрь Хәбра Рахман укый. Аны әдәби түгәрәк җитәкчесе итеп сайлыйлар.

Әмма утызынчы елларның икенче яртысыннан соң (репрессияләр көчәйгән чорда) иҗади мохит зәгыйфьләнә, әкренләп юкка чыга. Аннан сугыш еллары... Ниһаять, илленче еллар башында биредә иҗат эшләре яңадан тернәкләнеп китә.

Менә минем алда 1954 елда Казан дәүләт педагогия институтының татар әдәбият-иҗат түгәрәгендә катнашучылар чыгарган кулъязма альманах — «Яшьлек тавышы». Аның тышына «№5» дип куелган. Димәк, әле монысына кадәр дүрт сан булган инде дигән сүз. Бәлки, алтынчысы, җиденчесе дә булгандыр. Әмма хәзергә табылганы — шул берәү генә. Ул югары уку йортыбызның татар теле һәм әдәбияты кабинетында сакланган. Укырга теләгән кешегә аны, нәкъ китапханәдәге кебек, формуляр белән биргәннәр. Шушы нөсхә эченә очраклы рәвештә, күрәсең, тагын бер формуляр килеп кергән. Ул «Яшьлек тавышы»ның өченче санынык. Бу сан 1951 елда чыккан. Аны шушы кабинеттан 1952



елның 26 октябрендә икенче курс студенты Илдар Юзеев алып торган. Формулярда Илдар абыйның бик тә таныш култамгасы бар. Күрәсең, аның биредә эшләүче иҗат түгәрәге эше белән кызыксына башлавы, анда катнашучыларның иҗат үрнәкләре белән танышырга теләве булган.

Аның каруы, өченче белән бишенче саннар арасында без И.Юзеевның шагыйрь буларак шактый танылуга ирешүен күрәбез. Байтак шигырьләр белән беррәттән, шушы ике-өч елда ул «Тормыш җиңә» дигән поэма да язып өлгергән! Аны «Яшь сталинчы» газетасының 1953 елдагы 132, 134, 135 саннарында һәм «Үсү юлы» альманахының алтынчы китабында бастырып чыгаруга да ирешкән. «Яшьлек тавышы»ның без сүз йөрткән санында исә шушы поэмага карата Марс Шабаевның бәяләмәсе урнаштырылган. Ул шәриктәшенең әсәре турында үз итеп, яратып, шул ук вакытта, таләпчәнлек күрсәтеп яза. Киләчәктә үзе дә шагыйрь булып китәчәк М.Шабаев И.Юзеевның күренекле элгәребез Һ.Такташ шигъри мәктәбенең дәвамчысы икәнлеген әйтә.

Поэма кинәт авырып китеп хастаханәгә юлыккан Равил исемле студент егетнең уй-хисләрен бирү белән башлана:

Институт!
Синнән аерылуга
Ике көн дә әле булмады,
Сагындым да инде...
Күңелемне
Әллә нинди уйлар чорнады.
Сагындым мин
Якын дусларымны,
Институт, якты залларыңа
Кайчан кайтырмын соң тагын мин?

Бу шигъри юллардан без үзе укый торган институтның лирик герой (һәм автор) тормышында нинди мөһим урын тотканын күрәбез. Бу — яшь каләм ияләренең һәммәсе өчен уртак хис, уртак уйлар. Язмалардан Казан педагогия институтының аларга никадәр якын, кирәкле һәм кадерле урын булганлыгы анык сизелә.

Марс Шабаев үзе дә шигырьләр яза. «Шаян күзләр» исемлесе башлап язучы өчен шактый уңышлы тоела. Егет очраклы рәвештә күреп калган бер кызга гашыйк була. Шуннан соңгы көннәре аны кабат очратырга теләп уза. Ниһаять, очрата. Кыюлыгы җитеп таныша да. Әмма бу танышу аңа шатлык бирми.

Без таныштык.
Исеме — Халисә.
Гади генә итеп әйтеп куйды:
— Син булырсың «запас колесо»?!

Ягъни, лирик герой теге кыз өчен яратышып йөри торган бишенче (!) егет булып чыга. Тегеләрнең берәрсе юлда төшеп калган очракта гына, «запас» булудан туктап, «төп тәгәрмәчләр»нең берсенә әверелүе мөмкин. Кайсы чын егет өлешенә тигән бу көмешенә риза булсын, ди? Шуңа күрә мондый нәтиҗә табигый дә:

«Илһам»да – илһамчылар гына! 1993 ел

Кыскасы шул:
Ул кемлеген ачты.
Сүз әйтергә аңа чиркәндем.
Телим, дуслар, кабат очрамавын
Шомырт кара күзле «иркәмнең».

Менә шундый табышлар тагын очрап тора әле. Авторлар арасында без С.Сафуанов, Х.Камалов, Ә.Заманов, С.Поварисов, Г.Энҗе, Р.Шакиров, Р.Гарипов, Г.Мөхәммәтшиннарны күрәбез. Барысы да диярлек институтның татар теле һәм әдәбияты бүлеге студентлары. Аларның киләчәге дә матур булды. Суфиян Поварисов — фән докторы, Башкорт дәүләт университеты профессоры, классик әдибебез Галимҗан Ибраһимовның тормыш юлына багышланган трилогия иҗат итте; Хисам Камалов — Татарстанның халык язучысы, Ватан сугышы хакыйкатен чагылдырган трилогия авторы; Суфиян Сафуанов — әдәбият галиме, Башкорт педагогия институтында кафедра мөдире, доцент булды. Һәммәсе дә сүз сәнгате, мәгариф, фән үсешенә зур өлеш керттеләр.

Аннан соң бу эстафетаны Гөлшат Зәйнашева, Ләбиб Айтуганов, Роберт Әхмәтҗан, Ренат Харис, Лена Шагыйрьҗан, Эльс Гадел һәм башкалар дәвам итте.

Альманахның редколлегия составы да күрсәтелгән. Иң беренче булып М.Җәләлиева исемен язып куйганнар. Әйе, илленче еллар башыннан әдәби түгәрәк белән кафедраның яшь укытучысы Мәдинә Җәләлиева җитәкчелек итә. Түгәрәккә «Яшь көч» дигән исем дә бирәләр. Шул исемдәге дивар газетасы да булдырыла. Ул, биш-алты метр озынлыкка җитеп, айга бер чыгарыла. Анда урнаштырылган әдәби әсәрләр һәм бизәлеше, һәм эчтәлеге ягыннан укучыларның игътибарын ала, бигрәк тә сатира-юмор өлеше кызыклы итеп оештырыла.

«Татарстан яшьләре» газетасының 1967 ел 16 сентябрь санында, әлеге түгәрәккә багышлап бит тутырып материал биргәннәр. Аны М.Җәләлиеваның «Безнең түгәрәк» дигән мәкаләсе ачып җибәрә. Хөрмәтле укытучыбыз иҗат коллективының үткәне, традицияләре, шул еллардагы эшчәнлеге белән таныштыра. Аннан соң алтмышынчы

Татар дәүләт гуманитар-педагогика университеты ректоры Рәдиф Җамалетдинов «Илһам» әдәби-иҗат берләшмәсе әгъзалары белән. 2009 ел

елларда укыган студентлар каләменнән төшкән күңел әсәрләре тәкъдим ителә. Алар арасында Рафаэль Баяновның «Тукай шигырь укый», Нурулла Гаптуллинның «Рәйхан», Фәһим Миначевның «Синең күзләрдән мин куркам», Разит Сибатовның «Укытучыма» дигән әсәрләре бар.

1974 елда мин институтка укытучы булып эшләргә чакырылдым. Беренче очрашуда ук Мәдинә Шәйхи кызы:

— Мин әдәби түгәрәк эшен егерме елга якын тартып киләм. Шулай да, яңа сулыш кирәклеген сизәм. Әйдә, шушы эшне син алып кит әле, — диде. Кафедра мөдире Фәрит Хатипов белән сөйләшкәннән соң, без түгәрәкнең эшчәнлеген колачлырак итеп оештырырга булдык. Иң әүвәл аны иҗат берләшмәсе дип атадык. Исемен дә уйлап таптык — «Илһам». Дивар газетабыз да шул исем белән атала башлады. Рафис Гыйззәтуллин, Зиннур Хөснияр, Марат Закир кебек хәзер инде чын-чынлап танылган язучылар нәкъ шул елларда үсеп чыкты.

Миннән соң бу иҗат коллективы белән үзе дә шагыйрь булган Әмир Мәхмүдов җитәкчелек итте. «Татарстан яшьләре» газетасының 1984 ел 1 май санында аның «Илһам юлдаш булсын сиңа, Илһам!» дигән мәкаләсе һәм бер төркем талантлы яшьләрнең шигырьләре урын алган. *«Хәзерге көндә,* — ди Әмир Гобәй улы, — *әдәби студиянең эшендә кеше тормышының үзенчәлекле якларын ачып бирергә омтылучы, кешенең уй-кичерешләрен тасвирлаган әсәрләр авторы Рәшит Фәтхерахманов, лирик хисләрне чагылдыручы Роза Зайцева, табигать күренешләре турында җылы итеп, үзенә генә хас фикерләр әйтүче Фәридә Фәйзрахманова, тормышчан шигырьләр иҗат итүче Венера Салахова, мәхәббәт хисләрен шигъри юлларда гәүдәләндерүче Рухия Ахунҗанова, Зөлфия Хәмзина, Раушания Сәхапова, Нәфисә Гыйззәтуллина кебек яшь язучылар һәм шагыйрьләр актив катнаша».* Исемнәре аталган яшьләрнең әсәрләре дә тәкъдим ителгән. Рухия

Ахунҗанованың, мәсәлән, «Син» дигән шигыренә күз салыйк:

Синең тормыш — тирән дәрья,
Үзең мәгърур тау идең.
Шау чәчәкле болыннан мин
Сиңа карап баш идем.
Тоярга теләдем сине
Илаһи бер зат итеп.
...Ләкин киттем җанны кыйган
Авыр сүзең ишетеп.

Рухия хәзер шигъри җыентыклар авторы, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы. Р.Фәтхерахманов исә — филология фәннәре кандидаты, республика газеталарында үткен-үткен мәкаләләр бастыручы журналист.

Мәгълүм булганча, 2005 елда Казан дәүләт педагогика университетына Татар дәүләт гуманитар институтын куштылар, ике югары уку йортыннан берне ясадылар. Ул Татар дәүләт гуманитар-педагогика университеты дип атала башлады. Гуманитар институтта «Дастан» исемле түгәрәк эшләп килгән. Шулай итеп, иҗат берләшмәләре дә кушылды, тагын да киңәйде, ныгыды. Миңа, ул вакытта татар әдәбияты кафедрасы мөдире буларак, әлеге талантлы яшьләрне бергә тупларлык сәләтле җитәкче табарга кирәк иде. Шушы җаваплы эшкә аспирантлардан Рамил Ханнанов белән Марат Миндубаевны билгеләдек. Тора-бара анда Рамил үзе генә калды. Ул диссертация яклады, филология фәннәре кандидаты исемен алды, кафедрада укытучы булып та хезмәт кыла башлады. Бер үк вакытта «Илһам» иҗади берләшмәсе эшен яхшы ук җанландырып җибәрде.

Әйе, соңгы елларда «Илһам» иҗат берләшмәсенең исеме, Татарстан чикләрен үтеп, милләттәшләребез яши торган башка төбәкләргә дә барып җитте. Ник дигәндә, аның эшчәнлек даирәсе нык киңәйде. Ел саен «Илһамлы каләм» дигән иҗади конкурс оештырыла (быелдан ул «Илһам» дип кенә атала башлады). Анда, Татарстаннан тыш, башка республикалардан, өлкәләрдән һәм крайлардан өлкән сыйныф укучылары катнаша. Апрель аенда — Габдулла Тукайның туган көне алдыннан — йомгак ясала, җиңүчеләргә бүләкләр тапшырыла, иң яхшы әсәрләрдән «Илһам канатында» дигән җыентык чыгарыла.

2010 елда чыкканына кереш сүзне Татарстанның беренче президенты М.Ш.Шәймиев язды. Аерым алганда, анда мондый юллар бар: *«Заманында бирелдә белем алган Шәйхи Маннурның бер шигыре искә төшә:*

Агымсулар язда ярсуын
Күреп үскән яшь дус, яшь буын!
Биреп бөтен яшьлек җылыңны,
Син дәвам ит инде җырымны, —
Син җырлап бир инде чорыңны!..

Минем исәпләвемчә, бу шигъри юллар шулкадәр тирән мәгънәле. Әйе, без һәрберебез үзе яшәгән чор өчен җаваплы. Бөтенесе дә бездән, шушы вакытта яшәүчеләрдән тора. Иҗатта да шулай. Заманында Кол Гали, Мөхәммәдьяр, Гаяз Исхакый, Галимҗан Ибраһимов, Муса Җәлил, Фатих Кәримнәр булган. Алар үз чорларында җилкәләренә төшкән бурычларны мөмкин булганча хәл иткәннәр. Тарихта бөекләр булып калганнар. Әмма бүгенгене алар җырлый алмый инде. Бу сезнең өлешкә төшә. Шәйхи бабабыз шул турыда әйтә. Без, бүгенгене иҗат итеп, тарихны тудырабыз. Килер буыннар аны сезнең әсәрләр ярдәмендә өйрәнеп беләчәкләр. Нәкъ менә сезнең каләм ярдәмендә татар әдәбияты башка кыйтгаларның сүз сәнгатьләренә якынаячак. Әмма, шул ук вакытта, үз традицияләребезне дә күз карасыдай сакларга тиешбез. Башка халыкларга без шуның белән кызыклы. Менә сезнең алда нинди катлаулы, олы бурычлар тора. Аларны бары тик сез — бүгенге югарылыктагы белем белән коралланган яшьләр генә хәл итә аласыз. Бу

юлда хәерле, куанычлы иҗат юлдаш булсын!»

Әлеге җыентыкны тәкъдим итү кичәсе ел саен зур бәйрәмгә әверелә. Биредән үсеп чыккан Рүзәл Мөхәммәтшин Муса Җәлил бүләгенә лаек булды, Рүзәл Әхмәдиев тә китапларын чыгарып куандырды.

Әйе, иҗат берләшмәсенең эше елдан-ел колачлырак була бара. Алга таба да талантлы яшьләрне үстерү кебек игелекле гамәлен ул яңа көч белән дәвам итәр, дигән ышаныч зур. Ник дигәндә, алга таба «Илһам» классик университеттагы бертуганы — «Әллүки» иҗат берләшмәсе белән бергә атлап китәчәк.

Хәер, сүз башым — «Яшьлек тавышы» иде бит.

Укучыларыбыз игътибарына шул кулъязма журналдагы берничә шигырьне тәкъдим итик әле…

«Яшьлек тавышы»ннан шигырьләр

Хисам Камалов

***

Саф сөюең мине җилкендерде,
Куәт бирде авыр булганда.
Шуның өчен рәхмәт укыйм безне
Очраштырган якты юлларга.

Ләкин бүген
Шул ук юллар сине
Еракларга алып чаптылар.
Мин ялгызым калдым кулым изәп,
Ә йөрәгем янды көйрәп-көйрәп,
Күз яшьләрем шунда актылар…

Арабызда хәзер биек таулар.
Тик шулай да миндә мәхәббәтең
Кайнарлана, һаман яктыра.
Кояш та бит ерагайган саен
Үз җылысын ныграк арттыра.

Аерылышу авыр сагыш түгел,
Кавышу язы алда булганда.
Мин һаман да рәхмәт укыйм безне
Очраштырган якты юлларга.

***

Юк, Миңнегөл,
Фотоң бүләк итмә.
Үзең нәкъ гөл,
Үзең нәкъ чәчкә
Кебек менә
Күңелемдә һаман үсәсең,
Синең белән шундый җиңел миңа,
Син бәхетле мине итәсең.

Сылу сының
Һаман тамыр җәя,
Чәчәк ата минем күңелдә.
Давылларга бирешмәслек булып
Һәм кичәрлек булып диңгезләр.

Юк, фотоңны бирмә,
Болай да әле
Ташу кебек җаным ашкына.
«Минем образ синең йөрәгеңдә
Булсын, диген», — шунсы яхшырак.

***

Гомер үтә…
Алмагачлар тагы
Чәчкә түгел,
Ак бәс белән инде төренгән.
Чал толымлы башын иеп, каен
Тезенә тиң көрткә күмелгән.
Кыш, утырып агай мыегына,
Өйгә кайткан басу түреннән…



Кыш шулай ул,
Бөтен нәрсәләрне
Буйсындыра, имеш, үзенә.
Тик без кышка һич тә бирешмәбез,
Гомер үтә диеп,
Күңелләрне төшереп йөрмәбез.

Карлар яусын,
Ачы суык булсын,
Кышын шулай матур бигрәк тә.
Буран булсын,
Кар муенга тулсын.
Кыш булмасын ләкин йөрәктә.

Газиз Мөхәммәтшин

КАРГА БЕЛӘН ТӨЛКЕ
(Крылов буенча)

Начальник итеп куйдылар карганы,
Зур бер портфель тоттырдылар аннары.
Авызына портфель кабып,
Бер чыршы ботагы табып,
Кунды карга.
Шул чыршыда тыныч кына утырганда,
Карганы хәйләкәр төлке күреп
Агач төбенә килә дә, туктап кала.
Уйлый хәзер безнең төлке эчтән генә:
«Бүре дусны очраттым кичә генә;
Ташларга бу авыр эшен,
Башка җиргә күчү өчен
Печать баскан буш кәгазьләр кирәк,
диде,
Тик табалмыйм, чөнки алар сирәк,
диде.
Ә минемчә,
Ул кәгазьләр шушы портфель эчендә.
Төшерәлсәм әгәр аны кулларыма,
Симез тавык бүләк итәр бүре кода».
Портфельдән һич тә алмый күзен,
Юхаланып башлый сүзен:
— Ах, кадерлем!
Зур урында эшләвеңне бик соң белдем,
Тик шулай да,
Карамыйча башкаларга,
Ашыктым сине котларга.
Дусларыма мактыйм сине һәр урында,
Каргадан да акыллы кош юк дөньяда.
Җырласа, ул бар кошларның
һушын ала.

Каргаларны тыңлаганда,
Хәтта җырчы сандугач та тынып кала.
Шатлыгымнан көчкә алып
сулышымны,
Бик еш тыңлыйм сине — җырчыбызны.
Җырла, дустым!
Ишетим моңлы тавышыңны!
Бу мактаудан тәэсирләнде
безнең карга:
Төлке сүзеннән туктауга,
Каркылдады ямьсез итеп.
(Портфель җиргә китте төшеп.)
Шуны күтеп торган төлке
Җитез генә алды аны,
Ә аннары
Яшерен кәгазьләрнең барсы
белән бергә
Алып китте бүре дусның өенә.

Кайвакытта портфель ала каргалар,
Һәм еш кына төлкеләрнең тозагына
каба алар.

Суфиян Поварисов

СТУДЕНТ КЫЗГА

Китабыңны тотып уң кулыңа
Син каршыма, иркәм, чыгасың.
Айлы кичтәй булып, алларыма
Гөлдәй сының белән торасың.

Керфекләрең сирпеп карыйсың да,
Кулларыңнан алсаң, качасың.
— Сөям… — дисең үзең, ә соң нигә
Мине түгел, китап кочасың?

Беләм, дускай, якты киләчәккә
Шул томнардан син көч аласың,
Яшьлегеңнең ямен, тормышыңның
Матурлыгын шуннан табасың.

Мин дә шулай корыч станокны
Йөрәк җылым белән яратам.
Күпкә түгел, чирек минутка да
Аерыласым килми заводтан.

Син — ВУЗ кызы,
Ә мин — завод улы,
Бер үк хисләр белән янабыз.
Бер савытта үскән пар гөлләр күк,
Безне үстерә Ватан-анабыз.

Син беләсең моны…
Белмисең күк
Йөрәгемнең көю ялкынын.
Китабыңны кысып кочкан кебек,
Мине дә коч инде, алтыным!

ТРАКТОРЧЫ ҖЫРЫ

Матурлыгың белән чорнап безне,
Әй, тыныч яз, тизрәк кил инде.
Хезмәт дәрте белән ярсып типкән
Йөрәк ашкынуын бел инде.

Тракторым минем күптән әзер,
Гүя, ул да түзми, эш көтә.
Җәйге таңда басу гөрләтүләр
Искә төшеп мине җилкетә.

Җылы нурларыңны, кояш, чәч тә
Эрет инде тизрәк карларны,
Әллә нигә, күңел түзми һич тә,
Бик сагындым иркен кырларны.

Матур итеп, кызлар тасмасыдай,
Буразналар килә сызасы.
Очар кошлар кебек талпынамын,
Кырга тизрәк килә чыгасы.

ЧЫН МӘХӘББӘТ

Күзләреңнән сөю ялкыннарың
Кирәк булган өчен эзләдем.
Карашыңда күргәч керсез нурлар,
Әйтми, дустым, сиңа түзмәдем.

Бик күп күзләр миңа һаман әле
Сөю карашлары ташлыйлар.
Ләкин алар минем күңелемдә
Синекедәй урын тапмыйлар.

Тик бирәүгә, сиңа, яшьлегемнең
Кайнар мәхәббәтен бирәмен.
Чын мәхәббәт аша тормышымның
Яктылыгын күбрәк күрәмен. ■

ЯҢГЫРАП ТОРГАН МИРАС КАЛДЫРДЫ...

Килер бер көн: татар теленең чисталыгын-сафлыгын саклау мәсьәләсе көн үзәгенә килеп басар. Менә шунда инде бу мәсьәләне хәл итү юллары-чаралары турында баш вату башланачак... һәм башка бик күп күләгәдә калган казанышлар белән беррәттән, Татарстан радиосында 1927 елдан бирле тупланып килгән тәҗрибә дә искә төшәчәк. Ә бит бар иде заманнар: Камал Саттарова, Айрат Арсланов, Мәрьям Арсланова, Фоат Галимуллин кебек радио дикторларын тыңлап, кешеләр үз сөйләмнәрен камилләштерә, хаталарын төзәтә иде. Радио, хәбәр-мәгълүмат җиткереп кенә калмыйча, чын мәгънәсендәге ана теле мөгаллиме вазифасын да башкарып килде.

Әлбәттә, Татарстан радиосы бу бурычны әле һаман да хәл кадәренчә үтәп бара, ләкин аны тыңлаучыларның сафы инде элеккечә түгел. Әйе, менә шул вакытта Татарстан радиосында сигез дистә ел дәвамында тупланган һәм бүген дә үстерелә баручы байлыкның кирәге чыгачак әле! Габдулла Камал, Фәйзи Кавалинский, Кәшифә Тумашева, Мохтар Мутин, Гали Хөсәенов, Госман Әхмәтҗан, Фәрит Җәләй кебек режиссёрлар тудырган, үстергән һәм камиллек дәрәҗәсенә күтәргән, хәзерге вакытта Әлфия Гыйлаҗи, Рамил Һидиятулла тарафыннан дәвам иттерелүче режиссура мәктәбен дә яңадан калкытып чыгарырга, өйрәнергә туры киләчәк.

Сүзне бик ерактан башлаганыма ачуланмагыз, режиссёрның радиода тоткан урынын ачыграк, төгәлрәк аңлатып бирү өчен шулай кирәк табылды. Микрофон алдына килгәнчегә кадәр журналистлар, чакырылган кунаклар, артистлар, хәтта телнең чын осталары — дикторлар да әле башта нәкъ менә режиссёр иләгеннән иләнә иде бит. Шуңа күрә бер генә хаталы сүз дә, логик басымы дөрес куелмаган җөмлә дә эфирга чыкмады; радиоспектакльләр дә тыңлаучыны мавыктырып, сиздерми-нитми генә татар теленә өйрәтү дәресенә тиң иде.

Менә шушы югарыда телгә алынган режиссёрлар арасында үз эшенә иң нык бирелгәне, иң озак хезмәт куйганы, әлбәттә, Госман Нигъмәтҗан улы Әхмәтҗанов иде. Без, радио хезмәткәрләре, барыбыз да, аны үзебезнең остазыбыз дип саныйбыз. Ә ул үзенең 75 яшьлек юбилее кичәсендә әйтте дә салды: *«Үземә кадәр эшләп эз калдырган режиссёрлар, артистлар, редакторлар, хәтта әле яңа гына килеп эшли башлаган яшь журналист-*

лар, гомумән, аралашкан һәрбер кеше —остазым, мин алардан нәрсәгә дә булса өйрәнеп калам», — диде. Әйе, бу дөрес, Госман абый гомере буе өзлексез укыган, акыл-фәһем җыйган энциклопедик белемле, хәтта олыгаймыш көннәрендә дә яңалыктан кызык табу, хыяллану, фантазиягә бирелү сыйфатлары дөрләп торган чын иҗат кешесе иде.

Аның тормыш юлы турындагы мәгълүмат безнең кулга иң ышанычлы чыганактан килеп керде. Ул — Госман аганың үз тавышы, аның әлеге дә баягы 75 яшьлек юбилее уңаеннан радиога биргән интервьюсы. Шушы язманы кәгазьгә төшереп, беркадәр шәрехләп барыйк.

«Мин 1925 елның 23 июнендә, ягъни үземнең хәләл җефетем Кадриядән бер көн алда, Әтнә районының Югары Бәрәскә авылында туганмын. Кадрия Түбән Бәрәскәдән, — дип башлаган әлеге әңгәмәне Госман ага. — *Гаиләбез урта хәлле крестьян санала иде. Колхозлашу елларын, авыл уртасындагы таш мәчетне ничек сүтүләрен, манарасын аударуларын хәтерлим. Без, малайлар, һәркайда булырга өлгерә идек. Әтнә янганын әвен түбәсеннән карап тордык. Усалланып йөри дип, мине укырга иртәрәк бирделәр. Үземнән бер яшь олылар — 24 нче елгылар белән укыдым. Яхшы укыдым, актив малай булдым. Стена газетасына шигырьне дә миннән яздыралар иде...»*

Бу урында Госман ага белән килешмәскә мәҗбүрбез. Ул үзен «урта хәлле крестьян гаиләсеннән» дисә дә, фактлар башкачарак сөйли. Эш шунда ки, Госманның бабасы Әхмәтҗан, Габдулла Тукайның атасы Мөхәммәтгариф һәм күренекле мәгърифәтче, дин эшлеклесе Төхфәтулла Мотыйгуллин Кышкар мәдрәсәсендә бергә укыганнар. Мөхәммәтгариф белән Төхфәтулла хәзрәтнең язмышы укучыга мәгълүм. Ә менә Әхмәтҗан, мәдрәсә тәмамлагач, Югары Бәрәскәдә муллалык итә. Ул

еларда җәдитчелек хәрәкәтенең канат җәйгән чоры була. Әхмәтҗан хәзрәт, кадими диндарларга ияреп, авылга яңа ысул белән укытуны кертмәскә сүз бирә. Тик үз улы Нигъмәтҗанга ничек тә җәдитчә белем бирәсе килә хәзрәтнең. Һәм ул малайны Җаекка, сабакташ дусты Мотыйгыйның данлыклы мәдрәсәсенә озата, артыннан ук почта аша хат та җибәрә. Хат, ни сәбәптәндер, барып ирешми, шулай итеп, Нигъмәтҗан мәдрәсәгә урнаша алмыйча кала. Олы Бәрәскәдән чыккан бер Җаек баена тамак хакына хезмәткә ялланырга туры килә аңа.

Госманның үзенә кайтыйк. Ул авылда җидееллык мәктәп тәмамлагач, Казан күн техникумына укырга керә. Әтисе үлеп китү сәбәпле, гаиләсенә ярәм итү өчен авылга кайтырга мәҗбүр була. 1941 елның 22 июнь көнендә аны Донбасска ФЗӨ гә җибәрәләр. Немецлар якынлаша башлагач, туган җиренә качып кайта. Егет ат белән Коркачыктагы запас аэродром төзелешенә мобилизацияләнә. Җелекләрне суыра

торган авыр эш, җитмәсә, ашау ягы такы-токы гына, фураж бирелми — атыңны үзең кайгыртасың. Соңыннан гына хәлләр бераз җиңеләя башлый.

1942 елның ахырында Госман туган авылына кайта, призывник буларак, хәрби өйрәнүләрдә катнаша. 1943нең гыйнварында армиягә алына һәм Сарапул шәһәрендә урнашкан Смоленск пехота училищесына җибәрелә. 1943нең июнендә чыгарылыш имтиханнары да биреп өлгермәгән курсантларны фронтка озаталар. Солдат Госман башта 26 нчы гвардия укчы полкында, аннары 79 нчы полкның миномёт батареясында сугыша. Миномётның 40 кг авырлыктагы терәк плитәләрен күтәреп, күп чакрымнар үтәргә туры

Госман ага әллә кайдан ук үзенә җәлеп итеп торучы баһадир түгел иде. Тышкы яктан. Җиңел сөякле җыйнак гәүдә, салмак хәрәкәт, хәтта бераз кызып киткән чакларында да тавышы талгынлыгын югалтмый. Әмма эшкә батыр иде Госман ага.

килә аңа. 1943 елның 18 августында балтыры яраланып, Кисловодск каласындагы госпитальгә озатыла. Бераз савыга башлагач, туган авылына кайта, хәл кадәренчә, гаиләсенә булыша. 1945 елда яңадан мобилизацияләнеп, Казандагы Синтетик каучук заводына эшкә җибәрелә.

«Үземнең театр сәнгатенә килүем очраклы рәвештәрәк булды, — дип дәвам иттерә Госман ага радиода язылып калган әңгәмәсендә. — *1945 елның 9 маенда, Җиңү көнен бәйрәм итеп йөргәндә, урамда театр училищесына укучылар кабул итү турында афишага тап булдым. Мең бәла белән заводтан эштән китеп, училищега керүгә ирештем. Аягым аксак булса да алдылар — төзәлүгә таба бара иде. Дүрт ел укып, училищены алтын медаль белән тәмамлаучылардан алты кешене академия театрына алдылар: Айрат Арсланов, Мәрьям Арсланова, Шәүкәт Биктимеров, Рәис Сафиуллин, Рауза Ибраһимова һәм мин.*

Үземнең сәнгатькә, әдәбиятка тартылуымны берничә фактордан күрәм. Беренчедән, Тукай факторы. Без сеңлем һәм энем белән әле мәктәпкә кергәнче үк, «Сак-Сок» бәетләреннән, «Йосыф» китапларыннан тыш, Тукай шигырьләрен әтидән ишетеп үстек. Ул Уральскида чагында Тукай белән нык аралашкан. Укыргаязарга өйрәнә алмый калса да, зиһене бик зирәк иде аның, Тукайның үзеннән ишеткән шигырьләрне яттан белә иде. Бигрәк тә «Теләнче» шигырен матур итеп көйләп укый иде. Мин инде үзем укый башлагач, әтинең бер хатасын таптым. «Менә бу китапта башкача язылган», — дидем. «Нәрсә минем башымны катырасың?! Мин Тукайның үзеннән ишеттем, китапка аны үзгәртеп басканнар», — дип ачуланды әти. Тукай солдатка каралырга кайткач, алар Әтнә базарында очрашканнар. Тукай әтигә үзенең буйга төшкән фоторәсемен бүләк иткән. Ул чакта фоторәсем бирү иң якын кешеләр арасында гына булган. Ул фотоны Казандагы туганнарыбыз Әмирхановлар, музейга бирәбез, дип алганнар, аннан соң язмышы ничек булгандыр, безгә билгеле түгел. Икенче фактор — безнең әти оста гармунчы, оста биюче иде. Абыем Гарифҗан да, мин дә гармунчылар булдык. Разыя апам бик матур җырлый иде, республика смотрларында беренче урынны алды. Сеңлем Нәфига да оста җырчы иде. Ләкин язмыш аларга сәнгать юлын ачмады.

Гомумән, безнең авыл талантлы кешеләргә бай. Мәсәлән, минем кордашым Равилнең әтисе Шадра Ярулла дигән кеше әле шаян, әле лирик җырлары белән таңга калдыра иде. Хәйруллин Габделхай «Мунча пәрие» дигән шигырьне сөйләгәндә халык тәгәрәп көлә иде. Ә безнең сабак-

Госман Әхмәтҗан Сания Хамматова һәм Варис Зиннәтуллин белән. 1981 ел

таш Нәзирә Сабирова: «Гармуныңның телләре лә, телләре! Сәлимәсе, Зәйтүнәсе, Дилбәре...» дип, «Гармун» шигырен сөйләгәндә тын да алмый тыңлый идек. Без, малайлар, барыбыз да аңа гашыйк булып йөрдек. Укытучылар коллективы да бик көчле иде. Алар куйган «Галиябану» минем өчен бүген дә эталон кебек күңелдә саклана. Шулай булгач, минем сәхнәгә, сәнгатькә омтылышым бик табигый. Безнең Бәрәскә авылы, гомумән, татар театрына иң күп артистлар биргән авыл. Хәким абый Сәлимҗанов, аның хәләл җефете Галия апа Нигъмәтуллина, соңрак — Рәфкать Бикчәнтәев. Аның улы Фәритне дә Югары Бәрәскә үзенеке дип саный. Илдар Хәйруллин — безнең Бәрәскә кешесенең оныгы. Бакир улы Марсель Җаббаров, минем туганнан туганым Зөлфирә Зарипова... Күрәсез, никадәр кеше килгән театрга Бәрәскәдән!..»

Госман ага әллә кайдан ук үзенә җәлеп итеп торучы баһадир түгел иде. Тышкы яктан. Җиңел сөякле җыйнак гәүдә, салмак хәрәкәт, хәтта бераз кызып киткән чакларында да тавышы талгынлыгын югалтмый. Әмма эшкә батыр иде Госман ага. Ул, мөгаен, каннан-нәселдән килгән егетлекне-сугышчанлыкны хезмәткә, иҗатка юнәлдерә белгәндер. Ә нәселләрендәге шул гайярьлек турында безгә, яшь хезмәттәшләренә, сөйләгәннәре булды аның. Менә, әйтик, Госман абыйның атасы Нигъмәтҗан аганы алыйк. Аның язмыш юлы гел маҗаралардан тора кебек. Уральскидан авылына кайтып төпләнгәч, ул гаилә корып җибәрә, хәләл көче белән йорт-җирен яңарта. Кәсепчелеккә дә хирыс була үзе. Шуңа күрә авылдашлары Казанга барып ит сату эшен Нигъмәтҗанга тапшыралар. Керемнең күпмедер өлеше сатучыга кала инде, әлбәттә. Шулай бервакыт Казан базарында ит сатып, әйбәт кенә акча эшләп, ат белән кайтыр юлга чыга Нигъмәтҗан. Биектауны үтеп бераз баруга ук, артыннан юырттырып килүче шикле җайдакларны шәйләп ала. Сизенә егет: хәерле эш белән йөрмиләр болар. Шунда ул ат чанасына аягүрә торып баса, өстендәге толыбын салып ташлый һәм җан дусты Йолдыз кашканың дилбегәсен тартып җибәрә. Шуны гына көткән кара айгыр дулап алга ыргыла. Чана юлы такыр, ат шәп.

Инде эзәрлекләп килүчеләр ерагайганнан-ерагая бара кебек. Әмма, гөнаһ шомлыгы, шулвакыт җайдакларның берсе, юлны кистереп, аның каршына ук чыга, чабып килгән уңайга Нигъмәтҗанның атына сикереп атлана. Тик егет җебеп калмый, кулындагы бүре суга торган чукмарын уйнатып ала. Юлбасар егылып кала.

Нигъмәтҗанның барганда-кайтканда ярты юлда кереп куна торган танышы, бик әйбәт рус кешесе була. Кышкы төндә сабынлангандай тиргә баткан кара айгыр менә шул кешенең капка төбенә килеп туктый. Юл буе һәр тарафтан хәтәр көтеп талчыккан, сусаган Нигъмәтҗан, аны-моны әйтеп тормый, өйгә кереп китә, хуҗа кеше атын туарып кала. Озак та үтми ул да, йөзе-бите агарган хәлдә, Нигъмәтҗан янына атылып керә. «У тебя под санями человек… не шевелится…» — ди ул, сулышын көчкә алып. Чыгып карасалар, чыннан да үрәчә астында кеше гәүдәсе ята. Бүре чукмары эләккәннән соң егылып төшкән юлбасар шунда кереп кысылган һәм кара айгыр ничәмә-ничә чакрымнар буе аны сөйрәп кайткан икән.

Тиз генә авыл Советына хәбәр итәләр, Әтнәдән милиция чакыртыла. Һәм Нигъмәтҗанга шушындый әшәке бандитны эләктергән өчен рәхмәт әйтеп, туган авылына озаталар. Чыннан да, юлчыларны талап, үтереп йөрүче бу банданы милиция инде байтактан эзәрлекләгән, тик эзләренә генә төшә алмаган булган.

Бу әле Госман абый безгә сөйләгән бер генә эпизод. Ә инде Нигъмәтҗан аганың язмыш юлы турында маҗаралы китап язып булыр иде. Аның егетлеге улы Госманга, әйткәнебезчә, иҗат гайярьлеге булып күчкән. Әнә шуңа да ул көндәлек тапшырулар, яисә мәңгелеккә каласы спектакльләр яздырган чагында кеше сөйләмендә бер-бер хата китсә, аның кем булуына, даны-дәрәҗәсенә карап тормастан, төймәгә басып, язманы туктата. Ничек булырга тиешлеген иплән кенә аңлата, яңадан яздыра… дөресләнгәнчегә кадәр яздыра. Аның белән бәхәсләшмиләр, чөнки беләләр: гәрчә рәсми кәгазьләре булмаса да, ул — тел галиме, әдәбият галиме, тарихчы, музыка белгече, физик, математик, астроном һәм тагын мең төрле гыйлемнәр иясе.

…Хәер, аның тормыш юлына урап кайтыйк. Галиәсгар Камал исемендәге театр сәхнәсендә 11 ел дәвамында ул калдырган якты эз, тамашачы хәтерендә әле дә сакланган рольләре хакында сөйли китсәң, үзе бер кыйсса булыр иде. Ләкин Госманның язмышына язылган эше башка икән әле. Сабый чагыннан ук радио җене кагылган аңа, артист буларак, радиоспектакльләрдә катнашырга барган саен шул «җен» һаман котырына, яз исе кергән җилкенчәк кебек, күңел гел шунда тартыла. Моны сизенәләр, әлбәттә, һәм 1960 елда аны яңа оешкан телестудиягә режиссёр ассистенты итеп чакыралар. Анда бер ел эшләүгә, Госман радиога тәрҗемәче булып күчә.

«Тәрҗемә эше белән мин электән үк шөгыльләнә идем, — дип сөйләгән булган ул радиога биргән интервьюсында. — *Әле училищеда укыган вакытта ук үзебезгә уйнар өчен Көнбатыш һәм рус классикасыннан өзекләр эзли идек. Шулвакытта Лермонтовның «Маскарад» драмасын тәрҗемә иттем. Аны студентлар белән сәхнәгә куйдык. Аннары Карло Гоццины «Болан патша» дигән әсәрен татарчалаштырдым. Бу шөгылем театрда эшләгән вакытта да дәвам итте. Ул чакта радиода режиссёр булып эшләүче Гали Хөсәенов, бу турыда ишеткәч, мине радиога тәрҗемә белән шөгыльләнергә тартты. Бик күп Көнбатыш, рус әйберләрен тәрҗемә итәргә туры килде. Аннан җырларны татарчалаштыруга да кереп кителде. Флёра Сөләйманова әле ул чакта радиода оператор булып эшли иде, шулай бервакыт ул миңа бер җыр тыңлатты. Казакъ телендә булса да, татар күңелен дә иркәли торган әллә нинди*

Радиопостановкага керешер алдыннан. Шәүкәт Биктимер, Госман Әхмәтҗан, Әминә Шаһиәхмәт, Зөлфәт Хәким. 1995 ел

Түрдән: Госман Әхмәтҗан, Айрат Арслан, Мәрьям Арсланова, Фоат Галимуллин. 1995 ел

бер аһәңе бар иде аның. Туктале, бу җыр безнең халыкка да ошарга тиеш, дип, мин аны тәрҗемә итеп карарга булдым. Гафур Каюрбәков шигыренә композитор Шәмши Калдаяков иҗат иткән «Әниемә» җыры иде ул:

Бурычлы сиңа мин, Әнкәем-алтыным,
Сиңа дип эзләдем дөньяның асылын.
Ай белән кояшны бирим, дип уйладым,
Үрелеп алырга җитмәде буйларым...

Җырны беренче булып Флёра Сөләйманова башкарды. Халык аны яратып кабул итте. Җыр таралып китте. Ул елларда урысларда бик популяр җырлар бар иде. Җырчылар, тәрҗемә итсәгез, шуларны без дә

Юк, безнең алда өлкән яшьтәге замандашыбыз түгел, Аллаһыдан башка бер генә затка да буйсынмаучы, үлемне коллыктан өстен күреп, ил азатлыгы өчен ут эченә кереп баручы гайярь ир-егет иде. Без Госман абыебызның чын асылын менә шул мизгелдә тойганбыздыр, мөгаен.

җырлар идек, дип килә башладылар. Бу яктан Эмиль Җәләлетдинов актив булды. Аның үтенече буенча «День победы» җырын — «Җиңү таңы», «Журавли»ны «Торналар» дигән исем белән татарчалаштырдым. Соңрак Нәҗип Җиһановның «Качкын» операсын (Әхмәт Фәйзи либреттосы) русчага тәрҗемә иттем. Аның белән 3 ел утырырга туры килде, чөнки күләмле әйбер, ул минем шактый зур эшем булды дип саныйм...»

Шунысын да өстәп әйтик: Госман Әхмәтҗан радиода эшләгән елларында урыс һәм чит ил язучыларының юмористик әсәрләрен дә тәрҗемә итеп, аларны үзе үк башкарды да. Язмалары Татарстан радиосы фондында саклана.

1965 елдан Госман ага иҗат юлының кыл үзәгендә торачак эшкә — режиссёрлык хезмәтенә керешә. Аның тарафыннан куелган спектакльләрнең, композицияләрнең, ул әзерләгән тапшыруларның төгәл санын ачыклау өчен тулы бер фәнни тикшеренү таләп итәлә торгандыр.

Югарыда телгә алынган интервьюдан тагын бер өзек:

«Режиссёрга күп вакыт нәни генә бер детальне уйлап табу өчен дә төн йокламаска туры килә. Радиода декорация юк. Вакыйганы күз алдына китерү өчен йә музыка, йә тавыш эффектлары кулланыла, биредә хәтта паузалар да мәгънә белдерә. Аркадий Векслерның «Юлда» әсәре буенча куелган спектакль миңа бер сабак булды. Аны үзем тәрҗемә иткән идем. Әсәрнең бер эпизодында кеше бүре базына төшеп китә. Менә шул моментта нинди тавыш бирергә? Кирәкле тавышларны туплау өчен студиягә төрле чыбык-чабыклар, печән алып кереп, аларны сындыргалап, шудырып, алынган тавышларны бергә укмаштырып, таләп ителгән эффектны табуга ирештем. Тагын: Әхмәт Рәшитнең «Мөхәммәдьяр» дигән поэмасын эшләгәндә Казанны яулап алу вакыйгасы. Ничек бирергә? Вакыйганы ничек күз алдына китерергә? Шуннан башка бер уй килде: безнең ата-бабалар аеруча әһәмиятле хәлләр вакытында тәкъбир әйтә торган булганнар. Артистлар чакырып булмый, бик күп кеше җыярга кирәк, үзебездәге егетләрне студиягә чакырдым. Рәхмәт, барысы да риза булды. Башта бөтенебез саф булып тәкъбир әйтәбез, соңгы сугышка барган чакта берәүләр төшеп кала, икенчеләр дәвам итә. Ахырда бер генә тавыш кала, ул да өзелә. Безнең гаскәрләрнең һәлак булуларын менә шушы рәвештә күзалларга мөмкин иде...»

Госман аганың сүзләренә үзебезнекен ялгап китик: әйе, 1990 нчы еллар башында ул милли темаларны алгы сафка алып чыкты. Әхмәт Рәшитнең инде әйтелгән «Мөхәмәдьяр», «Кол

Утырганнар (сулдан): Хуҗи Мәхмутов, Әлфия Гыйлаҗи, Вахит Хаков, Госман Әхмәтҗан; аягүрә: Рөстәм Акъегет, Минвәгыйзь Зәйнетдинов, Җәүдәт Дәрзаман, Әхмәт Рәшит, Рәшит Ягъфәр. 1990 нчы еллар

Шәриф» поэмаларына, Җәмит Рәхимовның «Батырша» романына һәм тагын башка бик күп әсәрләргә нигезләнеп, радиоспектакльләр эшләнде. Горурланып әйтәм: Госман ага телгә алып үткән тәкъбир әйтү эпизодында минем үземә дә катнашу насыйп булды. Студиядә Коръәннең байтак сүрәләрен яттан белүче Әхмәт Рәшит белән Җәүдәт Дәрзаман, алар янәшәсендә шагыйрь Рөстәм Акъегет, язучы Заһид Мәхмүди, журналист Рәзин Нуруллин һәм башкалар — болар инде тәкъбир әйтмәслек кешеләр түгел. Тик режиссёрга һаман нидер ошап җитми.

— Монда бит, егетләр, сәхнә түгел, — диде шулчак Госман ага, — радиотыңлаучыга актёрның уены да, мимика, ишарәләре дә, декорация дә күренми. Биредә башкаручының бердәнбер коралы — аның тавышы. Димәк, тавыш ихлас, чын йөрәктән булырга тиеш! Чын йөрәктән чыкмаса, сүз йөрәкләргә керә алмас…

Шунда ул, ишетелер-ишетелмәс кенә итеп тәкъбир әйтергә кереште. Бу мизгелдә, гүя, вакыт тукталып калды, аның тавышы тәндәге бөтен күзәнәкләрне уятты. Тәкъбиргә кушылып киткәнебезне сизми дә калдык. Юк, безнең алда өлкән яшьтәге замандашыбыз түгел, Аллаһыдан башка бер генә затка да буйсынмаучы, үлемне коллыктан өстен күреп, ил азатлыгы өчен ут эченә кереп баручы гайярь ир-егет иде. Без Госман абыебызның чын асылын менә шул мизгелдә тойганбыздыр, мөгаен.

…Госман ага Әхмәтҗанның абруйлы исемнәре байтак — Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, СССРның телевидение һәм радио отличнигы, һәм башкалар. Ләкин аның күп санлы шәкертләре, хезмәттәшләре күңелендә сакланган олы бер исем-титулы бар — Остаз. Шушы олуг остаз биргән сабаклар озак вакытлар дәвамында милләткә хезмәт итәчәк әле! Тууына 90 ел тулып килгән шушы көннәрдә якты исемен дога белән искә алыйк.

Нәсим Акмал,
Г.Әхмәтҗанның шәкерте

МИЛЛИЯТ СҮЗЛЕГЕ

Адлер Тимергалин



ЙОЗАК — Бик, бикләвеч. Сүзнең төпле этимологиясе юк, ул күпчелек төрки телләрдә очрамый да. Куман телендә *йусхак*. Гарәпчәсе — *кофел (көфел)*.

Цивилизация үсеше белән бер үк вакытта кешелек тормышында саклагыч йозакларның роле артканнан-арта барган, яңадан-яңа йозак һәм бик төрләре уйлап табылган. Борынгы Болгар җирләрен казыганда археологлар күпсанлы бронза йозак калдыкларына юлыгалар. Бу йозаклар ат, сарык, көчек кебек хайваннар рәвешендә шактый зур итеп ясалганнар. Биләрдә табылган бер болгар йозагында Әбүбәкер исемле останың имзасын күрәбез (ясалу вакыты 1146/47 ел).

Төшеңдә йозак күрүгә карата төрле-төрле тәгъбирләр туган. Гомумән, төштә йозак күрү аптыраштa калдырачак хәлләр турында кисәтү, дип карала. Әгәр төшегездә йозакны бикләп торуыгызны яки ачканыгызны күргәнсез икән, тәгъбирнамәләр сезнең дошманнарыгыз яман ният белән йөриләр, дип фараз итә.

//*Усал йозак* — бу термин, ихтимал, борынгы төрки *ус, ос* («тәҗрибә, дикъкать, акыл») сүзенә барып тоташа торгандыр. Ул чагында аның мәгънәсе «акыллы, хәйләкәр йозак» булып чыга. Әгәр *йозак* сүзе белән *тозак* сүзе арасында параллель үткәрсәк, *усал тозак* атамасының мәгънәсе ачыкланыр иде. *Амбар йозагы. Богау йозагы. Йозак томлыгу* — йозакның ачкыч белән бикләнми торуы. *Сандык йозагы. Мылтык йозагы, туп йозагы* (русча — *затвор*). *Йозакчы* — тупны корып торучы (бу сүз татар прозаигы Г.Әпсәләмов текстында очрый.)

Русча — *замок* (басым соңгы иҗеккә төшә). Басым беренче иҗеккә төшкәндә, бу сүз ныгытылган йортны, кальга-йортны, баструкны белдерә.

Тагын кара: ***Кофел, көфел.***

ЙОКЫ — Гомумтөрки сүз. Иске татар телендә — *уйку/ойкы*. Гарәпчә — *нәвем*. «Йокы — үлемнең карендәше», дигән сүз гарәптән кергән.

«Кайсы сәгатьләрдә йокларга кирәк?» — дигән сорау бик әһәмиятле. Намазларын вакытында үтәп бара торган мөселман кешесе өчен йокының әһәмияте, ихтимал, тагы да зуррактыр. Ураза вакытында көндәлек режимны

*Дәвамы. 2014 елның 3 нче саныннан басылып килә.

дөрес оештырып, йокыга тиешле кадәр вакыт бирүгә нык игътибар итәргә кирәк. Организмны хәлсезләндермәс өчен, бу вакытта көндезләрен өйләдән соң бераз черем итеп алу файдалы.

Гомумән, кичке сәгать 11 дән иртәнге 6-7 ләргә кадәр ара йокы өчен аеруча файдалы дип исәплиләр. Кичке сәгать 11 ләргә организмыбыз инде шулкадәр арыган була, ул йокыга тоткарлануны үз эшчәнлегендә зарури вакыт буларак кабул итә. Иртәрәк ятканда йокыга тоткарлану тиешле вакыттан бераз элегрәк булырга мөмкин. Чөнки иртәрәк ятуыбыз белән әле шактый актив хәлдәге орган һәм системаларыбыз эшчәнлеген без беркадәр ясалма рәвештә тоткарлыйбыз. Әгәр дә тиешле вакыттан соңрак йокларга ятсак, кайбер орган һәм системаларның шушы мизгелгә үтә нык аруы мөмкин. Андый шартларда йокыга тоткарлануның бик тискәре нәтиҗә бирүе ихтимал. Күпләрнең йокларга соң ятканда, йоклап китү мизгелендә, мөгаен, кинәт һава җитми башлавын, йөрәк тибеше ешаюын тойганнары, тиргә батканнары бардыр. Болар — нәкъ менә йокыга вакытсыз тоткарлану нәтиҗәсе.

Шуны әйтергә кирәк, йокы өчен кичке 11дән иртәнге сәгать 7гә кадәрге вакыт һәркемгә дә мәҗбүри түгел. Асылда һәр кешенең үзенең эш һәм ял режимы була: берәүләр — «тургай», аларның иң иҗади хезмәт вакытлары иртәнге 5тән 8гә кадәрге сәгатьләргә туры килә. Икенчеләр исә — «төнге ябалаклар», алар, киресенчә, кичен һәм төнлә эшләргә яраталар.

Мөхәммәд Хәсән бине Хөсәен үзенең «Тыйбб китабы»нда: «Йокының сәламәтлек өчен файдалы вакыты шулдыр ки: кеше әүвәл уң ягына, соңыннан сул ягына ята. Карыны өстенә яту — ашказанын эшләтмидер. Әмма аркага чалкан ятарга ярамастыр. Күп авырулар килеп чыгар: зыяндаш, буын авырулары, сеңерләр тартышу авыруы, арка авыруы, томау һәм фалиж (паралич) кебек авырулар», — дип яза. Аның сүзләрендә азмы-күпме дөреслек бар кебек.

Төнге йокыга кагылышлы тагын бер искәрмә. Кайбер кешеләр тиз генә йоклап китә алмыйлар һәм йокыга талганчы урында кайвакыт ике-өч сәгать боргаланып яталар. Мондый чакта йоклата яки тынычландыра торган дару кулланмау хәерле. Дөрес көндәлек режим, гимнастика, су процедуралары һ.б.ш. йокыны нормальләштерү өчен иң әйбәт чара булып тора.

«Мәшһүр кешеләрдән кем күпме йоклаган?» — дигән сорау да кызыклы. Мәс., Леонардо да Винчи нибары 15 минут кына йоклап ала торган булган. Дөрес, ул һәр 4 сәгать саен башын мендәргә төрткән. Наполеон исә 4 сәгатьтән артык йокламаган, диләр. Эйнштейн да тәүлегенә 3-4 сәгать йоклаган, ләкин аның йокы схемасы башкачарак: ул 3,5 сәгать уяу булып, 15-20 минут йоклап алган да янә шулкадәр үк вакыт эшләп утырган.

Чарлз Диккенс, Уинстон Черчилль йокысызлыктан интеккән.

Нормаль кешене унҗиде тәүлек буена йоклатмасаң, ул акылдан яза. Бу факт КГБ төрмәләрендә ясалган «ачыш», дип уйлыйлар. Шулай да бер 17 яшьлек американ (Рэнди Гарднер) 1954 елда 230 сәгать буена йокыга китә алмаган.

Йокыдан торгач: «Әлхәмдү лилләһилләзи раддә галәййә рухи вә гафәни фи җәсәди вә әзинә ли би зикриһ», дип әйтергә киңәш ителә. Бу сүзләрнең мәгънәсе: «Миңа җанымны кайтарып биргән, бәдәнемә рәхәтлек биргән һәм үзен зикер итәргә миңа рөхсәт иткән Аллаһы Тәгаләгә барча мактаулар булсын». Бу догада йоклаган вакытта җанның тәннән аерылып торуы турындагы караш чагыла.

//*Йокы капчыгы* — йокычан кеше, йокы симертүче, йокы чүлмәге, русча — *соня*. Ә туристларның *йокы капчыгы (йоклау капчыгы) — спальный мешок* (русча). *Йокысызлыктан интекмәгән кеше үзенең биографиясен белми.* Дон-Аминадо.

Тагын кара: ***Төш юрау.*** ■

«Кояш» газетасында «Казан хәбәрләре»: 1915 елның июнь ае

Текстны һәм искәрмәләрне басмага Ленар Гобәйдуллин әзерләде.

Сабан туе

Үткән җомга көн Сабан туеның соңгы көне булды. Халык, бигрәк тә Казанның могтәбәраны әүвәлге көннәрдән күбрәк иде. Моның өстенә губерна башлыгы Боярский, шәһәр башлыгы Баронин һәм полицеймейстер ярдәмчесе Ширшновның булуы Сабан туен яхшы ук эреләндереп җибәргән иде.

Сабан туенда бу көн дә әүвәлге программа белән уеннар уйналды. Таяк тартышу, америкалыларча күп кеше катнашы белән аркан тартышу программаның әүвәлге көннәрендә ясалмаган яңа номерларыннан иделәр.

Уеннар ярыйсы гына рухлы үтте. Зурлар көрәшендә Габдулла Галиәкбәров 9, Вафа Хәйруллин 9, Миңлеҗан Сәйфетдинов 8, Мортаза Мостафин 8 кешене җиңеп батыр булып калды. Зурлар йөгерешендә Шәһидулла исемле егет беренче, Гани Вәлиев икенче килделәр. Велосипедчылардан әүвәлге ике көндә беренче килгән Егоров бу көндә дә беренче булып килде. Атлар чабышында Җиһаншин аты беренче, Габдуллаҗан Шәфиев аты икенче, Хәерби Кәрим хәзрәт аты өченче булып килде.

Бу көн Сабан туеның бөтен кереме 600 сумнан артыграк булган. Шуның 580 сумы билет сатудан килгән.

Кояш. — 1915. — №717. — 1 июнь.

Бәйрәм ялы хакында

1914 нче елның 9 нчы сентябрендә вилаять валисе [губернатор] тарафыннан праздникларда кибет ябарга мәҗбүр итә һәм 12 дән 5 кә кадәр ачарга мөмкинлек бирә торган вакытлы **мәҗбүри карар** чыгарылган иде. Шәһәр главасы, Дума әмерен җиренә җиткерү юлында бу **мәҗбүри карар**ны чыгаруда вилаять валисен хаксыз табып, Дахилия вәзарәтенә [Эчке эшләр министрлыгына] вилаять валисе өстеннән шикаять биргән иде. Инде хәзер вилаять валисе шәһәр управасына Дахилия вәзарәтенең шушы шикаятькә җавабының копиясен җибәргән. Дахилия вәзарәте шәһәр главасының шикаятен игътибарга алырлык тапмаган һәм шунлыктан бу шикаятьне нәтиҗәсез итеп калдырырга (кабулга ашырмаска) ясаган.

Кояш. — 1915. — №718. — 2 июнь.

Асаре гатика [археология]

Казанның асаре гатика җәмгыяте бу ел да Болгар ханлыгы урынындагы җирләрне казып, болгарларга караган асаре гатиканы тикшерүендә дәвам итәдер. Бу ел болар Болгар авылында һәм дә Чистай өязендәге Биләр авылында казыналар. Өченче көн Биләр авылыннан асаре гатика мөтәхассыйсе

* Даталар иске стиль белән бирелә.

[археолог] Понамарёв шәһәргә кайткан. Аның риваятенә караганда, бу ел Биләр авылы янындагы казынуларның нәтиҗәсе буларак, болгарлардан калган кирпеч корылманың нигезе һәм мичтән чыга торган төтен юллар, вә бер морҗа һәм дә бик иске болгарларга караган икәнен аңлата торган чирәп[1] комганнар табылган. Моннан башка Окушка инеше буенда бик күп болгар баш сөякләре табылган. Җәмгыятьнең шунда хезмәт итүче әгъзалары тарафыннан Тимерләккә[2] мөнәсәбәтле курган (туфрак койма белән әйләндерелгән түгәрәк крепость) һәм дә Изгеләр чишмәсе дигән җирдә мөселман каберлекләре тикшерелгән. Биләр янында байтак курганнар барлыгы беленгән. Болар арасында ат каберлекләре, адәм каберстаны табылган. Курганнарның күбесе хәзерге көндә иген игелгән җирдә булганлыктан, аларны казып йөрүләрдән иген җыелганга кадәр туктап торырга уйлаганнар. Бу тирәләрдә кыйммәтле нәрсәләр табылганга күрә, якындагы авыл кешеләре казып иске урыннарны бик күп бозганлыклары беленә икән.

Кояш. — 1915. — №720. — 4 июнь.

Сабан туе хисабы

Бу елгы Сабан туеның варидәт-мәсариф [керем-чыгым] хисабы исәпләнеп беткән. Өч көн дәвам иткән бу Сабан туеның варидәте 2527 сум 77 тиен булган. Мәсарифы исә 743 сум 33 тиен. Саф файда бу хисап буенча 1784 сум 44 тиен буладыр. Моның 100 сумы Татьяна Николаевна хәзрәтләре комитеты файдасына вәгъдә ителгән булып, моннан калганы җәмгыяте хәйриянең үз файдасына — мөселман шифаханәсендә мәҗрухлар тәрбиясе өчен ачылган кроватьларны тәрбия мәсарифына китәчәктер. Сабан туеның җентекле хисабы җәмгыять идарәсе тарафыннан якын көннәрдә игълан ителсә кирәк.

Кояш. — 1915. — №722. — 7 июнь.

Татарча спектакль

19 июньдә җомга көн Панаев бакчасында[3] «Сәйяр» труппасы тарафыннан спектакль бирелеп, тамашага «Хуҗа һәм приказчик» вә «Артист» исемле пьесалар куелды.

«Хуҗа һәм приказчик» кебек тозсыз вә артык түбән пьесаның куелуын, куярлык пьесалар юклыгы белән генә аңлатырга мөмкин. Югыйсә ... бу пьеса иң буш баш белән язылган пьесаларның берседер. «Артист» пьесасы уйнала башлагач, бераз иркенрәк сулу алырга мөмкин булды ичмаса, ул кадәр эч пошмый.

Бу пьесалар уйналышларына килсәк, икесе дә ярыйсы уйналды. Тик хатын рольләре генә зәгыйфьрәк, йомшаграк. Әгәр дә алар да ирләр роле белән беррәк сценага менгерелсә, «яхшы уйналды», дияргә үк мөмкин булыр иде. Шулай да халык уенны яратты төсле, һәр пәрдәдән соң артистларны бик нык алкышладылар. Халкыбызның зәвыгына «яхшы фикеребез» булса да, бу алкышлар пьесаларга түгел, бәлки артистларга юнәлтелгән, дип уйларга җөрьәт итәбез.

Кояш. — 1915. — №734. — 22 июнь. ■

[1] Чирәп — киң авызлы.
[2] Тимерләк — Аксак Тимер.
[3] Панаев бакчасы турында www.beznenmiras.ru сайтыннан укыгыз.

КОРЪӘН САВЫТЛАРЫ

(ТР Милли музее фондларыннан)



Белгәнебезчә, Коръән — мөселманнарның изге китабы. Аны элек-электән күз карасыдай саклаганнар. Шуңа да махсус савытлар уйлап табылган. Алар өчпочмак, турыпочмак рәвешендәге геометрик фигуралар формасында ясалган, гарәп хәрефләре белән матур итеп язылып, үсемлек орнамент-

лары белән бизәлгән. Мондый савытларны ир-егетләр хатын-кызларга бүләк иткән, дигән фикер йөри.

Милли музейга нигез салучы А.Ф.Лихачёвның бай коллекциясендә дә алтын һәм көмештән эшләнгән унберләп Коръән савыты бар. Шулай ук музейда асылташлар белән бизәлгән Коръән савытлары да саклана. Фирүзә асылташ белән бизәлгән түгәрәк формадагы савыт күпләрне таң калдыра. Коръән савытлары белән «Казан татарларының бизәнү әйберләре» күргәзмәсендә танышырга мөмкин.

Руфия Мөхетдинова *әзерләде.* ■

Сабан туеның шаян мизгелләре

Алмаз Хәмзин

А.Алёшин шаржы

«Без — Сабантуйлы халык!» — дип юкка гына әйтмибез. Һәм ул шулай да. Дөньяда аңа охшаган бәйрәмнәр күп, әлбәттә. Ләкин күкрәк кагып, горурланып сөйләрлек, үзебезнең Сабан туен узарлык, ай-һай, бар микән тагын шундыйлары?!

...Бер елны Казандагы «Каенлык»та үтә торган Сабан туе уеннарында, беренче мәртәбә үзем катнашмыйча, рәхәтләнеп, халыкча күңел ачып йөрергә булдым. Ул чакта бу олуг бәйрәмне безнең белән бергә карап ләззәтләнергә Президент Путин да килгән иде. Кызып китеп, катыктан акча эзләгән елы аның... Хәтерлисездер? Аннан соң, башка уеннарны да карап, шаккатып йөрде. Иң гаҗәпләндергәне — этиле-уллы берәүләрнең маймылларны да уздырып, колга буйлап аска-өскә үрмәләүләре, шунда әллә нинди акробатик хәрәкәтләр ясап, берсе аркылы икенчесе узышып йөрүләренә таң калды. Үзем ишеттем: телен шартлатып болай диде ул: «Чего только на свете не увидел, но такого!!!»

Авызын ачып, озак күзәтте ул аларны. Мин шунда эчемнән генә: «Сабан туена ешрак килеп йөрсәгез, әлләниләр күрерсез әле!» — дип уйлап куйдым. «Татар — ботыңнан тотып атар!» — дигән әйтем дә искә төште, кисәтү рәвешендә. Алайса... уйлап йөриләр бит кайберәүләр, Сабан туеның нәрсә икәнлеген дә аңламыйча, ызгыш-талаш, тәртипсезлек булган җирдә: «Что за Сабантуй устроили здесь?» — дип. Әле үз татарларыбыз да болай дигән булалар: «Нам татарам всё равно, что Сабантуй, что война!» Мәгънәсезлек, чама юклык, мокытлык аңкып тора бу әйтемнәрдә. Әйдәгез, без аны шаярту дип кенә бәялик тә, түбәндәге шаян рәсемнәргә һәм шигырьгә игътибар биреп, үткән заманнарга да — шаян мирасыбызга бер күз салыйк әле! ■

Шәүкәт Галиев
(1928-2011)

Читләр читтән күргәнчә...

Бик ерак бер илдән, ди,
Бер журналист килгән, ди,
Безнең якта күргәнен
Кайткач язып биргән, ди.

«...Төрле анда килешләр,
Төрле анда килбәтләр,
Дөрес әйтеп килгәнбез —
Дус яшәми милләтләр!

Мәсәлән, бер колхозга
«Дуслык» диеп кушканнар,
Бактың исә, үзләре
Менә дигән дошманнар!

Җыйнаулашып сугышлар
Гадәт икән гел генә,
Мин үзем дә юлыктым
Шундыйларның беренә.

...Башта Миклай каршына
Педер атылып чыкты,
Миклай сугуын сукты,
Педер бәреп ук екты!

Учларына төкереп
Иван торды сикереп,
Һәм тондырды Педергә
Мәтәлерлек иттереп!

Киерде дә түшләрен,
Кысты Вәли тешләрен —
Сизми калды Иван да
Җиргә барып төшкәнен!

Булды анда төрлесе,
Буталышып беттеләр,
Капчык белән дөп тә дөп
Тетмәләрен теттеләр!

Мин сизмәсен дип кенә
Елмаешкан итәләр,
Һәм дә шушы сугышны
«Сабантуй» дип әйтәләр!

Юк, киметә алмаслар
Бу фактның кыйммәтен —
Тукмашканда һәркемнең
Сорап тордым милләтен:

Миклай — мари икән бит,
Педер — чуаш икән бит!
Вәли — татар икән бит,
Иваны — рус икән бит!

Җиңелгәчтен, әлбәттә,
Иван ачулангандыр,
Үч алмакчы булгандыр,
Шуңа кусәк алгандыр!

Арттан килеп карт татар
Тизрәк күзен бәйләде,
Иван селтәп кусәкне
Мәйдан буйлап әйләнде.

Дошманнарга бәрәм дип,
Җиргә суга шап та шап,
Үзләренә тимәгәч,
Педер, Вәли, Миклай шат.

Ярый әле кусәге
Чүлмәккә генә тиде —
Юкса, Иван бәррәттән
Барсын да кыра иде!

Ә бит шушы колхозга
«Дуслык» диеп кушканнар,
Күрдегез ич, үзара
Әнә ничек дошманнар!»

...Бик ерак бер илдән, ди,
Бер журналист килгән, ди,
Сабантуйда күргәнен
Шулай язып биргән, ди...



– Ветфельдшерны әйтәм, булдыра икән үзе, ничек йөгерә!
– Шәһәргә качуы бит, ничек йөгермәсен!

– Сыпыртыйк моннан: шаһит итеп судка-фәләнгә йөртмәгәйләре!

– Мөдир иптәш, йомырка тапшыру планын быел дә үти алмыйбыз, болай булса...

*Шигырь һәм шаян рәсемнәр «Чаян» журналының төрле елларда дөнья күргән саннарыннан алынды.

Ләбүдә Дәүләтшина,
Кукмара туган төбәкне өйрәнү музее директоры

Узган 2014 ел ахырында Казандагы «Милли китап» нәшриятында тарихчы галимнәр Ирек Һадиев белән Раиф Мәрдановның «Кукмара төбәгенең ташъязма истәлекләре» дип аталган 200 битле китабы басылып чыкты. Бу фәнни хезмәт «Челтәр компаниясе» ачык акционерлык җәмгыяте генераль директоры, Кукмара туган төбәкне өйрәнү музеена да зур булышлык күрсәткән Илшат Шәех улы Фәрдиевнең матди ярдәме белән нәшер ителде.



КУКМАРА ТӨБӘГЕ ТАРИХЫ – ЯҢА КИТАПТА

Кукмара туган төбәкне өйрәнү музее хезмәткәрләре белән 1998 елда үзара киңәш-табыш иткәннән соң, якташ галимнәребез Ирек Һадиев белән Раиф Мәрданов райондагы элекке кабер ташларын комплекслы өйрәнү бурычын үтәргә алындылар. Бу максатта, җирле хакимият ярдәме белән, алар тарафыннан 1998-1999 һәм 2013-2014 елларда махсус фәнни-тикшеренү экспедицияләре оештырылды. Нәтиҗәдә, Кукмара районының 61 татар авылындагы зиратлар өйрәнелеп, гарәп язулы 305 кабер ташы исәпкә алынды һәм тикшерелде.

Кукмара районында ачыкланган иң борынгы биш таш XVII гасырга карый. Алар Ятмас Дусай (1676 ел), Өлге (1681 ел), Мәмәшир (ике таш: 1684 һәм 1685 елгылар), Байлангар (якынча 1670-1680 еллар) авылларында сакланган. Кайберләрендә аларны уйган оста — Килмөхәммәд Ишмән улының исеме дә язып куелган. Шунысы да мәгълүм булсын: 2002 елның җәендә Мәмәшир һәм Өлге авылларындагы әлеге борынгы истәлекләргә Кукмара районы хакимияте һәм район музее хезмәткәрләре тырышлыгы белән бизәкле тимер чардуганнар куелды.

Өйрәнелгән ташъязмаларның күпчелеге XIX гасырның икенче яртысына һәм XX гасыр башына карый. Кукмара районында

әүвәлге ташлар иң күп тупланган урын — Мәчкәрә авылы. Андагы 35 ташъязма истәлек өйрәнелгән. Мәчкәрә авылы, гомумән, татар тарихында мәгърифәт үзәге буларак абруйлы бер урын алып тора. Зираттагы ташлар да электәге мәдәнилек, мәгърифәтлелек эчендә узган тормышның көзгесе кебек.

Кукмара төбәгендәге төрле авыл зиратларында бер үк оста — «мулла Фәллахетдин Кенәбаши» тарафыннан язылган ташлар очрый. XIX гасыр ахыры-XX гасыр башында бу оста уйган ташлар (иң әүвәлгесе 1882 елга, ә иң соңгысы 1918 елга карый) Кәчимер, Кенәбаш, Әсән-Елга, Пычак, Өлге, Иске Пенәгәр, Олыяз, Мәчкәрә һ.б. авылларда бар.

Кабер ташлары мәрхүм ир-атларга да, хатын-кызларга да, балаларга да бердәй хөрмәт белән куелганнар, китапка теркәлгән ташъязма текстларыннан күренүенчә, аларда 186 ир-ат һәм 127 хатын-кыз исеме теркәлгән. Яшь ягыннан караганда, ташъязмаларда исемнәре теркәлгән мәрхүмнәрнең иң өлкәне — Тарлау авылыннан 98 яшьлек Мозаффар Сөләйман улы, ә иң кече яшьтәгесе — җиде айлык бала (Кенәбаш авылының Гыйлаҗетдин мулла улы Габделкоддус). Тагын 2, 3, 5 һәм 7 яшьлек балаларга куелган ташлар да бар.

Ташъязмаларның күпчелеге — гомумән, теге яки бу җәһәттән тарихи әһәмияткә ия истәлекләр. Әйтик, 1859 елда бу дөньядан киткән Исмәгыйль Сәйдәш улы Юнысовка Туеш авылы зиратында куелган затлы ташта аның кенәз, морза, купец, становой пристав, мәхкәмә рәисе булганлыгы хәбәр ителүе, ягъни шәхес турында бай мәгълүмат бирелүе кызыклы.

Галимнәр әүвәлге кабер ташларының тарихи кыйммәтен ассызыклау белән беррәттән, аларны татар милли сәнгате традицияләрен өйрәнүдә мөһим чыганак буларак та бәялиләр. Кукмара районындагы эпиграфик истәлекләр арасында да сәнгати эшләнешләре җәһәтеннән аеруча затлы һәм купшы бизәкле, чәчәк-үсемлек һәм геометрик орнаментлар мул һәм зәвыклы кулланылган, гарәп каллиграфиясенең гаҗәеп матурлыгын чагылдырган үрнәкләр бар. Шундыйлардан бер өлешенең фоторәсемнәре бу китапта аерым тупланма итеп бирелгән.

Китапның ахырындагы сүзлектә иске төрки-татар, шулай ук гарәп һәм фарсы телләрендәге сүзләргә, тулы гыйбарә-җөмләләргә һәм кайбер ташъязмаларның өлешчә текстларына тәрҗемәләр, аңлатмалар бар.

Ташларга исемнәре уелган кайбер шәхесләр турында өстәмә мәгълүматлар да язылган. Чөнки төбәк һәм авыл тарихлары өчен алар, һичшиксез, әһәмиятле. Кем өчендер вак булып тоелган нәрсә дә, үз урынына күрә гаять файдалы булып чыга. Тарих дигән гаҗәеп бай дөньяның серләре кечкенә бөртекләрдән тупланa да инде. Бүген нәрсәгәдер илтифат итүчеләр булмаса да, киләчәктә файдасы тияр.

Китапның ахырындагы кушымта өлешендә Кукмара ягы белән бәйле шәхесләрнең чит шәһәрләрдә (Казан, Оренбург, Троицк) һәм төбәкләрдә куелган 13 кабер ташы турында мәгълүмат өстәлгән.

Җыентыкның ахырында махсус өстәмә күрсәткечләр: ташъязма текстларында исемнәре телгә алынган шәхесләрнең, тасвирламаларда булган торак пунктлар атамаларының исемлекләре урнаштырылган. Алар аерым шәхесләр һәм авыл-шәһәр тарихлары белән кызыксынучыларның эшләрен җиңеләйтү өчен тәкъдим ителгәндер, мөгаен. Шунда ук таш уючылар һәм ташны куйдыручылар исемнәренең, дин әһелләре титулларының һ.б. атамаларның ярдәмче күрсәткечләре дә таблицалар рәвешендә урын алган.

Бу китап тәэсире белән күпләр үз туганнарының кабер ташларын зиратлардан табып, тирәсен чистартып, ташын төзәтеп куяр, ихластан багышлап догасын кылыр. Тарихи ядкярләрнең кадер һәм кыйммәтләрен аңлап, киләсе буыннарга да уалмыйча-

1832 елның декабрендә вафат булган Габдулла Габдессәлам углы Үтәмешевкә куелган таш. Мәчкәрә авылы

Кукмара районындагы эпиграфик истәлекләр арасында сәнгати эшләнешләре җәһәтеннән аеруча затлы һәм купшы бизәкле, чәчәк-үсемлек һәм геометрик орнаментлар мул һәм зәвыклы кулланылган, гарәп каллиграфиясенең гаҗәеп матурлыгын чагылдырган үрнәкләр бар.

ватылмыйча ирешүен хәстәрләр. Һәрхәлдә, авторлар һәм без шундый теләктә һәм өметтә калабыз. Аллаһының рәхмәте киң бит, арабызда игелекле затлар бар, әлхәмделилләһи. Әүвәлге тарихи ташларны җил-давылдан, ватылудан саклауның төрле ысуллары билгеле.

Тарихи мирасыбызны барлау, өйрәнү, киң даирәгә таныту белән шөгыльләнүчеләргә, әлеге кыйммәтле һәм мөһим хезмәтне бастыруга ярдәм күрсәткән игелекле затларга районыбыз халкы бик рәхмәтле!

Бу китаптан үзләренең нәселдәшләрен, элеккеге әбибабаларының, мәшһүр авылдаш-якташларының исемнәрен, ташларының рәсемнәрен табып куанучылар белән бергә без дә сөенәбез, тырышып эшләгән бу хезмәтнең бушка китмәгәнлеген дә тоябыз. Уртак шатлыкларыбыз бу китапта исемнәре искә алынган һәркемнең рухына изге дога булып ирешсә иде, амин! ■

Мирасворд



… Христиан Андерсен

2010 елда Федераль Сабантуй узган шәһәр

Көрәшче Әсхәт Гайфуллин туган район

Көньяк җимеше

«Кайдан син, …?» повесте (Ш.Рәкыйпов)

Саломея … (Литва шагыйрәсе)

Байрак, флаг

Француз актеры

… итеп искә төшү

Һ.Такташ поэмасы

Гектар

Казандагы бистә

Рахит (иск.)

Купшы, кояз

Актриса Ольга …

Шагыйрь Мөдәррис Әгъләмнең кушаматы

… Карнеги

Белән (иск.)

Әкияти тау

Колга башындагы йорт кошы

Бүлүче теркәгеч

Татар халкының милли бәйрәме

Казан татарларының топонимик риваятьләре

Того мәркәзе

… де Мопассан

Н.Гыйматдинова повесте

Кечкенә көймә

Кимоно путасы

… Шәйхетдинов (көрәшче, министр урынбасары)

Борынгы Рим полководецы

… Емельянов (көрәшен шагыйре)

Мәңге яшел көньяк куагы

Актёр Дэнни Де …

Борынгы Мисыр мифологиясендә Җир Алласы

Ләкин, тик

Мордваларның милли бәйрәме

… канаты ат була

Күзне бәйләп чүлмәк …

Рәис Габдулла төзеде.

5 нче санда дөнья күргән мирасвордның җаваплары:

Сулдан уңга: Гази, арзу, фырт, амия, Огайо, түшәк, әбәт, Карл, угы, Әсәл, ре, җиңги, марш, ирән, Таҗи, иза, Икен, изах, манара, утын, ияр.

Өстән аска: Кәрим, «Манас», Рәҗәп, Гафиятуллин, имди, «Зар», Ош, «Газинур», «Иртәгә», «Азат», АК, арык, Кутуй, имтихан, ошбу, аак, Әгерҗе, Батыршин.

«БЕЗНЕҢ МИРАС»
елъязмасы / июнь

- **210 ел элек (1805)**

Таҗетдин Ялчыголның (1768-1838) «Тәварихы Болгария» әсәре нәшер ителә.

- **185 ел элек (1830)**

Мәшһүр фабрикант Әсфәндияр Акчурин (1830-1903) дөньяга килә.

- **160 ел элек (1855)**

Казанда шәм һәм сабын кайнату заводы ачыла.

- **115 ел элек (1900)**

30 июньдә Брест крепосте каһарманы, Советлар Союзы Герое Пётр Гаврилов (1900-1979) дөньяга килә.

- **105 ел элек (1910)**

1 июньдә күренекле әдип Нәби Дәүли (1910-1989) дөньяга килә.

- **100 ел элек (1915)**

Колыманың Среднекан елгасы буенда беренче алтын бөртекләре табыла. Аны Казан губернасының Морзалар авылында туып-үскән Бари Шәфигуллин үзе казыган шурфта таба. Берничә елдан исә биредә «алтын өянәге» башлана. Магадан шәһәренә нигез салына...

Колыма җирендә 1928 елдан башлап бүгенге көнгә кадәр 3000 тонна алтын, 8000 мең тоннага якын көмеш табылган.

- **95 ел элек (1920)**

4 июньдә «Эшче» газетасы болай дип хәбәр итә: *«Сәяси идарә хозурындагы мөселман секциясе тарафыннан Самара шәһәрендә 15 июньдә 300 кешелек татар драма һәм музыка студияләре ачыладыр. Студиядә дәрес бирер өчен Казан, Мәскәү, Сарытау (Саратов) вә башка шәһәрләрдән мөтәхассис мөдәррисләр алдырылган шикелле, татар һәм шәрык сәнаигы нәфисәсе дөньясында татарның атаклы сәнгать нәфисә хадимнәре алдырылды.*

Бу студияләрдә 4 ай укыган гражданнар артист вә артистка булып, 6 ай укыганнар исә режиссёр-инструктор булып чыгачаклар.

Татар драма һәм музыка студияләренең юлбашчысы — Кәрим Тинчурин. Драма студиясенең мөдире — Зәйни Солтанов».

● 90 ел элек (1925)

25 июньдә Казанда беренче татар операсы «Сания» куела. Операның авторлары — Солтан Габәши, Газиз Әлмөхәммәтов һәм Василий Виноградов.

● 75 ел элек (1940)

Себер татарларының фольклор-авыз иҗаты әсәрләрен җыю вә ачыклау максаты белән Яңа Себер (Новосибирск) һәм Омск өлкәләренә экспедиция оештырыла. Фәнни сәфәрнең җитәкчесе — Хәмит Ярми.

● 70 ел элек (1945)

16 июньдә Польшаның Згәш шәһәрендәге хәрби госпитальдә Гадел Кутуй (1903-1945) вафат була.

17 июньдә «Кызыл Татарстан» газетасында II Белоруссия фронтының татар сугышчыларыннан татар халкына шигырь белән язган хаты игълан ителә.

Гадел Кутуй

● 60 ел элек (1955)

«Совет әдәбияты» журналында Нәкый Исәнбәтнең «Зифа» исемле дүрт пәрдәлек комедиясе басылып чыга.

● 55 ел элек (1960)

25 июньдә Габдулла Тукай премияләре буенча Республика комитеты карары нигезендә «По зову Ленина» һәм «Җил исми, яфрак селкенми» шигырь җыентыклары өчен шагыйрь Сибгат Хәким (1911-1986) Тукай премиясенә лаек була.

● 50 ел элек (1965)

«Совет әдәбияты» журналы «Казан утлары» исеме астында чыга башлый. «Казан утлары» журналында Ибраһим Салаховның «Күкчәтау далаларында» исемле романыннан бер өзек дөнья күрә.

● 45 ел элек (1970)

25 июньдә Татарстан АССР төзелүгә 50 ел тулу уңае белән Муса Җәлил исемендәге татар дәүләт опера һәм балет театрында тантаналы утырыш була. Утырышны ТАССР Верховный Советы Президиумы председателе Салих Батыев ачып җибәрә.

«Бүген бәйрәм!» Арча районының Яңа Кенәр авылы малайлары. 1973 ел

РИФКАТЬ ЯКУПОВ

Рифкать Госман улы Якупов 1944 елның 29 июлендә Ижау шәһәрендә дөньяга килә. 1967 елда Казан дәүләт университетының журналистика бүлеген тәмамлый. 1968-1986 елларда «Яшь ленинчы», «Комсомолец Татарии» газеталарында, «Азат хатын» журналында фотохәбәрче булып эшли. 1987 елдан — Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында фотограф.

Рифкать Якупов — Татарстан Журналистлар берлеге, Россия Фоторәссамнар берлеге әгъзасы, Дамир Сираҗиев исемендәге театраль премия лауреаты. Аның фотохезмәтләре Санкт-Петербург, Стокһольм, Берлиндагы этнография музейларында, шулай ук Нью-Йорктагы «Коркоран» галереясында саклана.

Сура елгасы. Ульяновск өлкәсе. 1978 ел

www.beznenmiras.ru

БЕЗ – МИРАСЛЫ ХАЛЫК!

«БЕЗНЕҢ МИРАС» БЕЛӘН БЕРГӘ БУЛЫГЫЗ!

Икенче ярты еллыкка почтада язылу бәясе – 498 сум. Редакциядә язылу бәясе – 380 сум.

ИНДЕКС:
ТАТАРСТАНДА – 54132
РОССИЯДӘ – 70275

4 612750 670172

«Безнең мирас» журналын башкалабыз Казандагы «Книги-Китаплар» (Бауман урамы, 29/11) кибетеннән, Г.Тукай музеендагы киосктан (Г.Тукай урамы, 74) сатып алырга мөмкин.

№06 / 2015